www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 15 (1380) 22 апрель 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga



8

Бөек шагыйребез Габдулла Тукай Әминә исемле кызга гыйшык тоткан дип расларга тырышу нигезлеме?



12

Мәскәүдә күренекле кинорежиссерлар белән эшләгән рәссам Рәшит Сафиуллин бүген кайнар эмаль белән иҗатка өстенлек бирә.

14

К. Тинчурин драма һәм комедия театры, нигезне саклаган хәлдә, заманадан артта калмас өчен, күп юнәлешле эшчәнлек алып бара.



Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк? – Хаккыбыз уртак ватанда шактый ук!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле «Хәзинә» концерт программасы белән Пермь крае, Свердловск өлкәсе һәм Удмуртия Республикасы буйлап гастрольләргә чыкты.
- Болгар музей-тыюлыгындагы бер урам быелдан «Идел Болгарында Ислам динен кабул итүгә 1100 ел» исемен йөртәчәк.
- Казан кооператив институтының Татар мәдәнияте үзәге республикакүләм «Шәҗәрәм» конкурсы уздырды.
- Ульяновск өлкәсенең Чынлы районы Яңа Тимерчән авылында Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына багышланган конференция узды.
- Чирмешәндәге мемориаль үзәктә биредә туып-үскән сәнгатькярләр – Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзалары Камил, Рәсүл һәм Рәмис Мингалимовларның картиналарыннан күргәзмә ачылды.
- Казан китапханәләре өчен Татарстан Мәдәният министрлыгы 4 миллионнан артык сумга китаплар сатып ала.
- Төмән шәһәренең татар мәдәният үзәгендә Себер татарлары тарихына багышланган «Себер каннык-2022» балалар рәсем бәйгесенә нәтиҗә ясалды.
- Төрки дөньяның уртак әдәбият басмасы – Төркиядә нәшер ителә торган «Кардәш каләмнәр» журналында тууына 135 ел тулу уңаеннан Галимҗан Ибраһимов турында мәкалә басылды.
- Казанның Аракчино бистәсендә 1956 елда рус шагыйре Александр Сергеевич Пушкинга куелган һәйкәлне торгызалар.
- «Абау» студиясе Татарстан Мәдәният министрлыгы ярдәмендә Салих Сәйдәшев һәм Кәрим Тинчурин тормыш сәхифәләреннән анимацияле видеоролик эшләде.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Мәсгудә ШӘМСЕТДИНОВА, композитор:

«Татарның кыйбласы кыйшайган. Мәскәүдә танылсын өчен безгә музыкабызны шулкадәр җәрәхәтләндерергә кирәк. Татар музыкасының кыйналуыннан аларга ләззәт булсын өчен шулкадәр бозарга кирәк. Индеецларның «Кагылмагыз безнең этнорәсемнәргә, безнең музыкага», дигән законнары бар. Мин дә татар көенә кагылган өчен штраф салыр идем. Безнең «Карурман»нарга тотынмасыннар! Ул җинаять! Аңа бернинди аранжировка кирәкми!»

СЫНАМЫШЛАР

Саесканнар караңгы төшкәнчегә кадәр бик биектә очса, икенче көнне аяз, коры була ● Усак чәчәге күп булса, арпа уңа ● Үрмәкүч, пәрәвезенә төренеп, почмакта утырса, төнге кыраулар көтелә ● 24 апрельгә елгаларда ташу китмәсә, җәй начар була ● Ай кызарып чыкса, җылыта иә яшенле яңгыр ява.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **4 сәгать 21 минутта** чыкты, һәм ул **19 сәгать 03 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **14 сәгать 41 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **31 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **29 апрельдә 15 сәгать 12 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

22 апрель – нәшир, каллиграф, шәркыятьче, Петербургта гарәп шрифтлы беренче басмаханә ачучы Ильяс Бораганскийның тууына 170 ел (1852–1942);

– шагыйрә һәм педагог Зәйнәп Хәлиулла кызы Сәгыйдәнең (Якупова-Бакирова) тууына 125 ел (1897–1994).

23 апрель – сәясәтче, тарихчы, дин әһеле Габдрәшит Гомәр улы Ибраһимовның тууына 165 ел (1857–1944 ел).

25 апрель – тарихчы, Лос-Анджелес университеты (АКШ) профессоры Азадә-Гайшә Рорлихка 80 яшь (1942);

– театр-декорацияләр сәнгате остасы, Татарстанның халык рәссамы Сергей Геннадьевич Скоморохова 70 яшь (1952).

26 апрель – шагыйрь һәм прозаик Рафаил Шәкүр улы Газизовка 75 яшь (1947).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Апрельнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләребез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 22, 23 апрель.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(23-30 апрель)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **18 февральдән 29 апрельгә кадәр** бавыр һәм үт куыгы актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны чистарту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген рамазан аеның 21 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Индус ТАҺИРОВ, академик

Без уяндык Рәсәйдә, таң белән...

Татар – тирән тамырлы халык, аның яшәү учагы беркайчан да сүнмәгән, тарихның иң авыр чорларында да пыскып булса да янып торган. Әгәр татар утының сагында Мәүлә Колый, аның остазы Мелла Мамайлар, аларның дәвамчылары Каюм Насыйри, Шиһаб Мәрҗани булмаса, татар учагы дөрләп китә дә алмас иде. Пыскып януның дөрләп китүенә тарихның кискен борылышлары сәбәп булды. Аларның иң беренчесе – 1905 ел революциясе. Тукай язганча, «уяндык без бишенче елның бер таңында». Моңа кадәр «татар үлмәгән, тик йокыга гына талган була». Канына бөек тарихы сеңгән булганлыктан ул яңа шартларда бик тиз уяна. Татарлар Россиянең иң укымышлы халкына, мисали ислам милләтенә әверелә.

Яңарышның башында мәшһүр Шиһабетдин Мәрҗани тора. Аңа ияреп, Һади Атласи, Гайнетдин Әхмәров, Ризаэтдин Фәхретдинов, Газиз Гобәйдуллин кебек зыялыларыбыз тарихыбызны ныклап тикшерү юлына баса. Шул ук вакытта татарның дистәләгән язучы-журналистлары калкып чыга. Утыздан артык газета-журналлар барлыкка килә. Меңләгән тираж белән китаплар бастырыла.

1909 елның рәсми мәгълүматларына караганда, Казанда мөселман телләрендә 8062000 бит тәшкил иткән 449 исемдәге 3115 данә китап бастырыла. 1912 елда Россиядә барлыгы 361 татар китабы чыгып, аның 69 проценты Казанга туры килә. 1913 елны Россиядә татар телендә 340 китап бастырыла. Шул ук вакытта әрмән телендә – 257, грузинча – 228 , украинча – 228 , чуашча – 56, казахча – 40, үзбәкчә – 37, белорус телендә нибары 2 китап дөнья күрә. Татарлар бу елларда Россиянең иң укымышлы халкына әверелә. 1908 елда Идел буеның рус булмаган мәктәпләр инспекторы Я.Д. Коблов болай дип язган: «Россиянең көнчыгыш өлешендә яшәгән халыклар арасында мөселман-татарлар беренче урында тора. Аларның укымышлыларының проценты, хәтта руслар белән чагыштырганда да бик зур. Татар, чыгышы белән кайсы класстан булуына да карамастан, диненең башлангычын һәм үз телендә укый-яза белә. Укымышлылыкның сәбәбе – аларның һәрбер, хәтта кечкенә авылларында да мәктәпләре булу. Аларда белем бирү белән юк кына бәягә, хәтта бөтенләй бушлай муллалар шөгыльләнә».

Халык китапка тартыла, күп җирдә китапханәләр барлыкка килә. Аларда укучыларның саны арта. Мондый гаҗәеп күренеш тик татарларда гына була.

Махсус рәвештә Тукай феноменына басым ясау урынлы. Тукай, аның иҗаты нindидер вакыт кысаларына гына сыймый. Ул мәңгелек, халкыбызга көч, куәт, дәрт һәм дәрман биреп тора. Тукаебыз – безгә тарих тарафыннан татарлыгыбызны саклау өчен бирелгән ядкәр. Аңа милли хис белән сугарылган талант иңдерелгән. Ул үзенең кыска гына гомерен милләтенә хезмәт итүгә багышлаган.

Беренче рус революциясе йогынтысында, ул инде җиңелгән булуына да карамастан, халыклар революцион эшчәнлекләрен дәвам итә. Эсерлар һәм социал-демократлар үз эшләрен туктатмый. Әрмәннәрнең «Дашнакцутюн», яһүдләрнең сионистик партияләре шулай ук хәрәкәттә була. Татарлар шулай ук үз партияләрен булдырырга тырыша. 1913 елда Киевта мөселман студентларының социалистик оешмасын барлыкка китерүчеләрнең берсе Галимҗан Ибраһимов 1914 елда җиң сызганып, милли партия төзү эшен башлый.

Халкыбызның тарихи хәтере, милли горурлыгы уяна, ул үзенең үткәнен барлый башлый. Ул 1552 елда башланган, Габделбарый Баттал сүзләре белән әйткәндә, урыс җәһәннәменнән, мескенлектән чыга башлый. Аны милли хисләр биләп ала. Ул гүреннән торып, өстеннән кабер туфрагын кагып төшерә һәм горур рәвештә яңә тарих мәйданына чыга.

Татар уянуга берничә генә мисал. 1911 елда Чиләбе шәһәренең мөселман китапханәсенең 13767 укучысы булган. Аларның кулларына 4435 китап бирелгән. Шуларның 2386 сы – татар, ә 2982 се рус телендә булган. Китапханә 905 данә газета-журнал алдырган.

Троицк шәһәрендәге «Нәҗәт» китапханәсенең шул ук 1911 елда 19432 укучысы булган. Казан, Уфа, Мәскәү, Петербург кебек зур шәһәрләрендәге китапханәләрдә дә укучыларның саны арта барган. Һәммә җирдә диярлек хатын-кызлар, балалар өчен мөмкинлекләр тудырыла. 1911 елның 9 (22) декабрендә Казанның Шәрык клубында мөселман хатын-кызлары өчен махсус бүлек ачылып, анда алар өчен газета-журналлар, китаплар уку мөмкинлеге булдырыла. Казанда «Балалар күңеле» исемле журнал чыгару планлаштырыла. Халык соравын истә тотып, Казан нәшриятлары Пушкин, Лермонтов, Тургенев, Куприн, Андреев кебек рус классикларының әсәрләрен татар телендә бастыра.

1916 елда Уфада Закир әл-Кадыйри халык университетының мөселман бүлегендә хатын-кыз хокукларына багышланган лекцияләрен башлый. «Мәгариф» типографиясе Тукай әсәрләре җыентыгын, «Сабах» типографиясе Ф.Сәйфинең татар теле буенча 2-3 дәреслеген чыгара, «Гасыр» нәшриятында хикәяләр һәм шигырьләр «Альманах»ы, «Йорт хуҗалыгы», «Художественный альбом», Г.Исхакыйның «Остабикә»се, Гыйффәт туташның шигырьләр җыентыгы, «Зәкия», Мустаевның «Сугышның максаты һәм сәбәпләре» исемле хикәясе басылып чыга. Шушы елларда Гаяз Исхакыйның «Өч хатын белән яшәү» пьесасы рус теленә тәрҗемә ителә. Аны «Знание» нәшрияты бастыра. Ул Казан, Уфа сәхнәләрендә уйнала. Татар тормышына битараф булмаган Максим Горький нәшриятка язган хатында Исхакыйның башка әсәрләре дә рус телендә дөнья күрсен иде, дигән фикер белдерә...

Россиянең татарлар яшәгән башка шәһәрләрендә дә шундый ук активлык хөкем сөрә. Россиянең 11 губернасында «Мәгариф лигасы» барлыкка килә. Аның 100 кешедән торган төп комитеты Петербургта урнашкан була.

Татар мәгарифенең үсешенә 1906 елда Түбән Новгород шәһәрендә үткән мөселман съездының әһәмияте зур була. Анда мәгариф үсешенә карата 33 пункттан торган карар кабул ителә. Аларның беренче ике пунктында барлык татар авылларында – башлангыч, ә кайберләрендә ике класслы мәктәпләр ачу теләге белдерелгән. 3 нче пунктында аларның барысында да укыту гарәп графикасында һәм татар телендә алып барылырга тиешлеге күрсәтелгән. Мәктәпләр белән идарә итү мөселманнарның үзләре сайлаган дирекция карамагында булуы теләге белдерелгән. Карарның 19 һәм 21 нче пунктларында шәһәр мәктәпләрендәге гимназияләрдә мөселман балалары өчен пансионнар оештырып, укучыларга дин белемен һәм әдәби татар телен иркен кулланырдай итеп бирү мөмкинлеген булдыру каралган. Анда укытуларын рус телендә алып баручы «Учительский школа»ларда аларны тәмамлаучыларга дин һәм туган телләрен үзләре укытырдый дәрәҗәдә үзләштерергә тиешлегенә басым ясалган. Шунысы игътибарга лаек, шушы карарны тормышка ашыруны дәүләт һәм земстволар финансларга тиеш була.

Әлбәттә, хөкүмәт бу карарга каршы чыга, кайбер земстволар гына нindидер йомшаклык күрсәтә. Шундыйларның берсе – Уфа губерна земствосы. Ул 1911 елның 23 маенда Думаның мөселман фракциясенең кайбер күренекле әгъзалары, җәмәгать эшлеклеләре, педагоглар һәм Халык Мәгарифе министрлыгы вәкилләре катнашында рус булмаган халыкларга белем бирү мәсьәләсен тикшерүгә багышланган киңәшмә үткәрә. Аның карарларында башлангыч мөселман мәктәбен тәмамлаучылар русча укый-яза белергә тиеш, диелә. Мөселманнар өчен укытельский семинарияләр булдыру ихтыяҗы барлыгы күрсәтелә. Аларда туган һәм рус телләрен укыту бер дәрәҗәдә булырга тиешлеге ассызыклана.

1912 елның 10-11 гыйнвар көннәрендә Казанда өяздәге татар мәгарифе мәсьәләсе карала. Өязнең халык училищелары инспекторы Коблов үзенең докладында, моңа кадәр татарлар һәрбер авылның мәчете каршындагы мәктәп-мәдрәсәләргә канәгать булып яшәгән булса, хәзер исә аларга дөньяви белем бирә торган рус-татар училищелары кирәк, ди. Ләкин бу училищеларда татарча укыту һәм татар телендә журнал чыгару кирәклеге шарт итеп куела.

(Дәвамы 5 нче биттә).

Җидегән вакыйгалар хәбәрләр яңалыклар

БИРИМ ДИГӘН КОЛЫНА...

Сүзләрдән гамәлгә (теориядән практикага) күчү бервакытта да җиңел бирелми. Милләткә йөкләнгән тәкъдири миссия турында сүз барганда, әлбәттә, эшләр башкачарак тора, чөнки ул Хак Тәгалә ихтыяры белән ныгытылган. Адәми зат исә, Аллаһның колы буларак, аны җиренә җиткереп үтәргә генә бурычлы. Шуның белән бергә, ислам диненең тәүхиди-иҗтиһади асылы Аллаһ тәкъдирен гамәлгә ашыруда кешегә аның рациональ (отышлы) юлларын сайлау иреге бирә, аны төгәл үтәү җаваплылыгы йөкли һәм иҗтиһат кылырга да рухландыра. Сүз уңаенда, «Аллаһның Үзе теләгәненә биргән юмартлыгы» һәм хәерхаһлыгы, татарның милләт буларак Урталык җирләрендә формалашуында гына түгел, аның бөтен дөнья буйлап сибелеп яшәвендә дә күренә. Ә инде борынгы бабаларыбызның ирекле рәвештә ислам динен кабул итүе рухи омтылышта алар холкына, илаһиятның тәүхиди асылын танудан тыш, туры юлны сайлау вә иҗтиһат иреге дә хас булуын күрсәтә. Хәлбуки, Җәнабе Хакның юмартлыгы һәм мәрхәмәте Үзе теләгәненә бүген дә зурдан. Татар күңелендә аны тоемлау исә «Бирим дигән колына чыгарып куяр юлына» дигән мәкаль шәкелендә чагылыш тапкан һәм бөтен язмышы дәвамында озата килгән.

Әлбәттә, югарыда телгә алынган факторлар һәммәсе дә Күкләр ихтыяры белән тудырылган тарихи шартларда формалашкан һәм татарга йөкләнгән илаһи миссияне үтәү өчен бүген инде зарури механизмнар булдыруга да хезмәт итә. Әмма җәмгыятьтә әлегә иблис гамәлләре өстенлек итүен дә онытмыйк. Димәк, әүвәл алардан арынырга туры киләчәк. Ә бу инде рухи һәм сәяси көрәштә, югарырак баскычка күтәрелеп, метасәясәт (илаһият кануннары буенча яшәүгә күчү сәясәте) дәрәҗәсендә эш итү зарурлыгын аңлата. Геосәясәттә диннәр сәясәт коралы итеп тә кулланылса, метасәясәт инде, киресенчә, иблис йогынтысыннан арыну һәм илаһи яшәешкә күчүдә сәяси ысул вә алымнар кулланып эш итүне күздә тота. Бу яктан, бүгенге глобаль кризис шартларында илдәге барлык диннәр һәм милләтләр арасында гармонияле яшәешкә күчүне максат иткән һәм аларның алдынгы өлешен берләштергән «Рухи вә милли бердәмлек хәрәкәте»н гамәлгә кую идеясе тагы да актуальрәк яңгырый. Моның өчен уртак максат тирәсендә берләшүгә илаһи вә җәмгыяви ихтыяҗ хәзер зур һәм төрле яктан күпкырлы мөмкинлекләр дә җитәрлек.

Гомумән алганда, Җирдә илаһият кануннары буенча яшәүгә күчү сәясәте милли, дини һәм гомумкешелек аспектларын колачлый. Халкыбызның фидакяр улы Рашат Сафин моннан дистә еллап элек аның формуласын «Татар язмышы – ислам язмышы, ислам язмышы – кешелек язмышы» шәкелендә тәкъдим иткән иде. Миңа калса, бүген инде ул цивилизацияләр бәрелеше чорының глобаль чишелеше формуласы да була алыдыр. Әйе, чыннан да, татар язмышы ислам язмышы белән тыгыз бәйләнгән һәм, киресенчә, ислам язмышы да татар факторы белән тәкъдири бәйләнештә. Биредә шуны да искәртеп үтик, Аллаһ тарафыннан яралтылганга күрә, милләт (кавем) - беренчел, ә диннәр, Хак Тәгаләгә якынаю юллары буларак - икенчел. Шуңа күрә һәр кавем Аллаһка юлны, ирекле рәвештә, үзе сайлый. Әлбәттә, тарихта диннәрне көчләп тагу очраклары да бар. Әмма адәми затның Аллаһка кайту юлында ислам дине аны соңгы баскычка күтәрү (рәсүли аңга ирештерү) өчен иңдерелүен, илаһият кануннары исә барлык кавемнәр вә диннәр өчен уртак булуын да истә тотсак, цивилизацияләр һәм диннәр арасында гармониягә ирешү өчен аларның үзара якынаерга тиешлеге дә тәкъдирдән булуы аңлашыла. Татар миссиясе - боларның һәммәсен дә аңлау һәм аңлатуда, ул гына түгел, илаһият кануннары буенча яшәүгә күчүдә үрнәк һәм әйдәп баручы көч тә булуда. Димәк, бу җәһәттән тәкъдири җаваплылык, мөселман өммәтендәге татарлар белән бергә, керәшен кардәшләребезгә дә төшә.

Иң мөһиме – һәр татар кешесенең, кайда яшәвенә һәм нинди вазифада булуына карамастан, милләт, дин һәм ил язмышы белән бергә, кешелек дөньясының киләчәге өчен дә тәкъдири җаваплылыкны үзенең йөрәге вә бөтен булмышы белән тоюы, ул гына түгел, моны акылы белән дә аңлап һәм изге гамәлләр кылып (лаеклы булып), милләт миссиясен үтәүгә үз өлешен кертүе, үзе өчен моны яшәү рәвеше дә итүе.

Фоат УРАЗАЙ.

Җыенга әзерлек

Уфада Бөтендөнья татар конгрессының VIII съездына делегатлар сайлау буенча киңәшмә узды. Чарада Татарстан Премьер-министры урынбасары,Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразиев, Бөтендөнья татар конгрессының Башкортстандагы вәкиле Альфред Дәүләтшин һәм Башкортстан Республикасының татар иҗтимагый оешмалары вәкилләре катнашты.

Милли Шураның 16 мартта үткән утырышында Бөтендөнья татар конгрессының VIII съездына һәм конгрессның 30 еллыгына багышланган бәйрәм чараларын 30 июль – 3 август көннәрендә уздыру турында карар кабул ителгән иде. Төбәкләрдәге татар иҗтимагый оешмалары апрель ахырына кадәр делегатлар сайларга тиеш.

Уфада узган киңәшмәдә Башкортстаннан барлыгы 90 делегат сайланды. Моңа кадәр, барлык җитәкчеләр бертавыштан Васил Шәйхразиевны съездга Башкортстаннан делегат итеп күрсәтү турында карар кабул итте. Съездда катнашу өчен Милли Шура рәисенә Башкортстаннан шәрәфле кунаклар исемлеге дә тәкъдим ителде. Алар арасында танылган мәдәният һәм сәнгать әһелләре, фән эшлеклеләре бар.

Васил Шәйхразиев соңгы елларда Башкортстанга конгресс җитәкчеләренең еш килүе, табигый булуын искәртте, чөнки Татарстан һәм Башкортстан татарлары халкыбызның умыртка баганасын тәшкил итә, диде ул.

Киңәшмәнең бүләкләү өлешендә татар милли мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертүче милләттәшләребезгә Татарстанның «Фидакяр хезмәт өчен» медале, Бөтендөнья татар конгрессының «Татар милләтенә күрсәткән олы хезмәтләр өчен» медале, Татарстан Президентының Рәхмәте тапшырылды.

Казанда шәҗәрә фестивале

Казанның «Мәскәү» мәдәни үзәгендә «Гаилә тарихында гасырлар кайтавазы – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә конкурсының зона этабы узды. Анда алты гаилә катнашты: Эльвира һәм Тимур Славиннар, Гөлмирә һәм Антон Дыкиннар, Ләйсән һәм Илдар Мөхәммәтшиннар, Айгөл һәм Салават Табаевлар, Светлана Мөхәррәмова, Ләйлә һәм Нияз Фасыйховлар.

«Һәр кеше тормышында буыннар хәтере бик мөһим. Нәселебезнең никадәр көчле булуын белгәч, бөтен халыкның һәм безнең белән яшәүче кешеләрнең никадәр көчле булуын беләчәкбез», – дип билгеләп үтте Татарстанның Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе Гөлнара Габдрахманова.

Конкурсның беренче этабында үз нәселең турында сөйләргә, шәҗәрә агачыңны тәкъдим итәргә, гаилә тарихындагы әһәмиятле вакыйгаларны һәм кешеләрне ассызыкларга, буыннан-буынга тапшырыла торган төп традицияләрне билгеләп үтәргә кирәк иде. Моннан тыш, катнашучылар үз гаиләләрендә пешерелә торган милли ризыклар тәкъдим иттеләр һәм ни өчен нәкъ менә бу сыйларның визит карточкасы булуын сөйләделәр.

«Без конкурста балалар үз гаиләләренең тарихын белсеннәр, үз тамырларын онытмасыннар, ата-бабалары хәтерен сакласыннар өчен катнашырга булдык, – дип сөйләде Тимур Славинның әнисе Әдилә Гомәрова. – Безнең гаиләнең төп традициясе – төрле илләрдә яшәүче барлык туганнар арасында дәвамчанлыкны һәм дуслыкны саклау». Гаилә үз башлангычын Рязань өлкәсеннән, Татарстанның Тәтеш районыннан, шулай ук Украинадан ала. Хәзерге вакытта Славиннар гаиләсендә 70 тән артык кеше исәпләнә. Аларның туганнары Россиянең төрле почмакларында – Мәскәү, Санкт-Петербург, Йошкар-Ола, Чиләбедә, шулай ук Франция, Германия, Үзбәкстан һәм башка илләрдә яши.

Конкурсның икенче этабында катнашучылар гаиләләренә багышланган иҗади номерлар күрсәтте, концерт номерлары белән чыгыш ясады һәм үз шәҗәрәләрен тәкъдим итте.

Конкурс сынаулары йомгаклары буенча беренче урынны Казанның Вахитов районыннан Гөлмирә һәм Антон Дыкиннар алды. Нәкъ менә алар Казанны конкурсның республика этабы финалында тәкъдим итәчәк.

Казан Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Булат Алеев бәйге кысаларында быел бриллиант туйларын билгеләп үтүче гаиләне һәм алтын туйларын билгеләп үтүче парларны да котлады.

«Гаилә тарихында гасырлар кайтавазы – Тарихта без эзлебез» фестиваленең финалы 15 майда узачак.

Тукай көненә уртак проект

Фешин исемендәге Казан Сынлы сәнгать училищесы һәм Казан театр училищесы студентлары «Туган як моңнары» дип аталган уртак проект әзерли. Мәдәни чара 26 апрельгә билгеләнгән.

Казан сәнгать училищесының Күргәзмәләр залында төрле белгечлек студентларының диплом һәм курс эшләре тәкъдим ителгән. Биредә тамашачы майлы буяу рәсемнәр һәм график эшләр, керамика, күн мозаикасы, металлны сәнгатьле эшкәртү кебек төрле техникаларда эшләнгән декоратив-гамәли сәнгать эшләнмәләрен күрә ала.

Экспозиция тамашачыны татар мәдәниятендә урнашкан традицияләр һәм гореф-гадәтләр, яшь рәссамнар белән таныштырачак.

Казан театр училищесы студентлары Габдулла Тукай, Дәрдеменд шигырьләреннән һәм Габдрахман Әпсәләмов прозасыннан «И мөкатдәс моңлы сазым» шигъри-музыкаль композиция әзерли.

Чара Россия халыкларының милли телен һәм мәдәни мирасын саклау елын үткәрү кысаларында уза.

1 нче биттә – «Созвездие-Йолдызлык» фестиваленең суперфинал концертыннан күренеш. **Салават Камалетдинов** фотосы. «Татар-информ».

Тәмле телле «Аллаһ баласы»



Театрларда режиссерлар спектакльнең тышкы сурәте белән мавыгып, тел һаман игътибардан читтә кала бирә. Әмма Казанда бер-бер артлы матур телле ике спектакль сәхнәләштерелде.

Аның берсе – К.Тинчурин театрында Илгиз Зәйниев үзе язган һәм сәхнәгә куйган «Мәдинә» булса, тагын берсе – «Әкият» татар дәүләт курчак театрында сәхнәләштерелгән «Дитя Аллаха» спектакле.

Бүген SMS-телефон хатлары теле, «споки», «чмоки» ише ямьсез кыскартулар шундый туйдырды ки, шагыйрь әсәрен йотлыгып тыңлыйсың. Әмма матур сүз дә әйтә белсәң генә матур. «Әкият» театры актерлары Илсур Минкеев, Ирина Гайнуллина, Эдгар Гайнуллин, Айвар Гыймаев, Татарстанның атказанган артистлары Сергей Кузнецов һәм Дилүс Хуҗиәхмәтов әсәрне җиренә җиткереп башкара.

Шагыйрь Николай Гумилев бу пьесаны 1916 елда Санкт-Петербургтагы марионеткалар театры өчен махсус язган була. Әмма Беренче бөтендөнья сугышы аркасында әсәр сәхнәләштерелми кала. Аны 1922 елда Берлинда беренче тапкыр сәхнәгә куялар. Ул вакытта рус шагыйренең әсәре алманнарны нәрсәсе белән әсир иткән? Бүген белорус режиссеры Олег Жюгжда ни өчен «Дитя Аллаха»га әйләнеп кайткан? Әсәр «Мең дә бер кичә» әкиятләрен хәтерләтә. Вакыйгалар Багдадта һәм аның тирәсендә бара. Дәрвиш, хәлиф, казый, бәдәвиләр, моңлы шагыйрь һәм гүзәл кызлар турындагы гарәп әкиятенә кайсы режиссер битараф калыр икән? Үз ярыңны эзләп табу, мәхәббәт темасы һәммә иҗат кешесенең күңелен җилкендерә, билгеле. О.Жюгжда спектакльне озак еллар күңелендә йөрткән. Тормыш-чынбарлыкка һәр бөртегенә кадәр охшаган Шәрык декорацияләре ясап кабатланасы килмәгән. Шуңа күрә ул Минскидан күптәнге иҗатташ дусты рәссам Людмила Скитовичка мөрәҗәгать иткән. Нәтиҗәдә, Шәрык әкияте турында кысмыр сәхнә бизәлешле спектакль килеп чыккан. Әмма иң кызыгы шунда, кысмыр булса да, рәссам ханым Шәрык экзотикасын матур чагылдыра алган. Сәхнәдә никадәр курчак күрәсең! Әмма ике су тамчысы кебек бер-берсенә охшаган ник ике курчак булсын?! Күчмә гарәпләр – бәдәвиләр, мәсәлән, бер-берсеннән аерылмый да югыйсә: бөтенесе актан киенгән, йөзләре сакал-мыеклы. Әмма Скитович курчакларының һәркайсының үз холкы булуы шаккатыра. Курчак театрының төрле чаралары – шәүлә театры, битлек, курчак файдалануы, артистлар үзләре курчаксыз гына да берәр геройны гәүдәләндерүе спектакльне баеткан. Сәхнә рәссамнарына әллә нәрсәләр уйлап табып, тамашачыны шаккатырырга тырышасы да түгел. «Дитя Аллаха» спектаклендә, әнә, гади генә чаралар, саран төсләр белән бер сәгать буе тамашачының игътибарын тотып торырлык тулы канлы картиналар барлыкка китергәннәр. Белоруссиядән Павел Кондрусевичның музыкасы Шәрык авазлары белән шыплап тулмаган, бик нечкә, нәзакәтле, тансык кына итеп Көнчыгыш моңын ирештерә. Бәдәвиләрне әйләндереп биетүче – Пермьнән Ирина Ткаченко. Дөя, бер мөгезле ат, тавис кошлар, жираф, фәрештәләр... ниләр генә юк сәхнәдә! Олысы, кечесе ярап карарлык тамаша.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Анкарада фотограф милләттәшебез

Төркия башкаласында яшәүче милләттәшебез, фоторәссам Мәсут Арсланбәкнең фотографияләре Анкарада Чикләүләрсез фотосурәт җәмгыяте (ENFOD) күргәзмәсендә тәкъдим ителә.

«Портрет остаханәсе» дип аталган күргәзмәдә барлыгы җиде фотографның портрет жанрындагы фотографияләре урнаштырылган.

Мәсут Арсланбәк 1956 елда Анкарада Япониядән күченгән татар гаиләсендә дөньяга килгән. Инглиз филологиясе бүлеген тәмамлаган. Озак еллар Төркия Бөек Милләт Мәҗлесе (парламент) тышкы эшләр департаментында тәрҗемәче булып эшләгән. Шул чакта ук фотосурәткә төшерү белән мавыккан.

«Лаеклы ялга чыккач фотография сәнгате белән ныклап шөгыльләнә башладым. Күбрәк аклы-каралы фотографияләр төшерергә яратам. Соңгы 15-16 елда пейзаж һәм портрет жанрларында эшлим. Чикләүләрсез фотосурәт җәмгыяте миңа камилләшү өчен бөтен мөмкинлекләрне бирә», – ди Мәсут Арсланбәк.

Чикләүләрсез фотосурәт җәмгыяте (ENFOD) рәсми рәвештә 2017 елда корылган, әмма ул 2000 елдан бирле эшчәнлек алып бара. Максаты – фотография ярдәмендә сәламәтлеге чикле кешеләр турында хәбәрдарлыкны арттыру, аларны да фотосурәт сәнгатенә тартып, җәмгыятьтә сәламәт кешеләр белән бертигез кабул күрелүләрен тәэмин итү, социальләшү мөмкинлекләрен арттыру.

Нисаб күләме үзгәрде

Татарстан мөфтияте рамазан ае алдыннан Голәмалар шурасы һәм Казыйлар шурасы карары белән билгеләнгән зәкят һәм фитыр сәдакасы нисабы күләменең үзгәрүе турында хәбәр итә. Үзгәрешләр хәзерге вакытта алтын һәм көмеш бәясенең тотрыксыз булуы белән бәйле.

Шулай итеп, 2022 елның 15 мартына фитыр сәдакасы түләү өчен 58 000 сум һәм зәкят түләү өчен 620 000 сум күләмендә билгеләнгән нисаб күләмнәре актуальлеген югалтты.

Килеп туган вәзгыятькә бәйле рәвештә, Татарстан мөфтияте рәсми сайт аша нисабларның яңа күләме турында үзгәргән саен хәбәр итәчәк. Мөселманнар өчен мәҗбүри түләүләрне түләр алдыннан сайтта бирелгән нисабның актуаль күрсәткечләренә игътибар итәргә яки мөстәкыйль рәвештә нисаб күләмен исәпләп чыгарырга киңәш итәбез.

2022 елның 19 апреленә фитыр сәдакасы түләү өчен нисаб күләме – 38 675 сум, зәкят чыгару өчен нисаб күләме – 426 275 сум.

Фитыр сәдакасы һәм фидия күләмнәре үзгәрешсез кала.

«Гөлләр» чәчәк ата

Казанның иң өлкән татар халык ансамбле 60 еллык юбилеен билгеләп үтте. «Гөлләр» коллективы Казандагы күп кенә милли-мәдәни чараларда, бәйрәмнәрдә чыгыш ясый. Аның репертуары татар фольклор, классик, эстрада җырларыннан һәм халык уен коралларында башкарылган әсәрләрдән тора. Ансамбль юбилей уңаеннан Сәетгалиев исемендәге мәдәният сараенда «Яшәү яме» дип аталган концерт тәкъдим итте.

Моннан 60 ел элек коллективны Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, баянчы Рәис Сафиуллин оештырган булса, аның эшен 2004 елдан Альберт Шакиров дәвам итә.

Ансамбльне түгәрәк дата белән Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин тәбрикләде. Ул ансамбльнең эшчәнлегенә югары бәя биреп, аның җитәкчесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, композитор, автор-башкаручы Альберт Шакировны Мәдәният министрлыгының «Рәхмәт хаты» һәм «Мәдәнияттәге казанышлар өчен» күкрәк билгесе белән бүләкләде.

Дамир Натфуллинның әнисе – Әлфия ханым да «Гөлләр» ансамбле эшчәнлегендә катнаша икән. Министр урынбасары әнисен дә истәлекле бәйрәм белән котлап, чәчәк бәйләме бүләк итте.

Юбилярларны Казан хакимиятенең Мәдәният идарәсе җитәкчесе урынбасары Эмиль Мостафин, Татарстанның мәдәният өлкәсендә инновацияләр кертү һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге директоры урынбасары Эльвина Якупова котлады.

Юбилей концертына коллективка яңа сәхнә киемнәре тектергәннәр. Концерт программасының сценариен шушы коллективта 46 ел эшләгән Гөлшат Гарифуллина төзегән. «1976 елда Казанның оптика-механика заводында эшләгәндә килгән идем. Шушы елларда Татарстанда гына түгел, бөтенсоюз һәм халыкара дәрәҗәсендә татар моңнарын яңгыраттык, күп кенә фестивальләрдә катнаштык, беренче урыннарны яуладык. Коллективта бүген 50 гә якын кеше исәпләнә. Безнең юлны дәвам итүчеләр булыр дип ышанабыз, яшьләр белән дә эшлибез», – дип сөйләде Гөлшат ханым. Концертта аның шигыренә Альберт Шакиров иҗат иткән «Яшә Тукай безнең күңелләрдә» җыры да яңгырады.

● Таиланд башкаласы Бангкок иң озын исемле шәһәр буларак Гиннессның рекордлар китабына кертелгән, ул без телне сындырмасын өчен генә кыскартып әйтелә, тулысынча исә болай яңгырый: Крунгтеп Маха Накорн Амон Раттанакосин Маханиндра Аюттая Махадилок Поп Нопрарат Ратчатани Буриром Удомратнивет Махасатан Амонпиман Аватансатип Сапкакатия Висануккампасит.

● Испан Пабло Пикассоның тулы исеме менә мондый: Пабло Диего Хозе Франциско де Паула Хуан Непомукено Криспин Криспиано де ла Сантисима Тринидад Руиз Пикассо – барлыгы 93 хәрефле.

● Дөньяда иң популяр хатын-кыз исеме – Анна (100 миллион), ирләр исемнәре арасында беренче урында Мөхәммәд тора.

● Тарихта иң танылган полиглот – Италия кардиналы Джузеппе Меццофанти (1744-1849), ул 100 тел белгән. Сөйләшкәндә, бер телдән икенчесенә (мәсәлән, кытайчадан гарәпчәгә, инглизчәдән төрекчәгә h.б.) бик җиңел күчкән. Аның белән Александр Суворов һәм Николай Гоголь дә очрашкан. Әлбәттә инде, кардинал алар белән русча сөйләшкән.

Без уяндык Рәсәйдә, таң белән...

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Татарлар өчен бу елларда театр да зур әһәмияткә ия. Чөнки татар театрының, гомумән мәгарифебезнең болгар чорыннан ук башланган тирән тамырлары була. Галимнәр раславынча, театр инде Идел Болгарстанында ук туа. Ул фольклор, төрле уеннар һәм спорт ярышлары белән баетыла һәм Сабантуйлар вакытында якты чагылыш таба торган булган.

1907 елны Казанда «Музыкаль җәмгыять» барлыкка килә. Концерт сәхнәләрендә татар һәм башкорт моңнары яңгырый башлый. Татар милли музыкасының шедеврлары булган «Тәфтиләү», «Озын су», «Мөхәммәдия», «Ашказар» җырларын скрипач И.Козлов, җырчы Г.Трейтер башкара. Әдәби музыкаль кичәләрдә еш кына скрипач Гали Зайпинның, Заһид Хәбибуллинның кыллы оркестры, Камил Мотыйгулин, Исмәгыйль Галиәкбәров һ.б. җырчыларның тавышлары яңгырый. 1909 елның февралендә Камил Мотыйгый-Төхвәтуллин үзенең баритон тавышы белән Петербургта гастрольләрдә татар җырларын башкарып, тамашачыларны таң калдыра, аны кайнар алкышларга күмәләр. Аны 4 мартта Саратовтагы көнчыгыш музыкасы кичәсендә дә кайнар алкышлар белән кабул итәләр.

28 октябрьдә Мөхтәр Мутин Чиләбедә ике бүлектән торган чыгышын тәкъдим итә. Шуннан соң «Әдәбият ахшамы» дип исемләнгән әдәби кичә үтә. Икенче көнне Мутин инде Семипалатинскида. Анда ул Г.Латыйпов белән бергә шәһәр җәмәгатьчелегенә үз концертларын тәкъдим итә... Шуннан соң алар Троицкида. Мондагы концертларын газета болай дип бәяли: «Троицк мөселманнары өчен бу бик зур вакыйга, чөнки бу шәһәрдә беренче мәртәбә профессионал мөселман артистларының чыгышы иде. Шунлыктан публика аларны зур күтәренкелек белән каршы алды һәм шулай ук озатты да», – диелә «В мире мусульманства» газетасында.

«Галия» мәдрәсәсендә Варшава консерваториясе профессоры В.Клеменц җитәкчелегендә оркестр оеша. Анда Г.Ибраһимов инициативасы белән «Милли моңнар, сәхнә һәм әдәбият түгәрәге» эшли башлый.

Земстволар, татарларга рус йогынтысын арттыру максатыннан чыгып, рус-татар училищелары ача башлыйлар. 1911 елның декабрендә татар укучыларының саны 160 кешегә җиткән Стәрлетамак өязенең Мәләвез шәһәрендә земство тарафыннан татар хатын-кызлары өчен рус-татар училищесы ачыла. Земство Богырыслан шәһәренең 5 нче мөселман мәктәбендә рус теле дәресләрен кертергә карар кыла. Укытучылар өчен елына 300 сум хезмәт хакы билгеләнә. Орск шәһәрендә Хәкимҗан Рәхмәтуллин тарафыннан 100 кешелек татар кызлары мәктәбе эшли башлый.

Петербургта шулай ук шәхси инициатива рәвешендә ир һәм кыз балалар өчен мәктәп ачу планлаштырыла. Иркутскида җирле хәйрия җәмгыяте мәктәп бетергән 13-20 яшьлек балалар өчен профессиональ мәктәп ачып җибәрә. Аның столяр бүлегендә 30 сум айлык хезмәт хакы белән һөнәр укытучысы билгеләнә. Балаларга рус телен укыту да карала. Инструментлар һәм башка җиһазлар сатып алу өчен 1000 сум акча бирелә.

Бәләбәй өязенең Каргалы авылында 1911 елның 1 сентябреннән шәһәр татар мәктәбе эшли башлый. Әстерхан шәһәренең «Шура-Ислами» җәмгыяте шулай ук мәктәп ачып җибәрә һәм аның каршында хатын-кызлар өчен китап һәм газета-журнал уку бинасы булдыра.

Күренекле эшмәкәр М.Рәмиев Уфа губернасының Стәрлетамак шәһәрендә зур мәдрәсә төзеп, аның эшчәнлеге өчен 1000 сумлык капитал билгели. Аның процентлары ремонт эшләрен алып бару өчен тотыла.

●1910 елда Казанга Төркиядән парламент вәкиле Хилми паша килү уңаеннан узган халык йөреше дә татарларның милли активлыгы артуын раслый.

Халкыбызның музыкаль дөньясы бөтен тулылыгы белән сабантуйлар вакытында яңгырый. «Йолдыз» газетасы 1915 елгы 19 май санында шул елдагы Сабантуй көрәштә җиңүчеләрне бүләкләүләр халык музыкантларының скрипка һәм мандолина уйнаулары белән дәвам итте, дип язган. Ләкин музыкаль сәнгать үсеше татарларда профессиональ музыкаль белем җитмәү аркасында тоткарланган. Татарның күпчелек артистлары махсус белемсез, һәвәскәр башкаручылардан гына торган. Фатыйх Әмирханның Г.Зайпинга багышланган мәкаләсендә «Әгәр дә бу татар халкының сәләтле улына чын белем бирсәң, аңардан һичшиксез менә дигән композитор чыгар иде, ул татар музыкасын тәртипкә салып, татарларга көнчыгыш рух белән баетылган опера бирә алыр иде», – дип язган. Шунлыктан музыкаль мәктәп ачу таләпләре ныклап яңгырый башлаган.

Жандарм органнары татарның рухи тормышын игътибарсыз калдырмый. 1913 елның 4 маенда Казан жандарм идарәсе Сембер, Самара, Саратов, Царицын, Әстерхан, Баку, Красноводск, Чарджоу, Мерв, Бохара, Сәмәрканд, Андиҗан, Наманган, Ташкент, Оренбург, Түбән Новгород шәһәрләрендәге хакимиятләргә шушы шәһәрләрдә Г.Кариев җитәкчелегендәге «Нур» труппасының концертлары булачагын һәм труппаның 45233 номерлы пароход белән Казаннан чыгып киткәнлеге хәбәр ителә. Шушы телеграммада «прогрессив юнәлештәге Кариев андагы җәмәгатьчелекне Казан прогрессистлары белән якынлаштырырга тырышачак» дигән борчылу белдерелә. Саратовтан алынган хәбәргә караганда, анда труппа «Новоцентральный» номерларында урнаша, Сөләйманов, Юскаев, Әбделмановлар белән очрашу уздыра. Татарларның мәдәнияте, мәгариф системасы тизлек белән үсү рус хакимиятенә һич ошамый.

1914 елның 17 сентябре көнне Казан хәрби-цензура комитеты үзенең бер белешмәсендә татарларның нәрсә уйлавын, кәефләренең ничек икәнен белү өчен аларның соңгы утыз елда иҗтимагый фикерләренең нинди шартларда үскәнлеген һәм татар интеллигенциясенең дөньяга яңа карашларының барлыкка килүенә ниләр сәбәп булганын, аларга нәрсәләр йогынты ясаганнарына күз ташлау кирәк, ди. Документ авторының сүзләренә караганда, татарлар суд, дин, мәктәп автономиясе һәм татар телен кайбер хөкүмәт органнарына кертү турында хыяллана.

Татар тормышындагы позитив үзгәрешләре Россия хөкүмәте башлыгы П.Столыпинның да күз уңында булган. Бу аның Синодның обер-прокурорына язган хатында ачык чагыла. «Христиан халкы өчен, – диелгән анда, – мөселман дөньясы белән бәрелешү дини көрәш кенә түгел, ә дәүләти, мәдәни бәрелеш. Хәтта илдә панисламистик пропаганданың көчәюе, аның уңышы махсус әһәмияткә ия». Столыпинны кечкенә генә авылларда да мәчетләр ачылу, яңа мәктәпләр барлыкка килү, әдәби әсәрләр басылу борчый, авыллар буйлап газета-журналлар таратып йөрүче ир-ат һәм хатын-кызларның арта баруы, һәммә җирдә мәдәнияткә, аңлы тормышка, үзбилгеләнүгә омтылышлары пошындыра. Алай гына да түгел, аңа татарларның православие һәм ислам арасында тибрәнүче рус булмаган халыкларга йогынтысы арта бару тынгылык бирми. Шунлыктан ул татар йогынтысына каршы аяусыз көрәш ачарга чакыра. Мондый көрәштән баш тарту гасырлар дәверендә барлыкка килгән тарихи бурычлардан баш тарту булыр иде һәм моның тискәре нәтиҗәләре санап бетергесез булыр иде, дип яза Столыпин. Һәм шушы көрәшкә хөкүмәтнең барлык мөмкинлекләрен кулланырга чакыра.

Нәтиҗәдә, озак көттермәстән, ул мөмкинлекләр хәрәкәткә килә. 28 исламчының исемлеге төзелә. 1910 елның 12-19 сентябрендә шушы көрәш чараларын билгеләү өчен «Идел буендагы татар-мөселман йогынтысына багышланган махсус киңәшмә» – «Особое совещание по выработке мер для противодействия татарско-мусульманскому влиянию в Поволжском крае» үтә. Анда дини-мәдәни төстәге татар-мөселман хәрәкәтенең дәүләткә каршы икәнлеге ассызыкланган. Теоретик яктан караганда, әлбәттә, ислам динендәге халыклар арасына христиан диненең нурларын тарату мөселманнарның рус культурасына кушылулары булыр иде дә бит. Ләкин моның бүгенге шартларда һич кенә дә мөмкин түгел, шунлыктан бу теләк берничек тә тормышка аша алмаячак, диелә. Тиешле чаралар күрелмәү аркасында пантюркист пропагандистларның зур уңышларга ирешүенә басым ясала. «Алар безнең законнар нигезендә конфессиональ рәвештә барлыкка килгән яңа методик мәктәпләр һәм мәдрәсәләр челтәрен гомумбелем бирү мәктәпләренә әверелдерде. Шуның белән алар дәүләт байлыгы булган мәктәпләрне үзләштереп, дини-мәдәни автономиягә адым ясады. Аларның бу адымнары куркыныч рәвештә үз нәтиҗәләрен бирә башлады. Анда дингә бернинди катышы булмаган арифметика, география, Төркия тарихы укытыла башлады», дип нәтиҗә чыгарыла.

«Киңәшмә» шушы рәвештәге керештән соң мондый карарлар кабул итә. Беренчедән, шушы гамәлләргә каршы көрәшү өчен рус булмаган халыкларның телләрен белердәй, алар арасына үтеп керердәй миссионерлар әзерләргә кирәк. Икенчедән, шул миссионерларны әзерли торган семинарияләрдә җирле телләрне өйрәнү мәҗбүри булырга тиеш. Өченчедән, бүгенге ике классны дини мәктәпләргә өстәп, андыйларны инородецлар яшәгән үзәкләрдә ачып, аларда укучы рус кешеләре өчен җирле халыкларның телләрен белүне мәҗбүри итәргә. Һәм ниһаять, ул җирләрдә яшәгән рус булмаган халыкларның уңайсыз шартларда булуын искә алып, аларның кулларына Божий Законны бирергә, аның исламнан өстен икәнлеген аңлатырга, аңа каршы бәхәсләр алып барырга өйрәтергә. Шушы максатка ирешү өчен, Киңәшмә ислам тарихы турында кыска язма һәм аны фаш итә торган катехезис төзергә һәм аның иң яхшы вариантлары өчен премияләр булдырырга, дигән карар кабул итә.

Татарга каршы адымнар моның белән генә чикләнми. Аны эзәрлекләүләр киң җәелдерелә. Беренчеләрдән булып Казандагы Г.Баруди мәдрәсәсе тар-мар ителә. Баруди үзе кайбер шәкертләре белән Вологда губернасына сөрелә. Вятка губернасының Сарапул өязендәге бертуган Габдулла һәм Гобәйдулла Бубиларның татар дөньясында дан тоткан мәктәпләре ябыла, үзләре кулга алына. Аларга каршы «Бубилар эше» барлыкка килә.

Уфа, Оренбург, Казан губерналарындагы татар хәрәкәтен хөкүмәт «сепаратизм», «дәүләт эчендә дәүләт» төзергә омтылу дип бәяли. 1911 елның сентябрендә аларны тикшерү өчен махсус комиссия җибәрә. Нәтиҗәдә, кайбер укытучылар, мәсәлән, Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллимнәре А.Мостафин, Ш.Шәрәфи һәм Ф.Зәбиров, Вятка губернасы Малмыж өязенең Урбар авылы ахуны Әхмәтгәрәй Садыйков кулга алына.

Шул елның 11 июлендә иң бай китапханәләренең берсе булып саналган Чиләбе мөселман китапханәсендә жандармлар тентү үткәрә һәм 1905 елда ук рөхсәт ителгән 75 татар китабын конфискацияли.

Ләкин мондый фактларның арта баруына да карамастан, татар алгарышы үсешен туктатмый. Киресенчә, ул киңәя һәм милләтебезгә дәүләтчелегебезне аякка бастыру өчен барган авыр көрәшендә көчкуәт биреп, маяк булып тора.

ЛЕНИН БЕЗГӘ ДӘШӘ

Көнчыгышка карап баскан Ленин
Кояш чыгышына караган.
Һәр таңны ул шулай каршы алыр
Үткәнне ул инде барлаган.
Карагызчы, сез дә күтәрелеп:
Өмет катыш үпкә йөзендә
Хәзер әйтеләчәк сүзләрендә
Мин зур гаеп тоям үземдә.
Әйтә кебек Ленин:
«Динсез, денсез, диеп,
Рәнҗетмәгез әни-әтине.
Изге көрәш юлын алар миңа
Аллаһ үзе кушкан өчен өйрәтте.
Минем рәсем төшкән кызыл билетларны
Яткырмагыз сандык төбендә
Чыгарыгыз кояш нурына, дөнья яктысына
Рухым минем көчле бүген дә.
Мин бит жандармнан куркып,
Подвалларда посып ятмадым.
Бөек көрәш юлын сайладым мин,
Тамак өчен җанны сатмадым».
Ленин сүзе – үзе политика
Ленин үзе – көчле сәясәт.
Бүген илдә иң куркыныч хезмәт -
Ленин юлындагы сәяхәт.
Миллиардерлар саны былтыргыдан
Дурт тапкырга арткан, күр әле!
Кырык миллион хәерче бар илдә
Бер хәерче дә борчымый һичбер түрәне.
Юк,юк,начар яшәмибез, киресенчә:
Бар да яхшы,бар да арта әнә,күр әле:
Бензин,налог,икмәк хакы арта:
Тик ул сумнар борчымый һичбер түрәне.
Коммунистлар салган биналарда
Оя корган әнә буржуа.
Депутатлар халык миен чәйни,
Чит патшалар белән кул уа.
Сез кайларда Дзержинскийның
Салкын канлы гаярь уллары?
Сез соң бүген кемгә хезмәт күрсәтәсез?
Сез соң бүген кемнең коллары?!
Шулай дәшә кебек безгә Ленин,
Фуражкасын тоткан кулына.
Кая барып, кайда яшәсәм дә,
Ленин чыгар кебек юлыма.

Бу юллар «Арча ремонт механика заводы» генераль директоры Даниял Шакир улы Фәсәхиев үзе төзеткән Ленин һәйкәлен ачуга багышланган тантанада сөйләнде. Д.Фәсәхиев чүплектәге һәйкәл калдыкларын вак ташлардан җыеп аны яңа баштан торгызды.

Нурия ХӘКИМОВА.

Тукай – безнең замандаш

Бүген татар дөньясының йөрәк тибеше булган башкалабыз Казанда Тукай хатирәләрен саклаучы изге урыннарның иң соңгысы (бигрәк тә «Болгар номерлары», җимерелгәннән соң), мөгаен, шагыйрьнең «Шамил йорты»ндагы әдәби музее гына калды.

Тукай иҗаты. Тукай дөньясы. Бу дөньяны һаман да колачлап бетерә алганыбыз юк. Һәм бу мөмкин дә түгелдер. Еллар узган саен, без Тукайны ныграк ачабыз, аның зурлыгын һәм пәйгамбәрлеген ачыграк тоябыз. Тукай безгә һәм безнең кабилияткә һаман саен ныграк якыная, без аңа үзебез дә ныграк тартылабыз. Шагыйрьнең үлемсезлеген, аның татар халкы өчен бәгырь кебек кирәк булуын, бәлки, менә шуның белән аңлатыргадыр...

Тукайның бик күп шигырьләре нәкъ менә бүгенге көннәребезгә, милли һәм сәяси вәзгыятебезгә бөтен рухы, барлык җепселләре белән туры килә. Шуңа да аның тулаем иҗаты, шигъри авазы көр яңгырый, халкыбыз күңелендә тел\u0259ктәшлек таба. Ул һаман да безнең замандаш. Алай гынамы, аның пәйгамбәрлеге публицистикасында да ачык ярылып ята. Сүзебезне раслар өчен, әйдәгез, ике генә өзекне укып китик.

«Беренчедән, бу Дума һәрбер кирәкле урында катнаша алмас, ул бер эш турында хөкем чыгару яки бер-бер мәсьәләне хәл итү өчен чакырылмый, тик бертөрле эшләр хакында үз фикерен сөйләү өчен генә чакырыла».

Икенчесе. «Фәкыйрьлек, мохтаҗлык бик авыр. Аны җиңеләйтүче юк... Бу күз яшьләренә, бу гөнаһсыз адәмнәрнең хурлыклы хәлләренә социаль төркемнәрнең булышмавы, кайгыртмавы һәм кешелексезлеге сәбәптер».

Шаккатам: бу юлларны укыганнан соң, Тукай әллә безнең заманда яши, бүгенге Думаның һәр кылган гамәлен сагалап тора микәнни, дип уйланасың...

Сизәсездер, баймы яки ярлымы ул, әлеге сүзләрдә нәкъ бүгенге көн кешеләребез (гражданнарыбыз) өчен тирән борчылу ята. Моннан 100 еллар элек язылган сүзләрдә – бүгенгенең дә ачы хакыйкате. Тукайның тәнкыйть уклары, оста мәргәннеке кебек, «мишень»нең кыл уртасына барып кадала. Бүгенге каләм әһелләре өчен көнләшерлек хәл түгелмени бу?

Табигатьнең зирәклегеме, әллә саранлыгымы – кешегә гомер дигәнең бик тә чикле, үлчәп кенә бирелгән. Ул менә шушы вакыт арасына сыярга, кешелек тарихында үзеннән билгеле бер өлеш – күңел хәзинәсен, асыл фикерләрен калдырып китәргә тиеш. Ни гаҗәп хәл: моның өчен Тукайга нибары 27 ел вакыт җиткән!

... Тукай музеена аяк басканда, күңелне иң әүвәле әнә шундый уйларның биләп алуы табигый булса кирәк.

Шагыйрьнең Казандагы музее – изге, тылсымлы йорт. Аның һәр почмагыннан безгә Тукай күзләре карап тора сыман. Каядыр якында гына шагыйрьнең аяк тавышлары да ишетелә кебек... Ни әйтсәң дә, 20 яшьлек Тукай 1907 елның 10 октябрендә Уральскидан Казанга кайтып төшә ич! Аның башкалабызда яшәгән еллары – үзе бер дәрья! Хатирәләр дәрьясы...

Музейда экспозиция һәм күргәзмә заллары эшли. Андагы байлык, олуг хәзинә һәм экспонатлар таң калырлык!

Экспонатлар туплауда гына түгел, ремонт-төзелеш һәм реставрация, биредәге интерьерны нәфисләп бизәү эшләрендә дә ифрат зур хезмәт башкарыла.

Ремонт-төзелеш димәктән, бу эшләрне дә аерым бер рәхмәт хисләре белән билгеләп үтү урынлы. Хикмәт шунда ки, әле «Шамил йорты» (ягъни патша заманындагы особняк) советлар заманында гади бер коммуналка рәвешендә яшәп яткан. Хөкүмәтебез карары белән бу бина Тукай музеена дип тәгаенләп бирелгәч, музейны оештыра башлаучылар мең квадрат биләмәсендәге тар бүлмәләрне, чоланнарны карап чыкканнан соң баштарак аптырап-югалып та кала, чөнки булачак музейны 100 еллыгына өлгертергә күрсәтмә бирелә.

Музейны оештыру, бүгенге камиллегенә җиткерү өчен аның беренче директоры Госман Әкрам улы Хәбибуллин – күп көч куйган зат. Ул – икебез бер партада утырып укыган классташым, аннары Казан университетында биш ел буе бергәләп белем эстәдек. Ул аспирантура тәмамлады, тарихчы (кызганычки, арабыздан вакытсыз китү сәбәпле, кандидатлык диссертациясен якларга өлгермәде). Очрашканда, киңәшеп утырганда, ул миңа кая нинди хатлар язылуын, дәүләт оешмаларының күп ишекләрен шакырга туры килүен, кыенлыклар, йокысыз төннәре турында зарланып түгел, дәртләнеп вә горурланып сөйли торган иде. Аның Киев, Ульяновск һ. б. шәһәрләргә сәфәр кылуы, Ленинградка барып фототукымалар юллавы – болар үзләре бер кыйсса...

Музей. Ап-ак култыксалы баскычтан күтәрелү белән Тукайның ике метр чамасы биеклектәге ап-ак сыны каршы ала. Экспозиция залларындагы күпсанлы материаллар шагыйрьнең балачагы, әти-әнисе, Кушлавыч, Кырлай, Өчиле авыллары, андагы табигать күренешләре турында сөйли. Менә «бәләкәй Апуш»ның әтисе Мөхәммәтзариф мулла үз кулы белән язган метрика кәгазе... Мулла йортындагы фрагментларны күздән кичергәндә (тәсбих, шәмаил, күмер үтүге, җиз самавыр, җиделе лампа һ.б.) ирексездән XIX гасыр татар авылы йортының бер почмагына аяк баскандай буласың...

Тукайның Уральскидагы тормышы шулай ук киң яктыртылган. Бер фотосурәткә махсус тукталып китик. Бу – шәкерт Тукайның атаклы җырчы Камил Мотыйгый белән төшкән фотосы. Әлеге рәсем күпләрдә бәхәс тудырган иде: мөгаллим, бай баласы, Европача яхшы киенгән Камил әфәнде фәкыйрь генә киенгән шәкерт белән фотога төшмәс, янәсе... Әмма үтә сизгер һәм күзәтүчән Батулла «Сәхнә» журналында (2002 ел) бу, һичшиксез, Тукай дип исбатлап чыкты. Аның исбатына икеләнмичә ышанырга мөмкин.

Тукайның соңгы көннәре... Клячкин хастаханәсендә төшерелгән 1913 елның 14 апрель тарихлы соңгы рәсем. Еллар аша Тукай фани дөнья, безнең белән дә саубуллаша. Ләкин шунысы ачык: аның үлеме – яшәүнең, халык күңеленә күчә баруның башы һәм дәвамы гына әле.

Залларның берсендә агач шүрәләләр рәте тезелешеп киткән. Рәхмәт сезгә, шүрәләләр! Сез бит Тукай әкиятеннән «сикереп» чыккансыз, аннары инде композитор Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балеты, музыкасы аша Европа илләренә генә түгел, хәтта Япониянең атаклы Фудзияма тауларына хәтле барып җиттегез. Канада урманнарын яктырттыгыз. Кызганыч, хәзер Фәрит Яруллинның үлмәс музыкасын яңгырату турында уйлаучылар юк диярлек...

Әйтергә кирәк, Җаекта, Кушлавычта һәм Кырлайда оешкан музейлар да Тукай хатирәләрен дистә еллар буе кадерләп саклый. Шунысы игътибарга лаек: эчке һәм тышкы бизәлеш-корылышы белән алар бер-берсен кабатламый.

Тукай кыска гына гомерендә яшен булып яшьнәде! Аның яшәү-яну рәвешен бары шулай гына аңлап һәм аңлатып була. Яшен бит үзенең бер ялтыравы белән күкләр галәмен колачлый ала. Шагыйрь да татар галәмендә әнә шундыйрак колачлау, яктырту сәләтенә ия булды. Ул безгә, татар халкына, Аллаһ бүләгедер. Тукай дәвам итә. Ул бүген дә безнең арабызда, йөрәкләребездә, аның шигъри авазы һаман да халык күңелендә яңгырый.

Рашат НИЗАМИ.

ШУНДЫЙ КИЧЛӘР БУЛА…

Шундый кичләр була: күкләр ава,
Ява җиргә меңәрләгән йолдыз.
Сүнәр өчен ява, тынар өчен,
Калсын өчен җирге утлар ялгыз.

Үзәгеннән сына ияләре –
Тибри җирдә сүзсез күләгәләр,
Меңәрләгән йолдыз ява күктән,
Карашларың күккә тисә әгәр.

Йолдыз көлен сибеп сукмакларга,
Вакыт тибри – шундый кичләр була.
Гомер – күмер. Гомер буйларына
Тәрәзләргә ялгыз утлар тула.

Үзәгеннән сына күләгәләр,
Ияләре җирдә, җирдә тына.
Кеше – бары кеше генәдер ул.
Күк йолдызы – бары йолдыз гына...

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА

Гомер дәвам итә.
Бер йодрыкка йомдым барысын да,
Ул ачылыр беркөн, дәһшәт кубар.
Кемнәр каерылыр? Кемнәр сынар?
Кемнәр калыр? Кемнәр ары узар?
Сез тоймысыз, ахры. Әллә тоеп,
Тоймагандай гына тоеласыз.
Кабатланыр, кайтыр, каергалар –
Һәр дәвернең шундый бер йоласы.
Уңга-сулга салулаган чакта
Сез утырган арба бүгенгедә,
Көчем җитсә иде
Таңга кадәр
Учларымны ачып өлгерергә…

СӘФӘР

Ап-ак болыт ага дөнья буйлап.
Кичектерер сәфәрләрең бармы?
Яшәсәң дә ярыйдыр ул юкса
Аямыйча бу дөньялар ярын,
Каш өстенә кулын куеп әнә
Ак яулыклы карчык басып тора.

Күккә баккан төссез күзләреннән
Вакыт үбә, көннәр тоныклана.
Кичектерер сәфәрләрең юктыр.
Күк йөзендә ап-ак болыт кала...

КИТКӘНДӘ

Тәннән җан киткәндә,
Җыр киткәндә,
Үзәгеннән шартлап үткәндә,
Бәхилләшер телең булсын икән,
Сүзең булсын икән – үткәннән.

Үзәкләрең өзелеп егылганда,
Торалмаслык булып ауганда,
Телең булсын икән, киткәннәрчә
Иман китерергә Аллаңа.

Киткәннәрчә, җирдән үткәннәрчә
Әйтеп калдырырга әйтәсең,

Әйтәсе сүзеңне онытгың аңласа, Гомерең бакыйга әйләнә...

КЕМ?

Яуга томырылган аргамакмы,
Кызыксыз бер роман өтереме,
Җир исемле олы зияратның
Дога көткән тузан бөртегеме –
Кем мин?
Кем мин үзем өчен?
Синең өчен?
Көчем җитмәс өермәгә кереп –
Җиргә килеп нәрсә үзгәрттем соң?
Нәрсә үзгәртермен монда үлеп?
Юк, үзгәрмәс кебек,
Шул ук калыр.
Сулышлары гына башка булыр.
Без атлаган сукмак йөзләрендә
Көзге җете яфрак ятып торыр
Язга кадәр.
Аннан кабат, кабат…
Кем мин –
Кояшына, салкынына карап
Түзә белгән шайтан таягымы?
Адәми зат кичерергә базган
Җирге хиссиятнең арьягымы?
Яуга томырылган аргамакмы,
Өнендәге өнсез өметләрме?
Ә Ул үзе кем дип яза икән
Җиргә иңгән безнең кебекләрне?
Кем дип тамга суга бездәйләргә
Туфрак йөзләренә тәү басуда?
Кем мин – Аңа,
үз-үземә,
сиңа?..

ДАСТАН

Әйтәсе сүземне үземчә аңласаң,
Яшәвем – бер дастан.
Ул сиңа тоташкан.
Көзләрне каршылап, алмалар баллана,
Гомерләр – моң гына тоташтан.

Алмалар аллана. Көзләрен һәр алма
Туфракка өзелеп төшәчәк.
Бу яшәү – әйләнә. Бөредән алмага
Әйләнә берзаман һәр чәчәк.
Туфракка сыенып, кояшка коенып,
Күкләргә үрелә шытымнар.
Бу яшәү – юмарт ул, һәр җанның түренә
Коярлык суты бар, коты бар.

Үзәгең нык булса, үзеңнең җиреңә
Чатырдап ябышса тамырың.
Көзләрен алмалар балланып коелыр –
Шул булыр югалтыр-табарың.

Җир һаман әйләнә,
Чор һаман әйләнә.
Дәверләр дәвергә бәйләнә.
Әйтәсе сүзеңне онытгың аңласа,
Гомерең бакыйга әйләнә.

Алмалар аллана, алмалар баллана –
Туфракка коелыр, беләсең.
Оныт ма язларның яңадан киләсен,
Дөньяга чәчкәләр эләсен…

Гомерләр итәсе, туфракка китәсе
Кайтканга өзелеп туфрактан.
Бу яшәү – борынгы бер дастан –
Асылда
Вакытның үзенә тоташкан,
Моң гына, моң гына тоташтан…

ИРТӘГӘ

Мин йодрыгым итеп йомарладым
Дәвер таңын, үткән чорлар зарын.
Җаныгызга шундый якын чагым.
Сез белмисез әле, сез белмисез
Бу йодрыкта нинди дәхшәт барын.
Сез тоймыйсыз әле уңга-сулга
Салулаган дәвер арбасында
Тәгәрмәчнең шартлап сынасын да,
Арбагызның беркөн авасын да.
Һавасына, җир-суына инде
Күкерт тәме кергән. Дәвер котә.
Җаннар тыпырчына. Тамыр тибри.
Вакыт сизри.

Киртәләрен тоймый!
Сәфәр чыккан
Ак болытка багып бии дөнья.
Башын кырып салып көзге җилгә,
Ак яулыклы карчык карап тора.

Чыгымчылый көннәр, вакыт шаша,
Зырылдатып ала көн камчысы.
Тулып таша гомер, күңеленә
Мең төчесен сала, мең ачысын.

Ачыттырып күзләреңнән үбә,
Дөнья томалана, сөрлегәсең,
Мәгәр һаман баш очында тора –
Кояш төсле тора шул бер рәсем:

Ап-ак болыт уза дөнья буйлап.
Туза төсләр, хисләр, сизгүләрең*.
Болыт куып инде йөгермәссең,
Чал җилләргә ачып изүләрең.

Вакыт чоңгылында чәбәләнеп,
Тынып калыр тиңсез аклык кына.

Үз мәкамең белән баш очында
Укысыннар өчен дә ясин,

Телең булсын, сүзең булсын икән.
Тел ачкычың булсын үзеңдә.
Вәгъдәләрең, дәгъваларың, хәтта
Син үзең дә – сөйләр сүзеңдә.

Тәннән җан киткәндә,
Җыр киткәндә,
Үзәгеңне өзеп үткәндә,
Телең калсын икән, сүзең калсын –
Сөйләсеннәр өчен иртәгә...

* * *

Җаныма мең гамьнәр тулыша,
Аннары очалар куышып –
Тоталмыйм, тоялмыйм, тыялмыйм!..
Мин кемме –
Мең гамьнәр куышы.
Мин шушы туфракта туганмын.
Мин шушы кояшка бакканмын.
Кып-кызыл кара кан минем дә
Йөрәгем түреннән аккан моң.
Ул моңнар кемнәрнең җанына
Кагылыр, кагыла, кагылган…
Мин сезгә туп-туры карыймын,
Мин сезнең күзләрдә чагылам.
Мең гамьнәр очырам җанымнан.
Очалар тулышып, куышып,
Ярканат явыдай шом салып,
Көн белән, өн белән сугышып…
Аларның кайларга җитәсен
Мин белмим. Беркем дә белмидер.
Мин бүген яшимен, сулышым
Сезнең дә тынлыкка бәрелер.
Мең гамьнәр куышы күңелем,
Тулам да,
Дөньяга түгеләм.
Мин сезнең күңелгә үреләм.
Сез мине аңлыйсыз,
Мин беләм.

---

*Сизгү – интуиция

ШАГЫЙРЬНЕҢ «БЕРДӘНБЕР

Сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның мәхәббәте темасын яктырткан мәкаләләр, яңача шәрехләүгә омтылышлы язмалар әледән-әле басылып килә. Болардан Рауль Мир-Хәйдәрев каләменнән чыкканнарны мин бигрәк тә кызыксынып укып барам.

Аерым алганда, әсәрләре күп телләргә тәрҗемә ителгән (шул исәптән, татар теленә дә), бу танылган әдип, публицист һәм җәмәгать эшлеклесенең татар һәм рус вакытлы матбугатында чыккан «Последняя любовь поэта (Неизвестные факты из жизни Габдуллы Тукая 1911-1912 годов» // «Республика Татарстан» 2018 ел, 20, 27 сент., 4 окт.), «Неизвестные факты из жизни Габдуллы Тукая. 1911-1912 гг.» («Идель», 2018 ел, 7 нче сан), «Шагыйрьнең соңгы мәхәббәте», («Идел», 2018 ел, 11 нче сан) исемле мәгълүматка гаять бай мәкаләләре белән, шулай ук интернетта урнаштырылган «Последняя любовь поэта (Неизвестные факты из жизни Г.Тукая 1911-1912 гг.)» дигән материал белән дә моннан өч-дүрт еллар элек танышып чыккан идем. Аларда Тукайның 1911-1012 елларда хәзерге Арча районындагы Күпербаш авылында булуы, Әминә исемле 18 яшьлек кызга күзе төшүе, аның белән хәтта гаилә корырга теләгәнлеге язылa, ул шагыйрьнең соңгы мәхәббәте сыйфатында шәрехләнә. 2019 елда «Идел» журналы битләрендә мин аларга үз мөнәсәбәтемне белдергән идем...

Күренә ки, Рауль Мир-Хәйдәрев Тукай һәм Әминә темасына тагын да мөрәҗәгать иткән: быелның гыйнварына кергәч, «Звезда Поволжья» газетасында ул «Единственная любовь поэта» дип исемләнгән язмасын бастыра башлады (ул барысы 10 санда чыкты, соңгы өлеше - 2-8 апрель санында). Монысында да әлеге тема үзәккә куелган, һәм, әйтергә кирәк ки, бик тәфсилле рәвештә тикшерелә. Шуңа күрә мин тагын да инде Р.Мир-Хәйдәревнең бу мәсьәләгә кагылышлы уй-фикерләренә мөнәсәбәтемне белдермичә калмамдыр.

Авторның укучылар игътибарына тәкъдим ителгән ошбу соңгы язмасының (русча) күләме элгәреләренә караганда күпкә зур кебек. Автор анда башлыча язучы-документалист, мемуарист сыйфатында чыгыш ясый. Чит җирләрдәге, бу очракта, автор үзе туып-үскән Мартук бистәсендәге (Казахстанда) татар халкы вәкилләренең яшәү-тереклек рәвешләре, аерым затларның язмышы, Татарстан, Күпербаш авылы белән бәйләнешләре турында бик җитди сүз алып бара. Мине аеруча да кызыксындырганы – әлеге дә баягы шул Күпербаш, Әминә һәм Тукай мөнәсәбәтләре, ягъни «Г.Тукайның 1911-1912 еллар тормышының билгесез сәхифәләре». Бу язмасында сүз сөреше Әминә тирәсендә әйләнә. Бу юлы да моңа төп сәбәп: әлеге дә баягы вакыйга – язучыга «Минем балачагым станциясе» («Станция моего детства») дигән әсәре текстында Мартук бистәсе дә телгә алынуын очраткан Рамил Шерлановтан (табиб-хирург, шагыйрь, Нукус шәһәрендә яши, интернеттагы библиографиясе гаять бай) хат килеп төшү (рус телендә; тулы тексты язучының мәкаләләрендә китерелә). Анда хөрмәтле Рамил әфәндебез Мартукта яшәгән әбисе Гыйльмениса Хәбибуллинаның үзенә «гаҗәеп бер тарих» («удивительная история») сөйләвен хәбәр итмәкче. Якынча 1912 елда Гыйльменисалар гаиләсе яшәгән Күпербаш авылына үпкә туберкулезы авырулы, «прилично киенгән» мәгълүм шагыйрь Габдулла Тукай (караңгы төстәге сюртуктан!) еш килеп йөргән (!) икән. Р. Шерланов язуына караганда, Күпербаш авылы старостасы вазифасын да үтәгән бабасы (бабасының атасы) Казан губернасында иң яхшы кымызга ия булган (яхшы атлар – кобылицалар тоткан). Тукайга исә яңа гына әзерләнгән кымызны аларның Әминә исемле ин өлкән (18 яшьлек) кызлары китереп бирә икән («всякий раз подавала Габдулле Тукаю чашу со свежим кумысом»). Мондый очрашулар вакытында, билгеле ки, яшьләр арасында әңгәмә дә була. Һәм алар бер-берсен ярата да башлый. Ахыр чиктә шагыйребез, кыюланып китеп, хәтта бабаебыздан Әминәсенең кулын да сорый. Әмма хуҗа – Хәбибулла Дәүләтшин (ул Р.Шерланов бабасының атасы) «неустроенный» кешегә кызын биреп җибәрергә теләми. Кинәт үзенә килеп кергән хатны укудан гаять тә шатланган Р.Мир-Хәйдәрев Әминәнең (кайда гына яшәмәсен) бу беренче мәхәббәтен гомер буе онытмавын сөйли. Әминә Тукай шигырьләрен әледән-әле алып кат-кат укый икән, гыйшкый хисләр кичергән... Тукай белән очрашулар истәлеге Әминәгә катлаулы тормыш шартларында исән калырга, 1911-1912 елларның шигърият һәм мәхәббәт белән сугарылган бәхетле ике җәен (1911 һәм 1912 еллар?) искә төшереп яшәргә, балалар үстерергә дә мөмкинлек биргән. Р. Шерлановка әбисе хәтта Тукайның Әминәгә багышланган шигыре булуын да әйткән икән (хат авторы аның исемен хәтерләми).

Мәкаләдә Р.Мир-Хәйдәрев Р.Шерланов хатындагы мәгълүматларның тәү башлап нәкъ үзенә килеп керүенә нисбәтле куаныч-шатлыгын, әйе, без кабиләдәшләр белән дә уртаклашырга теләвен яза (балачактан ук Тукай белән үзе арасында мистик бәйләнеш булганлыгын да әйтеп куя). Ул Әминә тормышында бу вакыйга чыннан да булганлыгына һич тә шикләнеп карамый, аны үзенең табышы итеп күрсәтә. Мәкаләсе дәвамында Р.Шерланов хатына чаклы ук ул Тукай белән «очрашып» торганлыгын, мәсәлән, Мәскәүдә уздырыла торган юбилейларына нисбәтле чараларда катнашлыгын искә төшерә.

1940 еллардан башлап Тукай турындагы истәлек-хатирәләрне җыйнау һәм укучылар игътибарына тапшыруга да шактый зур әһәмият ителде. 1960, 1976, 1986 елларда алар өч мәртәбә китабый басмалар (төзүчеләре – С.Исәнбай; И.Нуруллин һәм Р.Якупов) рәвешендә дөнья күрде. Шагыйрьнең тууына 130 ел тулу вакытларына аның хакында җыела килгән барлык диярлек истәлек язмалары (басылганнары да, кульязма рәвешендә генә сакланганнары да) күләмле ике томга тупланып («тулылыкка дәгъва итми»чә) тәкъдим ителүен («Тукай – ядкярләрдә», 2015-2016; төзүчеләре – Р.Исламов, Җ. Миңнуллин) дә әйтергә кирәк. Төрле чорларда, төрле иҗтимагый вәзгыятьтә һәм төрле принципларга кулланып әзерләнгән бу басмаларда Тукайның иҗади эшчәнлеге белән янәшәдә, шәхси дөньясы да, холкы-фигыле дә шактый тулы чагылыш таба. Шул исәптән, адәм балаларының фани дөньядагы яшәешен аеруча мәгънәле итә, ике җенес вәкилләрен бер-берсенә бәйли торган сөю-мәхәббәт хисләре белән Тукайның да януы турында кайбер замандашлары сөйләп калдырган фактик мәгълүматлар да. Хәер, алар әллә ни күп түгел. Укучыларны аеруча да кызыксындыра торган бу бик тә үзенчәлекле сфера башлыча аның самими дусты Ф.Әмирхан язмаларында ачыла. Шунлыктан да фәнни хезмәтләрдә, төрле мәкаләләрдә, әдәби, сәнгати әсәрләрдә авторлары Тукайның сөю-мәхәббәткә баглы интим кичерешләре турында фикер йөрткәндә бик хаклы рәвештә Ф.Әмирхан язганнарга таяналар, Чистайдан 1908 елның февралендә Казанга укырга килгән, әсәрләре вакытлы матбугат битләрендә әледән-әле басылып торган тере шагыйрьнең үзе белән танышырга омтылган Зәйтүнә Мәүлүдова белән берничә очрашу нәтиҗәсендә шагыйрь күңелендә дә туган саф, нечкә хисләр, тойгы-кичерешләр, экзерсез, җылы мөнәсәбәтләр хәзерге вакытта шагыйрьнең беренче (һәм бердәнбер мәхәббәте) рәвешендә интерпретацияләнә. Менә 114 ел дәвамында «яшәп килгән», бүген дә күңелләребезне дулкынландыра торган бу мәхәббәттән тыш шагыйрьнең икенче бер конкрет затка сөю-мәхәббәт хисләре белән янганлыгына ышанычлы дәлил булырдай башка фактлар инде табылмастай тоелган иде. Ялгышканмынмы? 2018 елда, кинәттән дип әйтимме, Р.Мир-Хәйдәрев, шагыйребезнең тагын бер (соңгы) мәхәббәте булган дигән фикерен үзәккә куеп язылган мәкаләләре белән чыгыш ясады. Быел исә бу теманы ул тагын да тәфсиллерәк стильдә шәрехләргә уйлаган. Билгеле ки, Тукай турындагы һәрбер кечкенә генә истәлекне дә без һәрвакыт аеруча да зур кызыксыну белән укыйбыз (ул Тукайны иҗатчы шәхес буларак, яңа яктан, башка истәлекләрдә күренмәгән образ-сурәтләрдә ачар шикелле каршы алына). Әмма яңа дип тәкъдим ителгән теге яки бу хәбәр-истәлек чынбарлыкта булган реаль хәлләрне, Тукай белән очрашу-сөйләшүләрне төгәл чагылдырамы соң? Мондый сорау туу гаҗәп түгелдер. Бөек Тукаебыз турында сүз бара бит. Кыскасы, бу юлы да миндә Рамил Шерланов хатында урын алган ике яшьнең очрашу факты Күпербаш авылы тарихында булдымы икән, дигән сорау туды.

Тукайның үз истәлекләреннән дә мәгълүм ки (балалык елларын санамаганда), Җаектан Казанга кайтып яши башлагач та, туган ягы – Казан арты авылларында ул ике мәртәбә булып киткән. Беренчесе – 1907 ел көзендә, октябрь аенда, гаскәри хезмәткә (солдатка - призывка) каралырга кайтканда. Ул чакта шагыйрь туган авылы Кушлавычта, шулай ук Каенсарда, Кырлайда, Югары Масрада, Иске Җөлби, Олы Әтнәдә, Олы Мәңгәрдә була (ун-уникe көн чамасы). «Мин дә менә, Казанны вә туган җирем булган Казан арты авылларын күреп, күп гыйбрәтләр вә хиссиятләр алдым», – ди ул Габдулла Кариевка 1907 елның 30 декабрендә язган хатында. Әлеге сәфәре вакытында ул шат күңелле (мондый рухи күтәренкелек аннан соңгы гомерендә (4-5 елда) еш булдымы икән әле!), кымыз эчеп дәвалану да «перспектива»да күренеп тормый. «Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!» шәһәрендә әле ныклап урнашып, үз кеше булып өлгермәгән, андагы яшь буын татар язучы-әдипләре, газетачылар, наширләре белән рәтләп танышып та, фикерләшеп тә, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Сәгыйть Рәмиевләр белән дуслашып та өлгермәгән була ул. Истәлекләрдә шагыйрь күңелен дулкынландырырлык гүзәл женес вәкилләре белән очрашу-әңгәмә коры турысында бер сүз дә юк. Хәер, Р.Мир-Хәйдәрев тә Тукайны Күпербаш авылына бу вакытларда түгел, бәлки соңрак, 1911-1912 елларда кайтып йөргән (бер генә тапкыр түгел!) итеп яза.

Икенче мәртәбә Тукайның туган ягына (авылга) кайтып тору факты аның Гыйльметдин Шәрәфкә, Әхмәт Урманчиевка адресланган хатларында, «Мич башы кыйссасы» исемле юлъязмасында, истәлекләрдә чагылыш тапкан. 1911 елның 29 сентябрендә үк салкынлыктан зарлана башлаган

МӘХӘББӘТЕ» ӘМИНӘМЕ?

Тукай, үзе язганча, «Наплевать на все», ди дә декабрь урталарында ямщик яллап, Өчиле авылына юнәлә (билгеле, кайту мәсьәләсе абыйсы (энисе Мәмдүдәнең энесе, эниләре башка) Кәшфелкәбир белән алдан сөйләшеп куелган була). Ул вакытларда Мәмдүдәнең атасы Зиннәтулла мулла Әмиров (1829-1909) инде вафат булып, нигезендә яшәп яткан улы Кәшфелкәбир хәзрәт һәм аның хатыны Рабигалар йортына ул инде бик авыру хәлдә аяк баса («Чанадан үзе төшә алмады, ирем белән без култыклап төшереп, күтәреп өйгә алып кердек. ... Берәр атнага кадәр урыныннан тора алмады», дип сөйләгән Рабига 1944 елда Мөхәммәт Галигә). Бу мәрхәмәтле туганнары шагыйрьне савыктыру өчен кулларыннан килгән бөтен шартларны тудырган. Ул «яхшы гына тазарган», аның «рухы күтәрелгән» (Рабига сүзләре). Тукай белән Кәшфелкәбир бервакыт «ун чакрым җыраклыктагы базарлы авылга» (Арчага) баралар. Анда да тулысынча савыкмаганлыгы сизелгән аның: бер урыс өенә кергән җирдә суык аның «тешләрен шакылдатып, Казандагы рәвешчә бөтен тамырларын дерелдәтә» башлый. Тукай мич башына менеп ятарга мәҗбүр була. 1912 елның март башларында гына Кәшфелкәбир аны Казанга илтеп куя.Шәһәргә кайткач та, ул салкын тидереп, яңадан авырып алган әле.

Беренче карашка, Тукай Өчиледә өч ай чамасы гомерен уздырганда (вакыты күп кебек), Арча янындагы Күпербаш авылына да барып йөргән дип уйларга ярый да шикелле. Әмма бу, минемчә, һич тә мөмкин түгел:

– ник дигәндә: ул, әйткәнебезчә, тулысынча ук сау-сәламәт түгел; шулай да авылдан китеп барганда беркадәр савыккан булуы исә «дөге ярмасы белән пешерелгән үрдәк шулпасы» ашау, җылы сөт эчү, авыл һавасын сулаудан, җиңгәсенең тәрбиясеннән булгандыр (Әминә белән очрашкан чагында Тукай инде авыру,... ул моңа кадәр дә үзенең нинди нәтиҗә («близкий исход») көткәнен сизгән, дип яза автор да!);

– тагын да бик мөһим нәрсә: ул үзенең Өчиле авылында икәнлеген берәүгә дә белгертмәскә кушкан (китаплары белән жандармерия бик тә кызыксынган вакытлар); Р.Нәфыйков 1966 елда Казан цензура комитетының 1912 ел ноябре-апрельләрендә Тукайны эзәрлекләве турында язды;

– җиңгәсе Рабига да истәлегендә (1944) аның башка берәр авылга кымыз эчәргә барып йөрүе турында бер сүз дә әйтми (әгәр шул вакытларда башка бер авылга барып йөргән булса, моны язмый калмас идеме?);

– Өчиле белән Күпербаш арасы унбиш чакрымнар, шактый ара; сәламәт булмаган хәлдә кышкы юлда кымыз эчәргә (Р. Мир-Хәйдәрев тәэтмәсе: «кәҗә сөте эчәргә») («Тукай приезжал в Кyпербаш на козье молоко.... «часто (!) приезжал из Казани» (!) диелә) йөрерме, үзенең авыру икәнлеген белгән хәлдә дә өйләнү турында сүз ачармы, гаилә кору кебек гаять җитди мәсьәлә белән шөгыльләнерме?

Г.Камал истәлегендә «Берничә тапкыр (!) авылга кайтып китүләрен исәпләмәгәндә, Тукай, Казанга килеп тора башлагланнан башлап үлгәнчегә чаклы бары өч тапкыр Казаннан читкә чыгып кайтты», диелгән. Бу «берничә тапкыр» сүзен кулланганда кимендә өч тапкыр булу күз алдында тотыла кебек. Югарыда икесе турында гына әйтелде (Г.Камал, бу сүзендә «тапкыр»ны истә тоткандырмы, бу – билгесез).

1912 ел башында өч ай чамасы Өчиле авылында яшәп алуы турында алда сүз булды инде, фикеремне әйтә алдым кебек. Автор тарафыннан билгесез дип тәкъдим ителгән (фаразланган) Әминә белән Тукайның очрашулары, бәлкем, элегрәк заманга – 1911 елга карыйдыр. Реаль факт: 23-24 апрельләрдә «Тургенев» исемле пароходта шагыйрь Әстерханга китеп барган. Монда аны әзәрбайҗанлы доктор Нариман Наримановка күрсәтәләр. Аңа кымыз эчеп көч җыярга киңәш ителә. 6 июньдә ул пароходта Казанга кайтырга чыккан. Кайтуга ияк эшенә чумган, җәен бер ай чамасы шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләй белән очрашып торган.

Күзгә якта авыруы көчәю турында алда инде язылды... 1911 елда Тукай Күпербаш авылына барып йөргәнме соң?.

Р.Мир-Хәйдәрев мәкаләләрендә кузгатылган Тукайның Әминә туташ белән ике арада кабынган «соңгы мәхәббәте»нә мөнәсәбәтебезне шәрехләргә омтылабыз икән, шагыйрьнең гомумән хатын-кыз, сөю-мәхәббәт, гаилә кору кебек мәсьәләләргә үзенчәлекле карашы, язмаларында чагылышы хакында да фикер йөртергә тиешбездер. Дүрт ай ярымлык чагында кинәт атасы үлеп китеп, дүрт яшьләрендә исә газиз анасы да гүр иясе булып, тома ятимлеккә дучар ителеп, кулдан кулга күчеп йөреп үсәргә, тернәкләнергә тиеш булган бу ир бала, билгеле ки, нормаль тормыш шартларында тәрбия күрмәгән, тулы гаиләләрдәге ата-ана һәм балакайлары арасында була торган сөю-яратулы мөнәсәбәтләрне тоеп үсмәгән. Ятимлектә кимсенеп үсү, шатлыклы кичерешләр аз эләгү, 22-23 яшьләрдә үк сәламәтсезлек билгеләре күренә башлау аның холык-фигыленә, психологиясенә (дөресрәге, үз-үзен идентификацияләүгә) бер генә дә тәэсир-йогынты ясамаган, дип әйтергә ярамастыр. Әмма моңа карап кына сөю-мәхәббәт хисләре аның иҗатында чагылыш тапмаган икән диген нәтиҗә ясалырга тиеш түгел. Дистәләгән шигырьләре шагыйрьнең хисси дөньясы бай, сизгер, нәфис, нәзакәтле булуы белән бүген дә безне дулкынландыра. Истәлекләрдән күренгәнчә, Тукай реаль тормышта да мәхәббәт хисләрен олылаган, бу мәсьәлә белән бәйлелектә килеп туа торган гамәли моментларга гаять җитди караган, хатын-кызларга гына хас психологик үзенчәлекләрне дә яхшы күзаллаган. Аның хатын-кызлар булган очрашу-сөйләшүләргә катнашырга теләмәве, шигырьләрен яратып укып, үзен дә күрергә, үзе белән – шагыйрь кеше белән дә күрешергә, танышырга килгән кызлардан (мәсәлән, Зәйтүнәдән) читләшүе турында дуслары, замандашлары (З.Вәлиди, Г.Камал, Ф.Әмирхан, Ф.Туктаров, Ф.Апакова һ.б.) шәһадәтлек бирә. «Мин аңар үзе мәхәббәт итә торган бер кыздан (чынында, Зәйтүнәдән) качып йөрүенең сәбәбен аңламаганлыгымны вә гайре табигый санаганлыгымны сөйләдем. Ул озак җавап бирми торганнан соң, үзенең бер күзен ишарә белән күрсәтеп, «Печать проклятия», диде», – дип яза Ф.Әмирхан. Хиссез шагыйрь була аламы икән? Истәлекләрдә аның да хис кешесе булуына басым ясала (Ф.Әмирхан: «Хис белән генә тора торган кеше»). Әмма Тукайда акыл да җитәрлек. Шуның чагылышына бер мисал. 1910 елның 4 декабрендә дусты С.Сүнчәләйгә юллаган хатында, ул чаклардагы тормыш чынбарлыгыннан чыгып, үзенең гаилә хакындагы «коры фикере»н яза: «Әгәр ... рәфыйкаңның (хатыныңның) синдәге хакын бөтенләй үк тәләф итмәгән булсаң (бозмаган булсаң), син – аны, ул сине якындан белеп яратышсаң, шуның өстенә, шәрмәндәи гыял (гаиләңне оятка калдыру) булмасын өчен, иң азында, җыл тәүләгенә биш йөз тәңкә килереңболса, һәркемгә өйләнү тиеш». Кыскасы, Тукай үзенең нинди хәлдә булуын яхшы аңлаган, һичкенә дә гаилә кору теләге белән яшәмәгән, мәхәббәт хисләре белән янса да (Зәйтүнәне онытa алмавы билгеле). Әмма шагыйрьдә бу яшерен тәс алган:

Файдасыз ит кисәгендән гыйбарәтдер йөрәк,

Парә-парә кисмәсә гыйшык мәхәббәт кайчысы.

... Әмма ләззәтле дә соң яшьрен газап, яшьрен яну! –

Бар микән, белмим, моның миннән бүтән аңлаучысы! –

дип яза ул «Мәхәббәт» шигырендә (1908). «Актык тамчы яшь»тә исә (1910):

Бик юашлатты мине яшьрен сөюдән җан көю,

Бар иде булган чагым хәтта арсландан кыю!

...Үлде рух яшьрен мәхәббәттән, – хафаю күлсәдә, –

Нишлим, иркәм кәйфенә килгәч шулай бер җан кыю! –дия.

Бу урында Җан (Галимҗан) Шәрәфнең бик тә кызыклы фикерен укучы игътибарына китермәкче булам. Аныңча, Тукай «... мәхәббәтен яшерен саклый, ләкин мәхәббәтен мәхбүбәгә белдермәве хәзер Тукайның куркуыннан, әйтергә кыюлыгы җитмәвеннән түгел, бәлки башка сәбәптән: Тукай «яшерен мәхәббәт», игълан ителмәгән, ачылмаган, хәтта мәхбүбәнең үзенә белдерелеп тә, яңалыгы, сафлыгы югалмаган мәхәббәт белән ләззәтләнә башлый. Ул тирән, куәтле мәхәббәт дип шундый мәхәббәтне генә саный башлый».

Укучы күргәндер: 2018 елгы мәзкүр язмалар укучыларга «Шагыйрьнең соңгы мәхәббәте» («Последняя любовь поэта») дип тәкъдим ителде, быелгысы исә «Единственная любовь поэта» дип исемләнгән. Әүвәлгеләрендә ул Зәйтүнә белән Тукайга нисбәтле хис-кичерешләрне Тукайның беренче мәхәббәте дип саный иде (Зәйтүнә – «Г.Тукайның сөеклесе», «она была возлюбленной Тукая», «первая возлюбленная Тукая» – Автор сүзләре). Тукай белән Зәйтүнә арасында 1908 елларда килеп туган мөнәсәбәтләрнең асылда чын мәхәббәт төшенчәсенә туры килүе истәлекләрдә, мәкалә-язмаларда килә. Аларның исемнәрен атап чыгарга кирәкмәс дип уйлыйм. Бу урында тик берсен генә күрсәтмәкчемен: ул – язучы-тарихчы Мирсәй Гарифның «Мәңгелек мәхәббәт. Тукай белән Зәйтүнә хикәяте» исемле китабы (Казан, 2006). Хикәят дигәч тә, ул легендар яңгырашлы вакыйга һәм образларга нигезләнеп язылган дип уйланмасын. Автор үз фикерен Тукай тормышы һәм иҗатына караган күптөрле реаль моментларга таянып яза.

Р.Мир-Хәйдәрев «Звезда Поволжья» газетасында ике ай дәвамында басылып торган бай мәгълүматлы мәкаләсен юкка гына «Шагыйрьнең бердәнбер мәхәббәте» дип исемләмәгән. Аныңча, Тукай Күпербаш авылына килгән («часто бывал у Хабибуллиных»; «где много раз бывал Тукай»; Казаннан килеп йөргән; «его подарки»!?), Әминә күңелендә дә, шагыйрь күңелендә дә гыйшкый хис-тойгылар пәйда булган, һәм алар бакый дөньяга киткәнчегә кадәр дәвам иткән икән иң. 1945 елдан башлап Мартукта гомер кичергән Әминә Камалиеваның (1895-1976) вафат булгач та, кыз фамилиясе – «Хәбибуллина» белән күмелү фактында да, читләтеп кенә булса да, Тукай белән очрашулары версиясе раслана диелә язмада. Автор фикеренчә, шагыйрь Күпербаш авылына очраклы гына барып чыкмаган, ул анда эшләгән (?), дәваланган («лечился»). Үз интуициясенә дә ышанып, Р.Мир-Хәйдәрев Тукайның сөеклесе белән очрашуы иҗатында эз салмый булмагандыр диген фикергә килә. Моңа кире каккысыз дәлилләр итеп автор шагыйрьнең 1912 ел 30 декабрендә чыккан «Җан азыклары»ндагы «Ни кирәк тагы?» һәм дә «Йолдыз»дан да курка» шигырьләрен күрсәтмәкче...

(Дәвамы 11 нче биттә).

ФИРДӘВЕС ЗАРИФ

АК БҮРЕ



Ак бүре ыруы бетүгә йөз тота башлады. Моны ыру башы Ямгырбәк җаны-тәне белән тоя иде. Яшь-җилкенчәктә олыларга ихтирам кимеп бара. Әле борын асты да кипмәгән яшүсмерләр үзләрен сугышчы ирләр белән бер рәткә куеп сөйләшмәкче итәләр. Хәер, ирләрдән дә ил-көн кайгысы китте. Ыруара сугышлардан һәрберсе мал тояп, кәнизәк чибәр хатын-кызлар алып кайтырга тырыша. Элек җиңүне бер көн бәйрәм итсәләр, хәзер инде аш-сый мәҗлесләре өчәр көнгә сузыла. Яшь кызларда да итагать бетеп бара. Кеше-кара күрмәгәндә, ирләрнең муенына асылынырга торалар. Дөрес, ирләр белән тотылганнарын җәзага тарта килә Ямгырбәк, әмма, моңа карап кына, андый очраклар кимеми. Боларның барысына да кояш баешындагы кавем гаепле икәнлеген белә ул. Аларның сәүдәгәрләре яшертен рәвештә эче бал да алып килгәлиләр икән. Моңарчы кымыз да эчмәгән хатыннар эче бал капкалый башлаганнар.

Әлеге хәлгә чик куярга теләп, эче бал белән тотылган сәүдәгәрне, кул-аякларын бәйләтеп, ач шакалларга ташлаткан иде Ямгырбәк. Әмма шуннан соң сәүдәгәрләр килми башлагач, һәрберсенә кагылгысызлык ярлыгы бирергә мәҗбүр булды.

Шулай да сәүдәгәрләрне гүзәл кәнизәкләр белән сату итүдән тыйды Ямгырбәк. Югыйсә кәнизәкләр сатып алган ирләр, хатыннарын онытып, алар белән күңел ача башлаганнар иде. Бүген ыруда имезүче кол булган сөт аналары гына бар.

Яшьрәк вакытында ыруны коры тота иде Ямгырбәк. Хәзер картайды шул, житмешенче яшь белән бара. Болай булмый, алмаш эзләргә кирәк, алмаш. Соңгы араларда дала киңлегендә ак бүре дә күренми башлады. Хәерлегә түгел бу, ыру өчен кисәтү...

* * *

Нәгыйм манма тиргә батып уянды. Әле уянгач та, шактый вакыт серле төш тәэсиреннән айный алмый торды. Ямгырбәк, ак бүре... Күреп, ишетеп түгел, тарихи китаплардан да укымаган хәлләр ничек керде соң әле төшенә?!

Тукта, очраклы хәлме соң бу? Безнең җәмгыять тә бозыклык, әхлакый деградация сазлыгына торган саен бата бара түгелме?! Шулай ук ата-аналар белән балалар, өлкән һәм урта буын белән яшь буын арасындагы упкын да тирәнәя. Алар хәзер бездән түгел, ә телевизордан күрсәтелә торган фильмнардан, әхлакый тотнаксызлыкны нормага әйләндергән төрле шоулардан үрнәк ала.

Болар барысы да милли тәрбиянең булмавыннан, милли йола-гадәтләрнең, милли традицияләрнең онытыла баруыннан килә бит.

Кая карама – бөтен җирдә таркаулык. Ул хәтта милли аңны, дәүләтчелегебезне торгызырга, милли яңарышны булдырырга тиешле милли хәрәкәткә дә үтеп керде. Анда да бүген тарткалаш, шәхси мәнфәгатьләрне милләт мәнфәгатьләреннән өстен күрү хөкем сөрә.

Шундый уйларга бирелеп утырганда, домофон кыңгыравы шылтырады. Трубканы алды.

– Әйе. Кем бар анда?

– Мин әле бу – Солтан.

– Хәзер ачам, дустым.

Нәгыйм ачкыч рәсеме ясалган төймәгә басуга, музыкаль сигнал яңгырады. Бу ишекнең ачылуын аңлата иде.

Ике-өч минуттан, Солтан сигезенче катка менеп тә җитте. Ишек кыңгыравы тавышына Нәгыйм аңа каршы чыкты. Хәер, ул башта әчке агач, аннары тышкы тимер ишекләрне ачып коридорга чыкканчы һәм, ниһаять, коридордагы тимер ишекне ачканчы, тагын берничә минут узды.

– Ай-яй, крепостьтагы кебек яшисең син. Тиз генә керерсең димә. Хәер, үзебездә дә шул ук хәл инде.

– Ишек биге нәрсә ул, Солтан! Күңелләр дә бикләнеп бара – менә шунысы аяныч.

– Гомер булмаганны, фәлсәфәгә бирелә башладың әле син.

– Әйдә, залга уз. Күңелне борчыган нәрсәләр бар. Син, утырып, газеталар караштыра тор. Ә мин тиз генә чәй куеп җибәрим.

Нәгыйм электр чәйнегендә чәй кайнатып алды. Чәй янына ризыклар куйгач, мәйне дә чыгарасы иткән иде, Солтан каршы төште:

– Юк, туган, аны эчкәч сөйләшкән сүз – сүз түгел инде ул. Әйдә, бабайларча, аек баштан фикерләшик.

– Рәхмәт, дустым. Мин үзем дә шулай уйлыйм.

– Йә, нинди борчу килде башыңа? – дип сорады Солтан, өстәл янына утыргач.

– Аны ике сүз белән генә аңлатып булмый инде. Борчу дигәч тә, шәхси борчу түгел инде ул. Күңелне тырнап торган борчулы уйлар дисәң, дөресрәк булыр. Дөрес, кичәле-бүгенле генә тумады алар. Бүген иртәнге якта күргән төш аларны яңартып җибәрде әле. – Нәгыйм күргән төшен кыскача гына сөйләп бирде.

– Алай икән, – диде Солтан, мыек астыннан гына елмаеп. Аның болай да кечкенә күзләре тагын да кысыла төште. Аннары чигәләре инде пеләшләнеп килгән башындагы озын сирәк чәчләрен артка сыпырып куйды. – Мин үзем төшләргә игътибар иткән кеше түгел анысы. Мендәргә башны куюга, караватка сеңәм дә будильник тавышына гына уянам. Үзең беләсең, ике эштә эшлим. Акча кирәк бит, быел кызны да укырга кертәсе бар.

– Шулаен шулай ул да, дустым. Акча кирәк анысы, ансыз кая барасың. Коммунизм дигәннәре мираж гына булып чыкты. Хәзер, тырыша-тырыша, капиталистик җәмгыять төзибез, дөнья куабыз.

– Җәмгыятен кем белгән инде аның, туган. Капитализмның минем гаиләдән үк башлануы хак. Хатын, дипломын чемодан төбенә салып, базарда сату итә.

– Әле мәктәптә татар телен укытып йөри иде түгелме соң?! Мин тагын, балаларга милли тәрбия бирә, дип куанган идем.

– Тәрбия ул гаиләдә үк башланырга тиеш, туган. Төп нигезе гаиләдә аның. Хәлемнән килсә, мин Гөлчирәне өйдә генә утыртыр идем дә, әлеге дә баягы, акча җитми. Ике җирдә эшләп тә, егерме меңгә дә тулмый бит минем хезмәт хакы.

– Акчаның җиткән чагы юк инде аның, дустым. Менә балалар урам тәрбиясе алып үсә, шунысы аяныч.

– Шул-шул менә, урам тәрбиясе. Ә анда сыра, аракы эчәргә, тәмәке тартырга өйрәтәләр. Моның нәрсәгә илтүен аңлатып кара син аларга! «Отстой булып йөрисем килми әле», – дип кенә җибәрәләр.

– Шулай, дустым. Өйдә утырса да, юньле нәрсә күрми ул. Телевизорны кабызсаң, һәр тапшыруда диярлек бозыклык. Әллә нинди шоулар уйлап таптылар. Ул киноларны әйткән дә юк инде. Киләчәккә идеаллар, максат калмады. Дингә кайтарасы иде яшьләрне, дингә... Югыйсә, күңелләрендә бушлык.

– Белмим, туган, ата-аналары динсезлектә үскән балаларны дингә кайтарып булырмы икән?! Шәһәрдә әби-бабай тәрбиясе күрми үсте бит алар.

– Кул кушырып утырыйкмы инде алайса?

– Мин кул кушырып утырыйк димим. Тәрбияне башта үзебездән башламыйкмы икән?

– Сүзең хак, дустым. Гаетләрне санамаганда, намазга баскан кеше түгел инде без.

–Авыздан өзеп алдың, туган. Пенсиягә чыкканны көтмәскә иде дә бит, әлеге дә баягы – акчасызлык. Вакыт җитми, дөнья куабыз. Хатыннар өйдә утырып, ирләргә гаиләне тотарлык акча түләсәләр иде дә ул. Мин дә бер эштән кайтып, икенчесенә китмәс идем. Дини китаплар да укыр, бәлки, акрынлап, намазга да басар идем.

— Анысы, теләгән очракта вакытны табарга була инде ул. Хәзер мәдрәсәдә кичләрен яки ял көннәрендә дә укыталар. Минем хатын, Аллага тапшырып, ял көннәрендә мәдрәсәгә йөри башлады инде. Үзем дә ниятләп торам, насыйп булса.

Солтан сәгатенә күз салды.

– Кара, минем эшкә барыр вакыт җитеп килә икән.

– Бүген ял көне бит. Нинди эш ул тагын?

– Бер фирмага каравылга урнашкан идем мин. Көнаралаш шунда йөрим. Ни, туган, калганын телефоннан сөйләшеп бетерербез инде, яме. Минем сиңа бер мөһим йомышым бар иде.

– Тыңлыйм, дустым.

– Машинам искерде, яңасына акчам җитеп бетми. Биреп тора алмассыңмы икән?

Нәгыйм бер минутка телсез калды. «Менә сиңа мә, мин аны ихластан сөйләшеп утыра дип торам. Ә ул акча сорар өчен генә кергән икән». Тик теле белән башкача әйтте:

– Акчаны бирермен анысы, Солтан. Хатынның авылдагы йортын саткан акчаны саклык банкына салган идем. Үзең беләсең, бүген банк эшләми. Иртәгә кичке якта сугылырсың.

– Менә рәхмәт, туган. Яхшылыгыңны гомер онытмам. Син бер дә борчылма, татар яши әле ул, яши.

Солтанны озаткач, фәнни хезмәтенә утырырмын дигән иде дә Нәгыйм, күңеле ятмады. Онытылып булмасмы, дип, тиз генә киемен алыштырды да бакчага юл тотты.

Тик бакчада да тынычлык килмәде аңа. Дөрес, гадәттәгечә, бар эшне җиренә җиткереп эшләде. Өйгә дә арып-талып, соң гына кайтып керде. Хатыны инде борчыла ук башлаган иде.

Ашап алгач, барыбер йокы кермәс, дип, фәнни журналларны караштырды, фәнни хезмәтенә тотынып карады. Тик уйлар өермәсе әзәрлекләүдән туктамады. Стена сәгате төнге берне суккач кына, борчулы уйлардан айнып киткәндәй булды. Залга кереп, йокларга ятты.

* * *

Таң алдыннан гына йокыга талды ул. Төшендә Нәгыйм җиргә тезләнгән Ямгырбәкне һәм дала буйлап аннан ераклаша баручы ак бүрене күрде.

– Ташлама ыруны, ак бүре, ташлама! – дип ялварды аның артыннан Ямгырбәк.

Шунда һич көтелмәгән хәл булды – кемдер ак бүрене укка алды. Ямгырбәк башта катып калды, аннары, сикереп торып, ук очып килгән якка ыргылды. Калкулыкта, җәясен тотып, кече улы Байгурҗа басып тора иде.

– Борчылма, атай, тиресеннән сиңа яңа бүрек тектерербез, – дип, аңа каршы атлады яшүсмер.

Ямгырбәк, йөрәген тотып, җиргә сыгылып төште дә мизгел эчендә хәрәкәтсез калды. Еракта-еракта – дала читендә ач шакаллар улый иде.

Чырагында Арча уты көйри

(Ахыры. Башы 14 нче санда).

«Инде бетте...» дигәч, кабат калка,
Соңгеләрдә әле дәрман калган.
Ханлык байрагына иң соңыннан
Газиз ягым – Арча каны тамган.
(«Арча капкасы» – «Канлы рәшә»)

Сания ханым моны һәрвакыт истә тотып иҗат итә. Бу аның бүгенге чынбарлыкка мөнәсәбәтле уйлануларының да нигезенә салынган.

Халкыбызның «Ат аунаган урында төк кала» дигән әйтеме бар. Шуның шикелле, каләм әһеле булган җирдән дә әдәби язмалар, тирән уйланулар белән тулы әсәрләр кайта. Ә.Еники, И.Нуруллиннар Төркиягә булган сәяхәтләреннән соң никадәр мөһим күзәтүләр белән чыгыш ясаган иде. Ф.Бәйрәмова, Т.Галиуллиннар хаҗ сәфәреннән алган тәэсирләре белән уртаклашты. С.Әхмәтҗанованың «Төрки дөнья таҗы – Төркия» дигән лиро-эпик циклга тупланган шигырьләрен дә шулар рәтенә куярга кирәктер. Чыннан да, халыкларны аерып торган чикләр бераз йомшара төшкәч, безнең милләттәшләр дә тугандаш төрекләр иленә еш йөри башлады. Әмма диңгез суларында коенып, кояшында иркәләнеп кайткан, яки сату-алу мәшәкатьләре белән йончыган ул кешеләрнең берсе дә шул сәяхәтләреннән шигъри табышлар белән кайтмады. Моның өчен бөтенләй башка кеше – бу очракта С.Әхмәтҗанова булу кирәк шул. Аңа бу җәһәттән сокланырга кала. Моңа ул ничек ирешә? Җавап беренче карашка гади генә кебек – ул башкалар гамьсез генә үтеп киткән нәрсәләрдән дә олы мәгънә табарга сәләтле.

Әйтик, ул төрекләрнең ни өчен үзаллы булып, язмышларын үзләре булдырып яшәүләре турында уйлана. Моңа җавап та таба: алар күп заманнардан бирле җитәкчеләреннән уңып килгән икән иң. Шуларның берсе – Ататөрек исеме белән дан казанганы – «Мин – төрек!» дип әйткән кеше бәхетле була», – дия торган булган. Ягъни ул шушы илгә, халыкка мөнәсәбәтле булуы белән горурланган. Бу сүзләр кавемдәшләренең күңеленә дә хуш килгән. Шагыйрә бу кешенең үз вакытында халкына тиешле сүзне әйтә белүенә соклана.

Чын бәхет кичерер идең
Син бүген, Ататөрек,
«Мин – төрек!» дип горурланган
Балаларыңны күреп.
(«Төрки дөнья таҗы – Төркия» –
«Бәхетле милләт»)

Чөнки алар: «Тау-ташлыкны җир ожмахы итеп, яши белеп яши». Шагыйрә безне дә үз милләтебезне әнә шулай яратырга өнди.

«Мин – татар!» – дип
горурланып дәшәм,
Үз чигемне атлап керәм дә.
Татар әле татар буна түгел,
Тамырлары киткән тирәнгә.

Татар бетсә, без дә бетәбез, дип,
Ничә милләт төбәлгән безгә?!
Телне яклап соңгы талпыну бу –
Аягүрә басыйк, бер эзгә!
(«Төрки дөнья таҗы – Төркия» –
«Соңгы талпыну»)

Чөнки бер эздән барган очракта гына алга килеп баскан мәсьәләләрне хәл итеп була. Әнә Г.Исхакый, С.Максуди, Й.Акчура һ.б. элгәрләребез үз ватаннарында чит-ят ителгәч, гомуми эздән тайпылмас өчен, «ят нигездә туган булып» танылган, шуның «сәяси-мәдәни күгендә якты йолдыз булып кабынган». Бу илнең таңы атсын өчен, татар акылын да китереп кушканнар. Заманында аларны үзебездә «кара маяклар» дип атаганнар иде. Вакыт шуны күрсәтте: аларның күңелләре дә, әсәрләре дә якты булган, шәхси бәхетләрен туган халкының тулаем бәхете белән берләктә табарга омтылу бары тик ак максат кына була ала. Шуңа күрә безнең хәлебезне «соңгы талпыну» дип саныйсы килми. Хәер, шагыйрә үзе дә моны яхшы аңлый.

Татарлыгым белән чын ихластан
Горурланып кайттым кунактан.
Телемне дә тотып кисмәделәр,
Һәм бормады беркем колактан.

Кунакта бу илнең табигате, хуҗаларның җылы мөнәсәбәте күңел рәхәте бирсә дә, болар лирик геройга үз илен алыштыра алмый. Аның өчен Европаны парланырга өйрәткән төрек мунчасы да ят, «анарлар» да «ышандыра торган ялганнар» сыман. Аңа миллекле мунчалар, ахак муенсалы баланнар кадерле. Циклга кергән «Каласың» шигырендә:

Үз ярыңа кайт, дип, салмак кына
Хәтеремә кага Казансу,

– ди ул. Шагыйрә үзе туып-үскән Арча төбәгендәге башка суларны да олылый. Ашыт, Шушма елгалары, җанга якын җирләр күкрәгеннән агып чыгып, Иделгә – Ана суга үзләренең тыйнак кына өлешләрен кертеп тора. Туган телебезнең сафлыгы шушы төбәктә кадерләп сакланган кебек, әлеге суларны туендыручы чишмәләр дә сафлыкларын, шифалы сыйфатларын безнең көннәргә кадәр китереп җиткергән. Шулай да С.Әхмәтҗанованың төп мәхәббәте әлеге дә баягы Казан суга барып тоташа. «Идегәй» дастанында ук «кара урманның төбендә каралып аккан Казан су» дип искә алынуы ук ерак дәверләрдә яшәгән шагыйрьләрнең дә теленә менгән Казан суына карата аерым бер хөрмәт уята. Шагыйрәнең борынгы шигъри өслүбкә якын аваздашлыкка ирешүе дә табигыйлекне көчәйтә.

И Казан су, Казан су,
«Җир кендеге» – бер чишмәдән
Җан тибеше тапкан су.
Сеңелләрен барлый-барлый,
Казаныма чапкан су,
Богылтауга каккан су,
Йөз кизләүнең күзе белән
Ак кирмәнгә баккан су.
(«Арча сулары» –«Казан су»)

Миңа Арча районында Г.Ахуновның туксан еллыгына багышланган чараларда катнашырга насыйп булган иде. Арабызда С.Әхмәтҗанованың да булуы хәтердә калган. Инде Өчиле авылы бетсә дә, кечкенә Гариф суын эчеп үскән мул сулы чишмәсе, берни булмагандай, һаман агып ята. Димәк, чишмәләр кешеләрдән озынрак гомерле. Бу күренеш күңелдә моңсулык та, тирән уйлар да тудырды. Кайчандыр бергә кайткач, чишмә суыннан авыз иткән Гариф абыйның көлә-көлә тау битеннән өскә күтәрелгән мизгеле күз алдыма килде.

Ә бу юлы, чишмә ачылышыннан соң, Казанбаш мәктәбенә килдек. Урамыннан узганда, Сания ханым, Арча ягына, Гариф абыйга мөнәсәбәтле итеп, һәр өй, аның кешеләре, үткәннәре турында сөйләп ала. Мәктәп исә аның күңелендәге истәлекләр дәрьясын тагын да көчлерәк ерып җибәрде кебек. Мәгънәле йөзеннән, ялкынланган күзләреннән, алардан битәр сөйләменең ягымлышыннан туган төбәгендәге һәрнәрсәнең аңа якын, үз, кадерле икәнлеге күренеп тора. Әсәрләрендә исә бу тагын да ачыграк сизелә. Казан су аның өчен, үзе әйткәнчә, «яшьлек хисе тамган су», «Кесмәсен кочагына алып, зур дөньяга агып чыккан су».

Һәр шагыйрь туган ягына мәдхия җырламыйча калмый. Әмма һәрберсе моны үзенчә эшли. Сания ханым тасвирлаганнар аларның берсенә дә охшамый. Чөнки ул Кесмәс, Казансу буйларының кабатланмас гүзәллеген, тарихи тамырларын җырлый. Аларга хас матурлык сыйфатлары, тарихи катламнарның зурлыгы бары тик монда – Арча төбәгендә генә. Шуңа күрә башка якларның җыры бары тик бүтәнчә генә була ала.

Кайбер халыклар, бездәге бер Арча ягы биргән кадәр каләм әһелләренә генә ия булса да, ничек горурланыр иде. Ышанып әйтергә кирәк, аларны зур әдәбиятлы халык дип атарга да мөмкин булыр иде. Шушы уңдырышлы туфракта җитешкән талантларның берсе, әлбәттә, С.Әхмәтҗанова. Арча кешеләре генә түгел, моңа без барыбыз да шөкер итәбез. Шагыйрә үзенең гомер бәйрәмен каләм йөгереклеге, фикер үткенлеге, иҗади куанычлар, ашкынулы күңел белән каршылый. Алдагы гомерендә дә ул бу җәһәттән безне сөендереп яшәр. Хәер, йөрәгендә Арча уты көйрәгән иҗатчының үз мәгънәсе бары шулай гына була ала.

Фоат ГАЛИМУЛЛИН.
Март, 2022 ел.

Шагыйрьнең «бердәнбер мәхәббәте» Әминәме?

(Ахыры. Башы 8нче биттә).

Ә М.Мәһдиев Г.Гейне сүзләренә Ф.Шуберт тарафыннан язылган романсның заманында бик популяр булуын, текстын Фет, Майковлар тәрҗемә иткәнлеген язып чыккан иде. Анда (текстта) «Җанкисәгем, ни кирәк тагын?» соравы рефрен сыйфатында гәүдәләнә. Нәкъ Тукайдагыча. М.Мәһдиев версиясе: «Тукай бу шигырьне немецча текстка ияреп, үзенчә үзгәрткән». Аныңча, Г.Гейненең «Әлмансур»ын турыдан-туры тәрҗемә иткән С.Сүнчәләйнең аны Тукайга укып күрсәткән булуы мөмкин, яисә Фет тәрҗемәсе белән очрашкандыр. Экспромт дип кенә аталуы да шигырьнең кинәттән язылуы, бик кызыклы рефрен «җилкәсендә» генә тууы турында «кычкырып»тора ич...

Былелгы мәкаләсенең исеме, күренә ки, ике төрле уйларга ирек бирми: Тукай белән Зәйтүнә мәхәббәте, инде һичшиксез, «юкка чыгарылырга» тиешле. Шунлыктан да мәкаләнең соңына таба укучыны Р.Мир-Хәйдәрев үзенең версиясен раслардай уй- фаразлары белән таныштырмакчы.

Мисалга берсе. Автор 1908 елда 14 яшендә чагында Тукай белән танышкан Зәйтүнә, ни өчен, үсә төшкәч тә, Тукай белән очрашырга омтылмаган дигән сорау куя. Җавап бирү кыен түгел. Казандагы тормыш читенлеге аркасында Зәйтүнәләр киредән Чистайларына кайтып киткән бит (аны Тукайдан читләштерү өчен, имеш). Аралар да ерагайган, Тукай белән икесе арасында туган гыйшкый хисләр дөньясында гына торып яшәү мөмкинлеге булмаган бит. Р.Мир-Хәйдәрев Тукайның 1908-1909 елгы шигырьләрен карап чыккан һәм аларда Тукайның Зәйтүнәгә яшерен мәхәббәте яшәгәнлегенә дәлилләрлек шигъри сурәт-образларны, ишарәләрне очратмаган. Ә бит тикшеренүчеләр, истәлек язучылар шагыйрьнең «Вәгазь», «...гә (Очраган...)», «Кызык гыйшык», «Кулың», «Мәхәббәт» кебек шигырьләренең нәкъ менә Зәйтүнә белән очрашулар нәтиҗәсендә туган хис-кичерешләрне чагылдыруын әйтә. Зәйтүнә исеме хәтта «Мә, мә, мә!» шигыренең текстына да «килеп кергән»... Җәмалетдин Юмаев «Яшерен мәхәббәт» исемле мәкалә белән «Сөембикә» журналында чыгыш ясагач, Зәйтүнә ханымның «чын ышанычлы, мәрхәмәтле дин кардәше» Г.Исхакыйга «аклангандай» хат язуыннан, язучының аңа җавабыннан Зәйтүнә Тукайны яратмаган дигән фикер тумый... Мин сүземне кыскартып, Тукай белән Зәйтүнә арасында мәхәббәт темасының күпсанлы мәкаләләрдә урын алганлыгын әйтү белән чикләнергә телим. Кыскасы, Тукайның бердәнбер мәхәббәте туугa сәбәпче кыз – Зәйтүнә. Тукай (үзе белән көрешмичә дә) шигъриятен яратуы, әсәрләрен укып хозурлануы Әминәгә җиңел булмаган тормыш шартларында сокланыгыч гомер кичерергә мөмкинлек биргән, дип уйлыйм.

Зөфәр РӘМИЕВ,
филология фәннәре докторы.
14.04.2022, Казан.

Рәшит Сафиуллинның эмаль әсәрләрендә гади халыкның шатлыклы, мәшәкатьле тормышы уч төбендә кебек ачып бирелә. Гомумән, сынлы сәнгать, рәссамнар әйтүенчә, көндәлек алып бару белән бер ул... Менә «Тауга таба» хезмәтендә җилкәсенә авыр йөк күтәргән бер хатын-кыз тауга күтәрелә. Бу эшне караганда күңелдә: «Кайтып җитә алсын берүк!» дигән теләк туа...

МАВЫКТЫРГЫЧ

«Ата-ана көне» әсәрендә исә ял көннәрендә Казаннан кайтучы балаларын һәм оныкларын каршы алырга җыелган ак яулыклы аналар сурәтләнгән. Күзләре офыкка юнәлгән мондый аналарны остага еш күрергә туры килгән. Аның майлы буяулар белән язылган картиналарында да – балалар һәм өлкәннәр дөньясы. Менә бер картинада боз белән капланган елгада балалар тимераякта шуа. Алар, әйтерсең очар кошлар! Ә менә яр читендәге этиләрен инде ярдан куптарып алырлык түгел! Аларны дөнья мәшәкате баскан, тәмәке пыскытып, бер урында таптанып, үзара гәпләшүне мөһимрәк санайлар. Тимераякларда шуып йөргән чаклар үткәндә калган... «Өйдә берүзе» картинасында сурәтләнгән кечкенә малай йорт эчен күзәтә. Бераз гына шөлләсә дә, ул үз күңелендәге шомны җиңеп, әти-әнисе кайтып җитәчәген ышаныч белән көтеп утыра. Рәшит Сафиуллин, гомумән, балачак хатирәләрен еш искә алырга ярата. «Рәсемнәрне дөньяга кечкенә балалар күзлегеннән карап ясау мөһим дип саныйм. Алардагы фантазия, дөньяга карата шатлыклы, самими караш һәрвакыт сокландыра. Хәтта төрле этаплы иҗатка ия П.Пикассо да: «Һәрбер бала – рәссам. Балачак чорыннан чыккач, рәссам булып калу гына авыр» һәм «Мин Рафаэль кебек яза алам, ләкин бала ясаган кебек итеп ясау өчен миңа бер гомер кирәк булачак», – дип юкка гына әйтмәгән бит!»

Булачак рәссам Рәшит Сафиуллин 1949 елның 23 февралендә Бөгелмә шәһәрендә туган. Аннары аның әти-әнисе нефтьчеләр каласына әйләнәчәк Әлмәткә күченгән һәм Рәшит тә ике абыйсы белән бергә шул калада үскән. «Әтием Тәлгать нефтьче иде, ә әнием Саимә күп вакытын чигү чигеп үткәреп, үз кул эшләнмәләрен сата иде. Рәссам һөнәрен сайлавымда әнием йогынтысы бар. Әниемнең төсле җепләрен, матур чигешләрен күреп үскәнгә күрә, гомуми эстетика, дөнья яме күңелемә керде. Әти-әнием мине Әлмәттә яңарак кына ачылган балалар сынлы сәнгать мәктәбенә укырга бирделәр. Бу вакыйга минем өчен зур бәхеткә тиң иде, ул мәктәпкә таба йөгерә-чаба бардым! Ясаган рәсемнәремне карагач, мәктәп директоры мине шунда ук икенче сыйныфка укырга алды» – ди ул.

Р.Сафиуллин 1964-1968 елларда Казан сынлы сәнгать училищесында укыган. Әлмәттәге бер урта мәктәптә рәсем һәм сызым дәресләрен укыткан. Берара Казан сынлы сәнгать училищесында да белем биргән. 1972-1976 елларда СССР Рәссамнар берлегенең Сенеж иҗат йортында урнашкан Үзәк уку-тәҗрибә студиясендә укыган. Мәскәүдә кино төшерү иҗаты белән мавыгып китеп, танылган кинорежиссер Андрей Тарковскийның «Мосфильм»да төшергән «Сталкер» кинофильмында рәссам-куючы булган («Сталкер» – Канны каласында узган кинофестиваль лауреаты буларак та билгеле). Башка режиссерларның кинофильмнарын төшерүдә дә катнашкан. А.Тарковский Мәскәүнең «Ленком» театрында «Гамлет» спектаклен куйганда, шушы спектакльнең рәссам-декораторы булган. Аннары төрле елларда Казан дәүләт яшь тамашачылары театры, Татарстан дәүләт опера һәм балет театры һәм Г.Камал исемендәге дәүләт академия театры спектакльләре өчен дә декорацияләр иҗат иткән.

●Айлы төн.

●Кышкы миләш.

Моннан тыш ул, әлбәттә, картиналар да ясый, китаплар бизи, график серияләр иҗат итә. Берничә мультфильм төшерүгә дә үз өлешен керткән. Рәшит Тәлгать улы Сынлы сәнгать фондында рәссам-проектлаучы булып эшләгәндә, Әлмәт һәм Казанның иҗтимагый урыннарын проектлау хезмәтендә дә булган. 1974-1975 елларда Тукай-Кырлай мемориаль ансамбленең музей зонасы интерьеры дизайнын иҗат иткән. 1975 елда Мәскәүнең А.И.Герцен музей-йорты интерьерын һәм 1976 елда, иҗат төркеме составында, Арбат урамында урнашкан А.С.Пушкин йорт-музее дизайнын башкарган. 1977 елда СССР Рәссамнар берлегенә кабул ителгән. 1990 елларда иҗатчы Казан белән Мәскәү арасында гомер итеп, зур заказларны үтәгән. Мәсәлән, Мәскәүдә «Базарбай» концерт залын төзүгә күп көч түккән ул. Рестораннар һәм коттеджлар төзүдә дә катнашкан. Мәшһүр оста 2003 елда – «Гармонист» мультфильмының, 2004 елда кинорежиссер М.Разбежкинаның «Время жатвы» фильмының рәссам-куючысы булган.

Рәшит әфәнде улы Чыңгыз белән гамәлгә ашырган зур-зур проектлар да бар. Әйтик, Мәскәүдә, Потсдамда, Швейцариянең Ивердон каласында А.Тарковскийның иҗатына багышланган юбилей күргәзмәләре. Аннары улы Чыңгыз белән берлектә Зөядә «Татар бистәсе» археологик агач музеен ачуга да өлеш керткән. Бу Татарстанда һәм гомумән бөтен Россиядә агач артефактлар саклана торган иң зур һәм иң атаклы музей санала. Россия дәүләт премиясенә лаек мирасханә! Биредәге интерьерлар һәм фасадлар аерым игътибарга лаек. Чөнки аларны иҗат иткәндә, осталар таштай каты агач фрагментлар һәм археологик казылма «дивар»ы кояш нурлары белән җылытылган төсле булып күренсен өчен, яңа төр технология кулланганнар. Рәшит һәм Чыңгыз Сафиуллиннар нибары ярты ел эчендә «XVII гасыр Зөясе» дип аталган панно-реконструкция иҗат итеп тә ихтирам казанганнар, чөнки әлеге хезмәттә барлыгы... дүрт йөз илледән артык персонаж, кораблар, көймәләр сурәтләнгән! Аның гомуми озынлыгы егерме бер метр! Панно анимация ысулында җанландырырлык итеп ясалган!

«Зөя түгәрәк тау дигән сүз. Монда яшәүчеләр аны шаяртып түмгәк дип тә атый. Бирегә сирәк кенә туристларны пароходлар һәм ракеталар алып килгән чаклар бар иде. Кайчак бирегә рәссамнар да килгәләгән. Шуларның берсе – үзем. Хәләл җефетем Гөлчәчәк белән Зөядә таныштык, биредәге тынлык, матур табигать күңелебезгә бик хуш килде һәм без гаиләбез белән Зөя елгасы күренеп торган текә ярда йорт салып, шушында төпләндек, – ди Рәшит Тәлгать улы. – Йортыбыз Зөягә килеп кергәндә, тауга менә башлаган җирдә... Тәрәзәдән карасак: сулык, иркенлек... Бу үзенә күрә бер медитациягә тиң».

Хәзер инде Зөя – башка, шәһәргә туристлар ерак җирләрдән үк килә... Музейларында күп тарихи материаллар тупланган, рәссамнар тарафыннан Зөя шәһәр-утравын сурәтләгән сәнгати әсәрләр дә бар. Рәшит һәм Чыңгыз Сафиуллиннар артеленең эмаль әсәрләре белән дә биредәге музейларда танышып була.

«Мин яңа иҗат төрләренә алынырга яратам, – ди әңгәмәдәшем. – Менә улым Чыңгыз, киленебез Анастасия белән бергәләп «Зөя эмале» иҗат артелен дә бик теләп ачып җибәрдек. Чыңгыз Мәскәүнең Г.В.Плеханов исемендәге Россия икътисад университетын тәмамлап, башкалада шул юнәлештә эшли иде. Әмма офис эшеннән туйды да бирегә әйләнеп кайтты, гаилә корды. Без узган гасырларда финифть дип йөртелгән гамәли сәнгать төренә – кайнар эмаль ысулына өстенлек бирдек. Улым да, Нас-

●Җылы кыш.

●Мәрҗани мәчете.

КАЙНАР ЭМАЛЬ

тя да, үзем дә шушындый яңа төр картиналар, миниатюралар иҗат итәбез. Әсәрләребез бакыр пластиналарда, төелгән пыяла порошогы белән ясала. Махсус пыяла пластиналарны Дулёво заводыннан сатып алабыз. Аларны, корыч савытларга салып, порошок консистенциясе килеп чыгарлык булганчы төябез. Бакыр пластиналарны кирәкле күләмдә кисеп, шомартабыз. Пластиналар төрле булырга мөмкин, билгеле, көмеш, мельхиор, сыйфатлы корыч һәм хәтта алтыннан ук ясалган да. Без үзебез бакырны сайлап алдык.

Финифть – ул төсле пыяла белән металлның 800 градус кайнарлыкта берләшүе. Бу – катлаулы иҗат ысулы. Бик борынгы да. Ул моннан меңнәрчә ел элек кулланыла башлаган, ди галимнәр. Бу техникада вазалар, савыт-саба, декоратив панно һ.б. җитештерелгән. XX гасырның соңгы ун елында кайнар эмаль гадәти кулланыш чикләреннән чыкты. Ул инде металлның да, төсле пыяланың да төрлечә җитештерелә торган техникаларын үз эченә алды. Булачак әсәрне югары температурадагы махсус мичкә берничә мәртәбә куеп алырга кирәк. Эрегән эмаль порошогы мичтә төсле пыяла катламга әверелеп, төрледән-төрле бизәккә әйләнә. Ул нинди эмаль куллануга карап үтә күренмәле дә, тонык төстә дә булырга мөмкин. Оста-эмальер эмаль белән югары температура арасындагы процесска берничек тә катнаша алмый, ул бары үз тәҗрибәсеннән чыгып, эретү вакытын һәм температурасын гына көйли ала. Шуңа күрә дә әлеге иҗади процесста пейзажлар һәм абстракцияләр ешрак тууына гаҗәпләнерлек түгел... Әзер әсәр өслеген тагы бер кат үтә күренмәле эмаль белән каплап куеп та була. Россиядә мондый төр иҗатка алынучылар бик аз. Чөнки бу – кыйммәт сәнгать төре. Мондый төр әсәрләрне ясау бик мавыктыргыч булса да, шактый озак вакыт таләп итә. Мәсәлән, үзем бер әсәрне бер ай иҗат итәм. Мондый картиналар сәнгати кыйммәтеннән тыш, вакыт сынауларына да чыдам, төшеп китсәләр дә ватылмыйлар. Ә менә заказларга килгәндә, башка әсәр дә нәкъ монысы кебек кабатланачак дип бер оста-эмальер да вәгъдә итә алмый. Чөнки әлеге ысулда тулы күчермә ясау мөмкин түгел.

Иҗат җимешләрем белән таныштыру максатыннан берничә шәхси күргәзмәмне дә үткәрдем. 2005 елда әнә шундый күргәзмәм Үзәк рәссамнар йортында, Әдәбият музеенда һәм 2010 елда Мәскәүнең Кино йортында узды. Сәнгать сөючеләр эшләремне бик ошатты. 2015 елда Казанның Ә.Мәҗитов музеенда, Зөя, Ульяновск күргәзмә залларында да иҗатым белән танышу мөмкинлеге булды. Финифть техникасында эшләнгән әсәрләребез берничә дәүләт музеенда саклана. Күп әсәрләрем – Россия, АКШ, Бөекбритания, Германия, Швеция, Швейцария, Япониядәге шәхси тупланмаларда».

«Зөя эмале» артеленең иҗаты утрау-шәһәрчеккә килүче бихисап туристларга таныш. «Баштарак безгә кунакка килүчеләр байтак иде, мәшһүр режиссерлар, рәссамнар, фотографлар... Ләкин вирус афәте сәбәпле, кешеләр кабул итмибез, – ди Рәшит Тәлгать улы. – Шулай да мин һәр көн иҗатта».

Рәшит әфәнденең кайнар эмаль ысулы белән ясалган ювелир эшләнмәләре дә җитәрлек! Ул ясаган гаҗәеп матур беләзекләргә карап туймаслык! «Чыңгыз да ювелир бизәнгечләрне бик яхшы сыйфатта ясый, – диде Рәшит Сафиуллин әңгәмәбез ахырында. – Гаиләбездә иҗатчылар булуына шөкер итәм! Иҗат – бик зур бәхет ул! Тагы бер бәхетем бар – шушы Җирдә җәннәттәге кебек яшәвебезне аңлавым!»

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

●Чиста боз.



●Йолдызлы чатыр.

●Яңа көймә.

Быел К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрына 90 ел тула. Ул соңгы берничә елда байтак үзгәрешләр күрде – баш режиссер булып Туфан Имаметдинов килде, төрле жанрдагы заманча спектакльләр куелды. Алар хакында һәм труппаның киләчәккә ниятләре турында театрның директоры Фәнис МӨСӘГЫЙТОВ белән сөйләштек.

ТЕАТР –

– Фәнис әфәнде, соңгы елларда күчмә труппа нигезендә барлыкка килгән Тинчурин театрының халыкчанлыгы югала бара кебек.

– Тамашачы төрле яшьтә. Арада совет заманын күргән минем яшьтәшләр дә, Союз таркалгач туган 20–30 яшьлекләр дә бар. 20 яшьлек тамашачы өчен халыкчанлык ни дә, 30, 40, 50, 60 яшьлекләр өчен нәрсә? Әгәр халыкчанлыкны саклыйбыз дип, яңа әйберләр куймыйбыз икән, без хәзерге яшьләрне югалтачакбыз. Ә яңа буыннар үсә тора. Мәдәни мирасны саклап, әмма бүгенге көн алымнары белән эшләү кирәк. Яшьләр белән аңлашу өчен аларга өлкәннәр телен өйрәтү генә җитми, яшьләр телен дә өйрәнү кирәк. Яшьләр кызык булмаган спектакльләргә йөрмәячәк. Ул вакытта кемне тәрбиялисең? Укытучының буш сыйныфка кереп, сабак бирүе кебек килеп чыга.

– Яшьләр телен өйрәнү өчен нинди яңа алымнар кертәсез?

– Мәсәлән, бәби театр әзерләдек.

– Бәрәкалла! «Әкият» курчак театрының икмәген урлыйсыз түгелме?

– Тинчурин театры – өлкәннәр өчен генә дигән фикер белән килешмим. Бәби театр балаларны театр мохитенә тарту, иялләндерү өчен кирәк. Кечкенәдән иялләнсә, тамашачы яшьлегендә дә, олыгайган көнендә дә безне онытмас дип ышанам. Безнең бурыч исә – баштан ук үзебез турында әйбәт фикер калдыру. Моның өчен балалар спектаклендә артистлар ун тапкыр артыграк тырышырга тиеш, чөнки баланы алдап булмый.

– Кайбер белгечләребез, бәби театр бөтән кызык нәрсә таба алмаудан барлыкка килгән, дип бара. Хәтта бу форманы зыянлы саный. Бәби театрда бала-чага артист белән якын мөгамәләгә иялләшә, шунлыктан театр сәнгатенең тылсымы бетә, спектакль барган вакытта балаларның урыннарыннан торып йөрүләре, сәхнәгә менеп китүләре дә шуннан башлана, ягъни тәртипсезлекнең башы – бәби театрда, ди.

– Килешәм дә, килешмим дә. Тамашачы белән тыгыз элемтәдә бара торган спектакльләрне залда түгел, бөтән җирдә куярга кирәк. Аның форматы, миссия башка. Сәхнә, чыннан да, илаһи урын булып калырга, сәхнәгә менү бәхет булырга тиеш. Театр музеенең бер өлешендә, бик матур уңайлы җирдә уйналачак бәби театр нәни тамашачыларыбыз күңелендә җылы хатирәләр калдырыр дип ышанам. «Менә сиңа куш кулым» дип исемләнгән спектакльнең үзенчәлеге тагын шул — аның төп герое – бармаклары булмаган виртуоз-пианист Алексей Романов... Өйдә утырып кына театрга мәхәббәт тәрбияләп булмый. Ә бәләкәйдән театрга иялләшкән кеше сәнгатьне гомер буе яратачак. Бала чагында бер тапкыр да театр бусагасын атлап кермәгән икән, олыгайган көнендә дә спектакль карарга килү ихтималы аз.

– Олырак яшьтәге балаларны нилэр белән кызыксындырасыз?

– Быел режиссерыбыз Туфан Имаметдинов Рүзәл Мөхәммәтшинның әсәре буенча «Асылкош» музыкаль спектаклен куйды. Тамашачы спектакль дәвамында оркестр башкаруында матур музыка тыңлый. Аны Мәскәүдә яшәүче милләттәшебез Зөлфия Рәупова иҗат итте.

Ары китеп, театрыбызда яшьләр өчен кавышу студиясе эшләп килә. Сәхнәдә тәкъдимнәр ясалды, гаиләләр барлыкка килде. Загстан соң килеп, театр бинасында фотога төшү матур гадәткә әйләнде. Борынгы гореф-гадәтләребезгә нигезләнгән сценарий буенча, үзебез барып та теркәү тантанасы үткәрәбез. Кавыштыру чаралары 50-60 яшьтән олыраклар өчен дә булачак. Аларны да махсус сценарий буенча театрга кагылышлы уеннар, гадәт-йолалар белән уздырырга ниятлибез.

Театрда яшь гаиләләр өчен дә уңайлыклар каралган. Әтиәниләре спектакль караган арада, балалар белән яшь белгечләребез шөгыльләнә. Татар телендә китаплар укый, бергәләп телефильмнар карыйлар, рәсем ясыйлар.

Әле күптән түгел театрның колонналы залында танылган дизайнер Нәҗия Галимованың остаханәсен ачтык. Тамашачы спектакль алдыннан экспозицияне карый ала. Н.Галимова театрга килүчеләргә татар костюмы тарихы, аның хәзерге торышы турында сөйли, төрле осталык дәресләре һәм иҗади кичәләр уздыра. Моннан тыш, Нәҗия театрыбызның сәхнә рәссамнарына консультация дә бирә. Беренче уртак эшләрен «Мәдинә» спектаклендә күрергә мөмкин. Әти–әниләр спектакль караган арада студияне «мәдәни няня» сыйфатында файдалану да каралган.

– Тинчурин театры төрле иҗат лабораторияләре уздыра башлаган иде.

– Бу юнәлештә дә эш дәвам итә. Мәсәлән, якын киләчәктә Казан дәүләт консерваториясе белән бергәләп уздырачак «Умай» опера лабораториясе милли драматург, либреттист, композитор, рәссамнарны барлау, аларга ярдәм йөзеннән үткәрелә. Тарих темасына кызыксынуны арттыру, милли җирлектә опера иҗат итүне максат итеп куя. «Умай» дип аталачак бу лаборатория татар хатын-кызы, милли туташларыбыз үткән мәгърифәт, тәрәккыят юлына багышлана. Татар мәдәниятендә хатын-кыз роле мәсьәләсен күтәрә. Нәтиҗәдә, татар телендә бер акттан торган 20 минутлык өч опера иҗат ителеп, аларны трилогия рәвешендә апрель азакларында күрсәтү ниятләнә.

– Моннан берничә ел элек тинчуринлылар музыкаль театр дәрәҗәсенә дәгъва кылып, музыкаль спектакльләр иҗат итә башлаган иде. Бу юнәлештә эш ничек дәвам итә?

– Драматург К.Тинчурин һәм композитор С.Сәйдәшев музыкаль комедия, музыкаль драма жанрларына нигез салып, безгә матур тамашалар калдырган. Бу эшне дәвам итмәү зур югалту булыр иде. Безнең театрда 1953 елга кадәр оркестр чокыры булган, әмма ремонт вакытында аны томалап, тагын ике рәт утыргыч өстәгәннәр. Без оркестр чокырын кайтардык. Сәйдәшев, пианино янына утырып, матур музыкаларын иҗат иткән бүлмә – безнең театрда. Моңа кадәр аны мемориаль бүлмә итеп эшләү ниятебезгә җылыту торбасы комачаулады. Әмма озакламый тарихи бүлмәне тамашачыга күрсәтерлек итеп эшләячәкбез. Элек Сәйдәшев музее театрыбызның бер өлеше булган, академия театры биредә урнашкан елларда андагы бүлмәләр тулай торак буларак файдаланылган. Бүген бу биналарны кабат кушу турында сөйләшү бара. Театр бинасыннан музей ягына чыга торган юл да бар. Без анда театральләшкән кичәләр эшләсәк, музей эше дә җанланып китәр иде. «Сәйдәш. Йокысызлык» спектаклен дә шунда күчерсәк, әйбәт булачак. Музыкаль спектакльләр куяр өчен шәп оркестр җыйдык. Аны талантлы Ильяс Камал җитәкли, әмма музыкантларыбызга урын кысан. Ишегалдында түбәсе черегән декорация склады бар. Аның урынына бинага тоташтырып яңа склад төзесәк, тегүчеләр, балта осталары цехларын, административ составны шунда чыгарсак, артистларыбызга да урын иркенәер, бер гримеркада унар кеше утырмас, оркестр музыкантларына да иркен булыр иде. Төзеләчәк бу бинада экспериментал сәхнә кору уе да бар. И.Камал оркестры спектакльләрдә генә уйнап калмый, артистларыбызны искә алу, иҗат кичәләрендә, башка чараларда да үзен матур күрсәтә. И.Камал елдан артык инде архивлардан композитор С. Сәйдәшевнең моңа кадәр билгеле булмаган әсәрләрен табып, партитураларын цифрлаштыру белән мәшгуль. Бу эш бөек композиторыбызның иҗатын тулырак күз алдына китерергә мөмкинлек бирәчәк. Ильясның бирелеп эшләвенә сокланып туймаслык. 30 секундтан алып 1 минутка кадәр дәвам иткән кечкенә әсәрләрне дә калдырмыйча, бик җентекләп Сәйдәшев мирасын барлый. Дөресен әйткәндә, Тинчурин театрының кыйбласын үзгәртеп, музыкаль театрга әйләндерү турында сүз булмады бит. Репертуарга музыкаль тамашалар – мюзикл, оперетталар кертү турында сүз барды. 90 ел тарихы булган драма һәм комедия театрының асылын алыштыру мәсьәләгә җиңел карау булыр иде. Кемдер бу мәсьәләне махсус болгата, дип саныйм. Өстебезгә алган йөкләмәне уңышлы алып барабыз, минемчә. «Кара урман», «Асылкош», «Башмагым» спектакльләрен тамашачы бик яратты, «Кара пулат» шулай ук театрыбыз тарихына кереп калды. Шагыйрь, язучы Җәвад Тәрҗеманның 100 еллыгы уңаеннан чыгарылган композитор Алсу Сөнгатуллинаның балалар өчен җырлары тупланган «Балачак дөньясы» җыентыгын тәкъдим итү күп җыр сөючеләрдә кызыксыну уятты. Гомумән, балаларны театрга җәлеп итүнең иң отышлы юлы – музыка дип саныйм.

● Тинчурин театрының Мәскәү каласына гастрольләре вакытында тәүге спектакльне тәкъдим итү.

– «Могҗиза» балалар студиясенең эше турында да беләсе килә.

– Мөмкинлекләре чикле балалар өчен «Могҗиза» студиясе биш елга якын эшли. Аны Татарстанның халык артисты Зөфәр Харисов җитәкли. Администратор Зөлфия Бәшәрова, яшь артистлар Гөлназ Нәүмәтова, Салават Хәбибуллин да күңелләрен биреп катнаша. Өч-дүрт конкурста җиңделәр. Артистларыбыз ис китеп дәресләрен, спектакльләрен карый. 24 сәгать хастаханәдән реабилитация

тамаша гына түгел

үзгәнә, театрга, тегендә-монда чапкан ул балаларның әти-әниләренә һәйкәл куярлык. Балалар үзләре бик саф күңелле, мөлаем һәм таза-сау кешеләргә караганда да берләшебрәк эшли. Проект Альбина Сәлимгәрәева җитәкчелегендәге «Во благо» фонды белән, аларның матди ярдәмнәре белән тормышка ашырыла. Яңа спектакльне үзебезнең артистлар белән катнаш итеп әзерлибез.

– Яшь буын өчен шулкадәр кызыксындыру чаралары каралгач, тамашачы да яшәрә төшкәндер, мөгаен. Сан ягыннан артуы да ихтимал.

– Коронавирус котырган айларда залны яртылаш кына тутыру рөхсәт ителде, ни чарадан бичара ишегалдында спектакльләр куя башладык. Аларны тамашачы бик яратты. Әмма шыгрым тулы залны күрүдән дә күңеллерәк нәрсә юк. Театрда яшьләр артты. Моңа Пушкин картасын кертү дә ярдәм итте. Ай саен сатыла торган билетның якынча илле проценты Пушкин картасы белән сатып алына. Әмма ни кызганыч, 14-22 яшьтәге һәр яшүсмергә Пушкин картасы бирелсә дә, бөтенесе дә аннан файдалана алмаска мөмкин. Күп авылларда клуб юк. Бу очракта, кулыңда карта булса да, берни эшләп булмый. Шуңа күрә без үткән елдан бирле районнарда, кечерәк авыллардан балаларны мәдәният йорты булган зурракларына җыеп, тамашалар күрсәтәбез. Якынтирә районнардан Арча, Әтнә, Питрәч, Лаеш, Апас, Яшел Үзән, Чүпрәле һәм башкаларында, Чувашия, Ульяновскида булдык. Чит сәхнәләрдә декорация кору безнең өчен өстәмә, четерекле эш булса да, сәхнә бизәлешләрен җиңеләйтеп, яшүсмерләргә эчтәлеге туры килә торган әсәрләр сайлап, тамашалар күрсәтүне дәвам итәбез. Балаларга яратып күрсәтә торган М.Мәһдиев әсәре буенча куелган «Без – 41 нче ел балалары», олуг шагыйрь Г.Тукай иҗатына нигезләнгән «Сөй гомерне!» спектакльләребез бар. Бүген Г.Камалның «Беренче театр»ын сәхнәләштерәбез. Киләчәктә инвалидлар, пенсия яшендәгеләр өчен карталар чыгару турында сүзләр йөри. Без анысына да әзер булырга тиеш.

– Өлкән буын тамашачы борчуга сала да инде. Театрда яшьләр өчен бөтен уңайлыклар тудырылып, өлкән яшьтәге тамашачы игътибардан читтә кала түгелме?

– Нигә? Репертуарыбызда өлкәннәр өчен дә матур спектакльләр җитәрлек.

– «Полиционер»мы?

– «Полиционер»га ни булган?

– Безнең илдә хокук структураларына чамадан артык вәкаләтләр, акча бирелү трагедиягә тиң. Ә сез комедия куясыз...

– «Полиционер» – авыл участковые, авыл кешеләре турында самими спектакль. Аның каршылыклы фикерләр уятуы әйбәт. Сәнгать фикер уятырга тиеш. «Полиционер»ны өлкән буын яратып карый. Бу иҗат фасылында куелган «Кияү урлау»ны да яраталар. Моңа кадәр репертуарда булган «Өч аршын җир», сугыш елларында хатын-кыз язмышына багышланган «Утка очкан күбәләктәй» һ.б. кайбер спектакльләргә шулай ук күбрәк өлкән буын килә. Киләчәктә Т.Имаметдинов «Идегәй»не куячак. Матбугатта, сатлыкҗан турында спектакль куйганнар, дип язып чыксалар да, тамашачыны уятырга, уйландырырга бер сәбәп ул... Драматургия лабораториясендә Р.Зәйдулланың «Ашина» әсәре буенча эскиз иҗат ителгән иде, аны жюри да ошатты. Шуны тулы канлы спектакль итеп куймакчыбыз. Бу әсәрдә буалар корганда авылларны су басу темасы күтәрелә. Ул шулай ук өлкән буын тамашачыларга кызык булыр. Илгиз Зәйниев куйган «Мәдинә» спектакле дә тамашачыларга ошар дип өметләнәм. Анда автор һәм режиссер «Медея» борынгы грек мифы вакыйгаларын татар җирлегенә күчергән, үзеннән дә өстәгән. Пьеса ак шигырь жанрында иҗат ителгән. Баш рольне театрыбызның әйдәп баручы артисткасы Резидә Сәлахова башкара.

– Фәнис әфәнде, бүген Тинчурин театрының йөзе нинди?

– Йөз процент татарча, бернинди акцентсыз, чиста, саф сөйләшүче артистларыбыз. Араларында җырлаучы һәм төрле музыка уен коралларында уйнаучылар бар. Безнең бренд ул – тарихи бина. Бу диварлар Тинчурин, Сәйдәшев, бик күп танылган артистларыбызның рухын саклый. Музеебыз белән горурланам. Без аны Мәскәүдәге атаклы Бахрушин исемендәге театр музеена өйрәнергә йөреп, аның белән экспонатлар алмашып кордык. Төрле яшьтәге тамашачыларга исәпләнгән бай репертуарыбыз бар. Халыкчан, җылы спектакльләр дә җитәрлек. Намаз уку бүлмәсе – безнең театрда гына. Артистларыбызның байтагы намазда. Якын киләчәктә исә Россиянең бер театрында да булмаган яңалык кертәчәкбез. Тик әлегә сер булып калсын...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Әдәпле әдәби җан

Әлегедәй хәтеремдә: туган авылым Түбән Тегермәнлек башлангыч мәктәбендә 3 ел укыганнан соң Югары Тегермәнлек урта мәктәбенә 4 нче сыйныфка белем алырга йөри башладык. Шул белем йортында иң беренче тапкыр, нинди хәлләрдә калганда да, сүзе, киңәше, эше белән ярдәм итүче укытучым Рамазан абый белән таныштым. Күркәм яшь мөгаллимебез, яңа гына югары уку йортын тәмамлап, укытырга туган мәктәбенә кайткан иде. Укучылар арасында Рамазан абый аң-белеме, ыспайлыгы, таләпчәнлеге белән бик тиз абруй казанды, дәресләрендә яңа укыту төрләрен еш кулланып, белем үзләштерүне мавыктыргыч итеп җанландыра иде.

Еллар арты еллар уза торды, мәктәп бусагасыннан чыгып киткәч тә хөрмәтле укытучым белән араларны өзгәнем булмады, вакытлы матбугатта чыккан иҗат җимешләре белән даими танышып бардым. Кайда гына көч салмасын (озак еллар җирле үзидарә рәисе, социаль приют директоры, мәктәп директоры булып эшләде) Рамазан Ибраһим улы үз эшен җиренә җиткереп башкара иде.

Татар теле, әдәбиятын үстерү, аны баету, халыкка аңлатуда мөхтәрәм Рамазан абый Кәбировның зур өлеш кертүе безнең район белемәләрендә генә түгел, бөтен республикабызга билгеле. Тормыш иптәше, татар теле һәм әдәбият укытучысы Рушания апа белән Рамазан абый, ачык дәресләр уздырып, якташларым шагыйрь Вазыйх Фатыйховка, шагыйрә Рәсимә Гарифуллинага тәүге китапларын тәкъдим иткәндә зур ярдәм күрсәттеләр.

Рамазан абый нинди җирдә генә хезмәт итсә дә әдәби, фәлсәфи темаларны яңа төрдә ачкан ачык укулар, район һәм республикакүләм фәнни конференцияләр буласын көт тә тор инде!

2020 елда безнең якташларыбыз булган күренекле каләм әһелләренә багышлап «Балык Бистәсе төбәге мәгърифәтчеләре» дигән җыентык әзерләп бастырдылар, шул ук елны Рамазан абыйның «Татар әдәбиятында Бөек Ватан сугышы темасының чагылышы» исемле китабы да дөнья күрде. Озакка сузмыйча, ул әдәби тәнкыйтькә бәйле язмаларыннан, иҗат бәяләмәләреннән гыйбарәт «Әдәби хакыйкать» дигән мәҗмугасын бастырды. Бер-бер артлы табадан төшкән сый-җимешләренә сокланмый мөмкин түгел! Рамазан абый миңа сер итеп кенә хәзер «Сугышта һәм сәхнәдә язылган язмышлар» исемле китабын төгәлләп килгәнен дә белдерде.

Рушания Әюп кызы һәм Рамазан Ибраһим улы Кәбировларның кырык елдан артык татар теле һәм әдәбиятында эзләнүләре, уку-укытуда методик ачышлары, хезмәтләре югары бәяләнде, алар икесе дә – Татарстанның атказанган укытучылары, Рамазан абый Татарстан журналистлар берлеге әгъзасы, Кадыйр Сибгатуллин исемендәге әдәби премия лауреаты, Татарстанның Мәскәүдәге вәкиллеге тарафыннан Муса Җәлилнең 110 еллыгына чыгарылган медаль белән бүләкләнде.

Газета-журналларда Рамазан абыйның әдәби эзләнү, тәнкыйтьче, тел галиме буларак язмалары басыла килә, аның каләменең үткерлеген мактап, галимебез профессор Фоат Галимуллин, олпат шагыйрь, язучыларыбыз Равил Фәйзуллин, Әхәт Сафиуллин, Шаһинур Мостафиннар күп җылы сүзләрен язды. Якташ язучыбыз Әхәт Гаффаровның бәяләмәсенә игътибар юнәлтәсем килә, Әхәт абый болай диеп яза: « ...Рамазан Кәбировның мәкаләләренә,китапларына аерым-аерым тукталып тормастан, аның татар әдәбиятына, аның халкыбыз, милләтебез бөтенлегенә керткән өлешенә мөкиббән икәнлеген, шуның белән рухланып, горурланып иҗат иткәнлеген мин җаным- тәнем белән дигәндәй рәхмәт хисләре белән искә алам...»

Гомер уза, күлмәк туза! дисәк тә, бу әйтем Р. Кәбировка кагылмый кебек, чөнки ул 65 яшен тутырса да, һаман да егетләр кебек, уй-фикерләре ташып тора, иҗаты елдан-елга түгел, айдан-айга, көннән-көнгә канатланып оча бара.

Роберт ШӘЙМӘРДАНОВ,
шагыйрь, автор башкаручы.

Атнаның сәяси мизгелләре

ДУСТАНӘ БУЛМАГАН МӨНӘСӘБӘТЛӘР

Австрия канцлеры Карл Нехаммер Мәскәүгә сәер сәфәр кылып китте. Россия президенты В.Путин белән очрашу, аның үтенече буенча, ябык ишекләр артында, тәрҗемәчеләрсез, беркетмә чараларыннан (камера алдында кул кысышу, матбугат өчен белдерүләр ясау һ.б.) башка гына үткән. Мәгълүм вакыйгалар башлангач, бу – Европадан дустанә булмаган ил башлыгының Мәскәүгә беренче сәфәре икән. Соңыннан канцлер үзе әйтүенчә, сөйләшүләр ачык, турыдан бәреп һәм катгый рухта үткән. Анда сүз күбрәк Украинадагы гуманитар хәл һәм кискен вәзгыять турында барган. В.Путинны ул Украина территориясендәге хәрби хәрәкәтләрен кичекмәстән туктатырга чакырган, ә туктатылмаган очракта, Европа Берлеге санкцияләре тагы да катгыйланачагы турында кисәткән. Тик кайбер сәяси күзәтүчеләр Нехаммерның Мәскәүгә яңа шартларда газ мәсьәләсен (ә бу ил 80% газны Россиядән ала) хәл итү өчен килүенә дә ишарәли. Сәфәрдән соң ул Венага әйләнеп кайткач, Австрия, Алмания һәм Венгрия үзләренең Россия газына эмбарго игълан итүгә каршы булуларын да белдергәннәр.

Рәсми хәбәрләрнең башкаларына килгәндә, аларда яктыртылган сәяси вакыйгалар да, нигездә, Украинадагы хәлләр белән бәйле. Әйтик, Европа дипломатиясе башлыгы Жозеп Боррель Европа Берлегенең Украинадагы конфликтны көч кулланып хәл итәргә омтылуы турында белдергән. Мәгәр, башка хәбәрләр дә куанычлы түгел. Әлбәттә, югалтуларсыз гына да булмый (бу хакта хәбәрләр даими бирелә). Аларның зурларына килгәндә, әйтик, узган атнада Мариупольдә Украинаның меңнән артык сугышчысы әсир төшкән. Россиянең дә Кара диңгез флоты флагманы саналган “Москва” ракета крейсерында, “янгын чыгу сәбәпле сугышчан запас шартлап”, фаҗига килеп чыккан. Ярый ла әле аның экипажын коткарып кала алганнар. Украинадагы хәрби операция фонында, Финляндия һәм Швеция быел җәй НАТО составына әгъза булып керергә җыенуы да мәгълүм.

Игътибарны исә күбрәк, мәсьәләнең хәрби ягы җәлеп итә. Соңгы чорда Көнбатыш илләре Украинага инде авыр сугыш коралларын белән дә ярдәм итә башлады. Элегрәк АКШ совет чорында эшләнгән “Оса” дигән зенит-ракета комплекслары (ЗРК) белән генә ярдәм итсә, хәзер ул Киевне хәрби аэродромнарны да юк итәргә сәләтле оператив- тактик максатлы ракета комплекслары белән дә тәэмин итәргә җыена. Узган атнада ул Украинага 800 миллион долларлык хәрби ярдәм (ә анда 200 берәмлек М113 бронетранспортеры, үзйөрешле 18 гаубица, танкларга каршы 300 үзочкыч-камикадзе Switchblade, 500 Javelin ракетасы, 11 берәмлек Ми-17 боралагы керә) күрсәтәчәге турында белдерде. Украинаның Донбасстагы гаскәрләрен камап алу ниятендә, Россиянең дә анда хәрби көч туплавын исәпкә алсак, алда торган вакыйгаларның колачын чамалавы кыен түгел.

Фоат УРАЗАЙ.

МӨСЛИМ – миллилек өлгесе

Мөслим районы – телебезне, гореф-гадәтләребезне, милли йолаларыбызны саклауда да үрнәк районнарның берсе. Бу Бөтендөнья татар конгрессының «Ак калфак» оешмасы катнашында узган «Милли тәрбия – җирлегебезнең киләчәге» дигән җыенда да ачык күренде.

Район белән танышу Туган якны өйрәнү музееннан башланды. Директор Назилә Бәдертдинова искәрткәнчә дә, Мөслим районы – кешеләр гомер кичергән бик борынгы җирләр. Археологик тикшеренүләр вакытында район җирлегендә кешеләр яшәгән таш, бронза чор, тимер дәвер башларыннан алып урта гасыр ахырларына караган урыннар табылган. Борынгы ядкәрләр арасында скиф акинагына кадәр бар. Мәҗүсиләрдән калган бизәнү әйберләре дә бик кызыклы. Ә инде археология залындагы мамонт баш сөяге, умырткалары, казык тешләре Мөслим районы җирләрендә кайчандыр йонлач мөгезборыннар да яшәвенең күрсәткече.

Бу якның “Мөслим каракатицасы” дип йөртелә торган чигү бизәге үзенчәлекле. Аны белгечләр Казанга алып китеп тикшергән, мондый бизәкнең Мөслимдә генә булуын әйтеп кайтарганнар. Музейдагы 1930-1940 еллардагы татар өе дә җирле осталарның тамбур җөе белән чигелгән җете бизәкләре төшерелгән пәрдәләр, мендәрләр, япма-җәймәләр белән ямьләндерелгән. Музейчылар үзләре дә борынгы япмадагы бизәкләрне кулланып чигәргә өйрәнгән.

Өйдәге сандык исә элеккерәк елларда Мөслимгә генә хас үзенчәлекле йоланы искә төшерә. Кәләш туй алдыннан үзенең дус кызлары белән бергә бирнә сандыгы тутырган. Кыз кияүгә чыкканчы, чигүле әйберләре күп, бирнәсе бай булса, менә шундый уңган килен килә, дигән хәбәр таралган. Ә бирнәне әниләр яңа туган кызына 40 көн тулуга ук җыя башлаган. Бу йола Мөслим якларында 1960-1970 елларга кадәр яшәгән әле.

Сәүдә лавкасына куелган борынгы аяк киемнәре, балаларның уен почмагында күрсәтелгән шәмәй уены да, элеккеге көнкүреш әйберләре дә бик кызыклы. Махорка ясый торган җайланма, үзенчәлекле кишер кыргыч та – сирәк ядкәрләрдән. Туган якны өйрәнү музее гаять бай, хәзерге көндә анда борынгы һәм Мөслимнең күренекле кешеләренә, тарихи вакыйгаларга кагылышлы 10 мең 225 ядкәр саклана.

Районның үзәк китапханәсе дә көн таләпләренә туры китереп җиһазланган. Аның залларына ачык форматта заманча стеллажлар куелган. Китапханәдә шулай ук интернет, балалар зоналары да яңартып эшләнгән. Китапханәдә шигырь язучы балалар өчен шагыйрь Зөлфәт Маликов түгәрәге эшләп килә. Аларның иҗатларын туплап дүрт ел эчендә “Кояшлы Ык” һәм “Талантлы син туган җирем”дигән ике китап бастырып чыгарганнар. Китапханә тарихы китабын да әзерләп нәшер иткәннәр. Грантлар, проектлар белән эшләүгә дә әһәмият бирелә. Китапханәдә 58 мең китап бар. Фонд даими яңартылып тора. Елына биш меңнән артык китап кайта.

Мөслимнең Г.Тукай исемендәге мәктәбендә 510 бала, кызлар һәм малайларга бүлеп, аерым укытыла. Башлангыч сыйныфларга белем саф татар телендә бирелә. Югары сыйныфларда, бердәм дәүләт имтиханын истә тотып, терминнарның русчасы да өйрәнелә. Татар теле һәм әдәбияты исә атнага 4-5 дәрес кертелә. Элекке парталарны бүгенгеләре белән янәшә куеп корылган музей исә бу мәктәптә Рәис Шәйхелисламов, Васил Гайфуллин кебек министрлар белем алуын искә төшерә. Муса Җәлил дә бу мәктәпнең спорт залында кунып киткән булган.

“Кояшкай” балалар бакчасында балалар калфак һәм түбәтәй өчен милли бизәк ясау буенча осталык дәресендә шөгыльләнә. Бирелә төп тәрбия татар телендә алып барыла, рус теле мәктәпкә әзерлек төркемендә дәрес буларак кертелә. “Кояшкай” Татарстанның «Иң яхшы 10 балалар бакчасы» дигән исемлеккә дә кергән.

Мөслим районы балалар бакчаларында, мәктәп-гимназияләрендә милли гореф-гадәтләребезгә, йолаларыбызга, туган якларының шәхесләрен зурлауга игътибар бирелүен район мәдәният йортында тәкъдим ителгән күргәзмәдә дә күрергә мөмкин иде. Мәдәният йортының тамаша залына күз төшергәч тә күңелгә бер җылылык таралды. Залны тутырып ак калфаклы ханымнар утыра иде. Татарстанның халык язучысы Фоат Садриев, аның җәмәгате Сәйденур Садриева, шагыйрә Лилия Садриеваны утырыш дәвамында сәхнә түренә утыртып зурлаулары исә – районда әдәбият, сәнгать әһелләренә, танылган шәхесләргә аерым игътибар булуы, яшьләргә аларның өлге итеп куелуының тагын бер мисалы.

2014 елдан үткәрелә башлаган Фоат ага Садриев укулары проекты да туган телгә, милләткә ихтирам тәрбияләүне күздә тота. Фоат ага Садриев та баланың илдәге мохитнең нинди булуына карап тәрбияләнүен ассызыклады. “Без әтидән, әниләрдән үрнәк алып үстек, җәй көннәребез басуда үтте. Безне үрнәк тәрбияләде. Эшләмәсәң бер әйбер дә булмавын без белә идек. Кешегә хезмәте бәя бирә, аны хезмәт кенә кеше итә”, – диде ул. Әмма язучыны соңгы елларда илдә хезмәтнең әһәмияте югалып баруы борчый. Фоат ага шулай ук “Ак калфак” оешмасының соңгы елларда ак калфакны халык әхлагы, намусы символы дәрәҗәсенә күтәреп килүе күркәм эш булуын белдерде.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Аһәңле тавышы күңелләрдә

Рамазан аеның унөченче көне кайгылы хәбәр китерде. Татарстан дәүләт радиосының кабатланмас тавышлы дикторы, ягымлы сөйләме белән милләттәшләребезнең якын, үз кешесе булып әверелгән Мәрьям апа Арсланова бакыйлыкка күчте. Күпме генә яшәсәк тә, гомер дигәнең чикле шул. Мәрьям апабыз әллә йөзне тутырырмы дип уйлап йөргән идек, туксан алты яшендә – табигать уянган, кояш көлеп караган бер вакытта – җир куенында мәңгелек урынын алды.

Моннан ун ел элек ул мине өенә чакырып алды.

– Менә истәлекләр язган идем, карап чык әле. Бу язмаларны, бер җаен табып, халкыбызга, дус-ишләргә җиткереп булмасмы икән?

Әлеге язмалар белән танышкач, шушы бик тә зыялы, киң карашлы, күңеле бары тик җылы нурлар белән генә тукылган бу ханымның да үткән юлы никадәр катлаулы булганлыгын күреп, ис-акылым китте.

"Кемерово өлкәсендәге Юрга дигән станциядән ике-өч чакрым гына ераклыкта урнашкан Сарсаз дигән татар авылы бар, – дип башлана ул. – Шул авылда, Рәсәйдән күчеп килеп, газиз телләрен, мөселман тәртипләрен саклаучы татарлар яши иде. Авыл халкы фәкать татарча гына сөйләшә. Матур ак каенлык эчендә кечкенә генә мәчет авылга ямь биреп тора. Бөтен мөселман бәйрәмнәрен авыл халкы зурлап уздыра торган иде. Әниемнең әтисе Даут бабай сөйләгәннәр истә калган. "Безне Микулай патша, поездга акча түләтмичә, Себергә җибәрде, җир бирде", дия торган иде.

Землянка казып, бик авырлыклар белән яши башлыйлар. Авылга да үзләре ягы исемен – Сарсаз дип кушалар". Мондый хәл-әхвәлләр бәян ителгән истәлекләр минем уй-хисләремне бөтереп алды. Безнең татарга кайсы гына дәвердә дә яшәү шартлары гаять катлаулы булган. Бу язмалар да моның бер көчле дәлиле. Кереш сүз язып, кызлары Гөлнар, Алсу белән бергәләп, замандашларының аның хакында матбугатта ясаган чыгышларын һәм истәлекләрен җыеп, гаиләләре архивыннан фоторәсемнәрне туплап, нәшриятка тапшырдык. Ниһаять, бу язмалар 2013 елда китап хәлендә укучыларга ирештерелде. Әлеге авыр хәбәр килеп ирешкәч, ярый әле бу эшне вакытында җиренә җиткергәнбез, дип куйдым.

Без үскән елларда радиода берсеннән-берсе матур итеп Камал Саттарова, Әминә Сафиуллина, Айрат Арсланов дигән дикторлар сөйли иде. Мәрьям апаның тавышын эфирдан беренче тапкыр армиядә хезмәт иткәндә генә ишеттем. Минем анда радиостанция начальнигы булып эшләгән вакытым. Безнең экипаж, урман куенына урнашып, өйрәнү очышлары ясаучы самолетлар белән элемтә тәэмин итә. Якшәмбе булу сәбәпле, ул көнне очышлар юк, шуңа күрә без дә ял итәбез. Мин әкрен генә радио боргалап утырам. Ниһаять, кирәкле дулкынны табам. Бик матур тавышлы апа татарча сөйли! Моңарчы бу ханымның сөйләгәнен бер дә ишеткәнем юк иде. Җыр тыңлаган кебек, аның һәр сүзен йотып барам. Рузаевкадан килгән мукшы егете Матвей да уянган икән. Ул әйтеп куйды:

– Татар теле радиодан нинди матур яңгырый икән!

Аңа рус егете Андриан кушылды.

– Сезнең Мәскәүдән сөйләүче Ольга Высоцкая дигән апаның сөйләгәнен дә тыңлаганыгыз бардыр. Бу татарча сөйләүче апаның тавышы нәкъ Мәскәү дикторыныкы кебек, әйеме?..

Ул вакытта, армиядән кайткач, Казан радиосына эшкә килермен дә, шушы Мәрьям апа Арсланова белән бергә эшләрмен дип кем уйлаган?

Хәер, Мәрьям апа үзе дә кайчандыр Татарстанның төп микрофоны алдына утырып сөйләрмен дип башына да китермәгәндер. Себергә бернәрсәсез килеп тә үз кул көчләре белән ару тормышлы булып әверелгән әби-бабаларын утызынчы елларда, кулак дип талап чыгып, хәерчелеккә дучар иткәч, бик авыр хәлләрдә калалар. Шул фаҗигаләргә әти-әниләренең тормыш юллары аерылу да өстәлгәч күргән михнәтләр онытылырлыкмы соң? Казанга килеп, театр техникумында ачлы-туклы укыган елларның авырлыгын ул куркыныч төш кебек итеп сөйли торган иде. Аның каравы нәкъ менә шушында ул үзенең мәхәббәтенә юлыга. Юллары Башкортстанның Бүздәк төбәгеннән килеп биредә укучы Айрат белән очраша. Күренекле җырчы Усман Әлмиев бу турыда болай дип искә алып яза: "Айрат Арсланов Таҗи Гыйззәтнең "Ташкыннар" әсәрендә Мирвәли ролендә уйнады. Мәрьям Фәйзуллина исә атаклы артисткабыз Фатыйма Ильская башкарган Айсылу ролендә иде. Миңа аның уйнавы бик ошады. Айратка мин, шул артисткага өйлән, дип әйтә идем. Ул минем сүзне тыңлады. Өйләнештеләр, әйбәт гаилә кордылар. Гөлнар, Алсу исемле балалары туып, һәркайсы эчке культуралы бик уңган кызлар булып үстеләр". Шулай булмый мөмкин дә түгел. Әти-әниләре укымышлы, талантлы, чын мәгънәсендә зыялы шәхесләр. Гаилә артистлар, язучылар, галимнәр, күренекле затлар белән даими аралашып яши. Өйдә әдәби әсәрләр, спектакльләр, фәнни ачышлар һәм юнәлешләр турында сөйләшүләр тынып тормый. Мәрьям апаның кулында еш кына яңа китаплар, нинди дә булса бәхәс уята торган әйберләр басылган газета-журналлар булыр, аларны безгә дә укытыр, аннан соң фикер алышу оештырыр. Аның белән аралашу үзе бер мәктәп иде.

Ул болай да бик мәгълүматлы кеше, әмма өстәлендә төрле сүзлекләр торыр. Аларны карап-карап алыр, сүзләрнең әйтелешен, мәгънәләрен исенә төшерер. Микрофон алдына үзенә нык ышангач кына утырыр. Боларның һәммәсе безгә үрнәк була торган иде. Аның белән соңгы хәбәрләр, матбугатка күзәтүләр уку, яшьләр, балалар өчен махсус тапшырулар алып бару синең дә иҗади үсешеңне тәэмин итә. "Тел күрке – сүз" тапшыруларын алып бару бер бәйрәм булып әверелә. Татарстан радиосы фонотекасында М. Арсланова укуында йөзләрчә-йөзләрчә тапшырулар саклана. Алар күп еллар буе яңгырап торыр әле.

Безнең хезмәттәшебез шагыйрь һәм язучы Җәүдәт Дәрзамановның бер әсәрендә мондый юллар бар:

Ил күрке – күз,
Тел күрке – сүз, беләбез...
Мәрьям ханым,
Ил күрке Сез, беләбез!
Яхшы сүздән якты булды
юлыгыз...
Һаман шулай халык кызы
булыгыз!

Әйе, Мәрьям Ислам кызы Арсланова халык кызы булып яшәде, шулай булып мәңгелеккә дә китте. Урыны җәннәттә булсын.

Фоат ГАЛИМУЛЛИН.
13.04.2022

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

23 апрель (шимбә). ***Рамазан аеның 22 нче көне. 22 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында,2.35 сәгатьтә калка, 8.57 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы сәгать.***

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

Сихәтле чәй

Чәйнең туган җире булып Кытай һәм Һиндстан санала. Кытайларда: "Бер көн чәй эчмичә торганчы, өч көн ашамыйча торуың яхшырак", – дигән мәкаль бар. Тик чәйне кайнар килеш эчү генә файдалы. Чәй сусауны баса, ризыкны эшкәртүгә булыша, организмнан токсиннарны чыгара. Анда 500 гә якын микроэлемент, аксым, аминокислота, углевод һәм витамин бар. Мәсәлән, чәйдә ананас һәм кишердәге кадәр үк микъдарда А витамины исәпләнә. Көн саен чәй эчү организмны С витаминына туендыра, җәй көне исә тир белән бүленеп чыккан кальций микъдарын тулыландырып тора.

24 апрель (якшәмбе). ***Рамазан аеның 23 нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 3.04 сәгатьтә калка, 10.27 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 14.50 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

Ангинадан – җиләк яфрагы

Кура җиләге яфрагы төнәтмәсе ялкынсынуны киметә, ашказаны-эчәк, сулыш юллары авыруларын җиңеләйтә. Ангина вакытында тамакны чайкау өчен дә сихәтле. 2 аш кашыгы киптереп вакланган яфракны 1 стакан кайнар суга салып, җылы урында 1-2 сәгать төнәтәләр. Сөзеп, чәй урынына эчәләр яки тамакны чайкыйлар. Бу – бронхит, стоматит, фарингит булганда да бик шәп дәва.

25 апрель (дүшәмбе). ***Рамазан аеның 24 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 3.23 сәгатьтә калка, 11.58 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 14.55 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

Тырнак гөл шифасы

Катарактадан (күз ясмыгы тукымасы тоныкланудан) интегүчеләргә тырнак гөл (календула) ярдәм итә. 3 аш кашыгы киптереп вакланган чәчәкне термостагы ярты литр кайнар суда 1-2 сәгать төнәтәләр, сөзәләр, көненә 3 тапкыр яртышар стакан эчәләр. Шушы төнәтмә белән күзләрне юдыру да файдалы.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

26 апрель (сишәмбе). ***Рамазан аеның 25 нче көне. 25 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында,3.36 сәгатьтә калка, 13.26 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 14.59 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Борынны юдыру

Томау дарулары күп төрле булса да, араларында файдалысы аз. Иң гади һәм нәтиҗәле чара – борын куышлыкларын юдыру. Ярты стакан кайнаган суга ярты чәй кашыгы тоз, чирек чәй кашыгы сода салырга, 1-2 тамчы йод тамызырга да, шуның белән тамак өстен көненә 3-4 тапкыр юдырырга кирәк (бер борын тишеген томалап, икенчесе белән тозлы суны эчкә суырып алалар һәм авыз аша чыгаралар).

27 апрель (чәршәмбе). ***Рамазан аеның 26 нчы көне.26 нчы Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 3.45 сәгатьтә калка, 14.50 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 15.04 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Теш дәвалату өчен начар вакыт. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

28 апрель (пәнҗешәмбе). ***Рамазан аеның 27 нче көне.27 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында,3.53 сәгатьтә калка,16.11 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 15.08 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

Күзне “сыйлау” зарур

Күз күреме начараймасын өчен, дөрес туклану мөһим. Көн саен күрәгә яки өрек, как яки йөзем, кишер яки кабак ашарга тырышу зарур. Петрушка, укроп, яшел суган, кукуруз да бик файдалы. Эчемлекләрдән яшел чәйгә, дуләнә төнәтмәсенә өстенлек бирергә кирәк. Иң әйбәт иртәнге аш исә – уылган кишергә каймак яки үсемлек мае сибеп ашау.

29 апрель (җомга). ***Рамазан аеның 28 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 4.01 сәгатьтә калка, 17.32 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 15.12 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

Шоколадлы печенье

4 йомырка, 300 г шикәр, 110 мл көнбагыш мае, 240 г он, 100 әр г какао һәм шикәр оны, 1 чәй кашыгы камыркөпшәкләндергеч, 0,5 чәй кашыгы тоз кирәк. Йомырка белән шикәрне күпертәсең, май, он, какао, камыркөпшәкләндергеч, тоз кушып яхшылап басалар, өстен целлофан белән каплап, 1 сәгатькә суыткычка куеп торалар. Әстерхан чикләвеге зурлыгындагы шарчыклар ясап, шикәр онында әвәлиләр, пергамент кәгазе җәелгән табага тезәләр дә, 180 градуслы газ мичендә 25 минут пешерәләр.

Пропаганда остасы

Язучы, журналист Ягъсуф Долмаган улы Шәфыйков – күренекле шәхес. Ил тормышының узгандагы һәм хәзерге вакыйгаларын, фактларын анализлаган репортажлары, әңгәмәләре, очерклары, публицистик мәкаләләре республикабызның төрле басмаларында еш дөнья күрә.

Мөселманнарның изге китабы – Корьәннең татар һәм рус телләренә тәрҗемәләре тарихына һәм күренекле тәрҗемәчеләренә багышланган «Мин бер могҗизаны беләм» исемле рус телендәге китабы республиканың мәдәни тормышында бер вакыйга булды. Авторның «Гасыр ахырында 17 әңгәмә» дигән китабы да «бәхетле» булып чыкты. Ул тиз арада укучыларын тапты. Кызганыч, 22 февральдә озакка сузылган каты авырудан соң ул безнең арадан китеп барды. Ел башында гына Ягъсуф 85 яшьлек юбилеен үткәргән иде.

Я.Шәфыйков 1937 елның 1 гыйнварында Актаныш районының Түбән Карач авылында колхозчы гаиләсендә туа. 1952 елда гаиләләре белән Удмуртиянең Сарапул шәһәренә күченеп килә. Ит комбинатында эшли, параллель рәвештә училищеда суыткыч җиһазлары механигы белгечлеген үзләштерә. 1960-1963 елларда армиядә хезмәт итә. Шул чорда хәрби газеталар өчен мәкаләләр яза башлый.

Армиядән кайткач Ягъсуфкә Сарапул шәһәренең «Красное Прикамье» газетасында бүлек мөдире вазифасын тәкъдим итәләр. 1970 елда «Удмуртия» нәшриятында «Твои земляки» дип исемләнгән беренче очерклар җыентыгы дөнья күрә.

1972 елда аны КамАЗ төзелешенә җибәрәләр. Монда ул профсоюз комитеты рәисе, төзелеш оешмасы башлыгының кадрлар һәм көнкүреш мәсьәләләре буенча урынбасары булып эшли. 1976 елда чираттагы комплексны файдалануга тапшыргач, «Главмосстрой оешмасы белән бергә Я.Шәфыйковны Ростов өлкәсенә Волгодонскидагы атом электр станциясе төзелешенә җибәрәләр. 1983 елда бу оешма тагын яңа төзелешкә керешә – Краснодар краендагы атом электр станциясенә нигез сала.

1991 елның декабрендә Ягъсуф яңадан журналистикага, иҗат эшенә әйләнеп кайта. Аны «Татар-информ» агентлыгының Төньяк Кавказдагы махсус хәбәрчесе итеп куялар. Аңа Краснодар, Ставрополь крайлары, Адыгей Республикасы, Ростов һәм Волгоград өлкәләрендә татар тормышын яктырту бурычы йөкләнә. Я.Шәфыйков «Татарские края», «Татар иле» газеталары хәбәрчесе булып та эшләп ала.

Үткән гасырның туксанынчы еллар ахырында Ягъсуф Казанга кайтты. «Татарстан» иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни журналында бүлек мөхәррире булып эшләде. Мин ул чорда баш мөхәррирнең беренче урынбасары идем. Я.Шәфыйков яхшы әзерлекле, үз-үзенә бик таләпчән, гадел хезмәткәр булараk хәтердә калган. Гаделсезлекне җене сөйми иде аның. Үзен бик акыллы санаган, мәдәният министры булырга хыялланып, бу вазифаның бушавын көтеп утыручы бер матбугат «начальнигы» Ягъсуфны гел тәнкыйтьли башлады. Я.Шәфыйков түзеп тормады, бу хакта Президент М.Шәймиевкә кереп сөйләде. Нәтиҗәдә бу «начальник»ны эшеннән җибәрделәр. Билгеле инде, аны министр итеп билгеләү турындагы сүзләр дә туктады.

Ни өчендер Ягъсуфның гаиләсе Казанга күчмәде. Күрәсең шунлыктандыр, Ягъсуф үзе дә биредә озак эшләмәде, Чаллыга китеп барды. Биредә ул шәһәр хакимиятенең җәмәгатьчелек белән элемтә бүлегендә хезмәт куйды. 2001 елда эштән туктады һәм документаль проза әсәрләре иҗат итү белән шөгыльләнде.

Я.Шәфыйков рус һәм татар телләрендә 25 китап язды. Аларның күпчелеге олуг шәхесләргә, танылган милләттәшләребезгә багышланган. Алар арасында Татарстан партия өлкә комитетының беренче секретаре булып эшләгән Фикрәт Табеев, республиканың беренче президенты Минтимер Шәймиев, Татарстан Фәннәр академиясен оештыручы Мансур Хәсәнов, танылган кардиолог Ренат Акчурин, Чаллы шәһәренең легендар җитәкчесе Рәис Беляев, шагыйрь Лев Гумилев, князь Феликс Юсуповка, Бөек Ватан сугышы каһарманнарына багышланганнары да бар. Шул исәптән берсе рейхстагка беренче булып Җиңү байрагын элгән Газетдин Заһитов турында.

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.

МК тамаша байлары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

22 апрель – «Әтәч менгән читәнгә» (А.Гыйләҗев).
23 апрель – Зур залда – «Сәфәр» (А.Шакиров). Кече залда – «Киек каз юлы» (И.Мөхәммәтгалиев).
24 апрель – «Өйләнәм.tat» (И.Зәйниев).
26 апрель – «Исәнме, улым!» (Б.Абдураззоков).
27 апрель – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).
28 апрель – Зур залда – «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин). Кече залда – «Тамашачы тамашасы».
29 апрель – «Килмешәк» (С.Гаффарова).
30 апрель – «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

22 апрель – «Шагыйрь мәхәббәте» (Р.Ахиярова).
24 апрель – 11.00, 18.00 – «Шүрәле» (Ф.Яруллин).
28 апрель – «Любовный напиток» (Г.Доницетти).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

24 апрель – «Чулпан» (Ш.Хөсәенов).
25 апрель – 12.00 – «Сөй гомерне!» (Г.Тукай).18.30 – «Төш» (Т.Миңнуллин).
26 апрель – «Өч аршын җир» (А.Гыйләҗев).
27 апрель – «Гомер буе сине көтәм» (И.Гали).
28 апрель – «Кияү урлау» (С.Юзеев, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
29 апрель – «Утка очкан күбәләктәй» (Н.Гыйматдинова, Т.Хәләф инсценировкасы).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

22 апрель – «Зәйтүнәкәй» (Р.Батулла).
23 апрель – «Әйт әле, күбәләк!..» (Т.Миңнуллин).
24 апрель – «Матур City» (А.Әхмәтгалиева).
26 апрель – 13.00 – «Сәлам, Актәпи» (А.Сальникова). 18.30 – «Арыну» (Т.Кулов).
27 апрель – «Алтынч[ае]ч» (Л.Янсуар, Р.Гарипова).
28 апрель – «Мәхәббәт күгәрченнәре» (В.Гуркин).
30 апрель – 13.00 – «Кәҗүл читек» (Г.Исхакый). 18.00 – «Ак чәчәкләр кебек...» (Р.Мухина).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

22 апрель – 11.00 – «Приключения Барона Мюнхгаузена» (Р.Э.Распе). 19.00 – «Ночь перед Рождеством» (Н.Гоголь).
23 апрель – 11.00, 13.30, 16.00 – «Страна чудес Алисы» (Л.Кэрролл әсәренә нигезләнгән). 12.00 – «Котбетдин мажаралары» (Н.Гернет).
24 апрель – 10.00 – «Один день из жизни улитки» (Ольга һәм Юрий Устюговлар).12.00, 14.00 – «Муха-цокотуха» (К.Чуковский). 18.00 – «Адәмнәр» (Г.Ибраһимов).
26 апрель – 11.00 – «Кәҗә белән сарык» (Г.Тукай, Г.Рәхим инсценировкасы). 11.00, 13.00 – «Волшебные сны Апуша» (Р.Бохараев).
27 апрель – 11.00 – «Коза и овца» (Г.Тукай, Г.Рәхим инсценировкасы), 11.00, 13.00 – «Волшебные сны Апуша» (Р.Бохараев).
28 апрель – 11.00 – «Су анасы» (Г.Тукай, З.Хөснияр инсценировкасы). 11.00, 13.00 – «Буратино» (А.Толстой).
29 апрель – 11.00 – «Җырла, Курай!.. Уйна, Шомбай!» (С.Дорожко). 11.00, 13.00 – «Золушка» (Е.Шварц).
30 апрель – 11.00, 13.00, 15.00 – «Гуси-лебеди» (Л.Кожевников инсценировкасы). 12.00 – «Җырла, Курай!.. Уйна, Шомбай!» (С.Дорожко).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

23 апрель – «Легенды Голливуда» дип исемләнгән концерт.
24 апрель – «Поколение «NEXT» дип исемләнгән кичә.
27 апрель – Җырчы Регина Вәлиева концерты.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

22 апрель – Татарстан Республикасы дәүләт камера хорының «Весна на Заречной улице» дип исемләнгән концерты.
24 апрель – 12.00 – «Волшебник Изумрудного города» исемле музыкаль тамаша. Ком анимациясе кулланыла. 17.00 – Татарстан Республикасы кыллы квартеты башкаруында «На берегах Темзы. Барокко Генделя» дип исемләнгән концерт программасы.

БАТУЛЛА кытыклары



Үзара сөйләшеп торганда композитор Мирсәет Яруллин тәмәке кабы чыгарып, бөтен егетләргә дә «Татарстан» сигареты тәкъдим итә. Барысы да берәр сигарет алып кабыза, чират Батуллага да килеп җитә:

– Тарт! – ди Мирсәет.

Ләкин Батулла тәмәкедән баш тарта.

– Нигә син генә тартмыйсың? – диләр.

– Татарстанны миннән башка да тарткалыйлар, йолкалар, имәләр, суыралар, – ди Батулла.

1970

* * *

Б а т у л л а. Шамил Маннап миннән күрмәкче мәзәкләр-вакыйгалар чыгара башлады бит ул.

Г а р и ф А х у н. Әйтәм җирле аның мәзәкләре тозсыз!

1997

* * *

Җәмил Зәйнуллинның бер җыелышта әйткән сүзе:

– Гариф Гобәйнең «Коръән серләре» китабы аркасында Ислам илләрендә, Советлар Берлегендә яшәүче мөселманнар гына түгел, хәтта мөселман булмаган халыклар да татарны каргый. Элек татарны «яулап алучы, вәхши татар» диеп беләләр иде, хәзер безне «Изге китапка кизәнүче халык» дип тә белә башладылар.

1988

* * *

Сибгат Хәким сүзе:

– 1934 елда, моннан 50 ел әүвәл, Мәскәүдә татар әдәбиятына махсус зур доклад багышланган иде. Быелгы корылтайда татар әдәбияты турында авыз ачучы да булмады. Татарда әдәбият юкмы, әллә күрмәмешкә салышалармы?!

1984

* * *

Фатих Хөсни сүзе:

– Кайбер яшь язучылар чыпчык борыны чаклы хикәя яза да: мине Язучылар Союзына алыгыз, дип чыркылдый башлый. Союзга алгач, нигә миңа «Тукай»ны бирмисез, дип талаша.

1968

* * *

Шагыйрьләр Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат белән Батулла сөйләшеп утыра икән. Өчесе дә акчасыз, өчесе дә бакчасыз дигәндәй, зарланыша икән болар. Шулчак Батулла әйтеп куя:

– Акча ул, егетләр, чибәр хатын кебек, никадәр аны сөйсәң, шулкадәр ул синнән ераккарак кача!

1995

Татарстан китап нәшриятының язучылар катнашындагы олы бер утырышында мондый тәкъдим кертелә:

– Татарстан полиграфия комбинаты белән Татарстан китап нәшриятын кушарга! – диләр.

Шулчак нәшрият директоры Харис Әшрәфҗан әйтеп куя:

– Өч херчене берләштереп, колхоз баемый.

1997

* * *

Язучы Заһид Мәхмүди азатлык өчен көрәш вакытында ачлыкка утыра да сакал үстереп җибәрә. Үзенә бик килешеп торса да, берничә көннән ул сакалын кырып ташлый. Моны күреп, Батулла:

– Хатының кырдырттымы? – ди.

– Каян белдең? – ди Заһид. – Ие шул, хатын рөхсәт итми сакал–мыек йөртергә.

Батулла кинәт кыты-кыты көлә башлый.

– Нигә көләсез, Батулла абзый? – ди егет.

– Соң, – ди Батулла. – Сакал-мыек үстерергә дә хокукы булмаган ир–егет үз халкына ничек итеп хокук яулый алсын?

1996

* * *

Егерме өч яшьлек яшь язучы Батуллага зарлана икән:

– Бер сау тешем юк, ашап булмый, терәләй йотам ризыкны. Синең тешләр ничек, Батулла абзый?

– Теш бетте, – ди алтмыш яшьлек Батулла.

– Алайса, синең хәлләр дә әйбәт түгел икән, – ди егет.

– Әйбәт түгел, – ди Батулла.

– Тешләреңүзеңнеке түгелмени?

– Үземнеке.

– Ничәсе?

– Утыз бере.

– Үзең теш бетте, дисең тагы.

– Бер теш бетте, дигән идем мин.

* * *

Атаклы музыкант Рәфкать Гомәрнең «Саз» ансамбле кызларына әйтә торган сүзе:

– И кызлар, матур да инде сез... җырлаган чагында.

1970



Валентин ДУБИНИН. «Чаян».

1968 елда кап-кара сакаллы Батулланы Язучылар берлегенә әгъза итеп алырга булганнар, ләкин аны сакал үстерә, дип алмаганнар. Язучылар башлыгы Мирсәй Әмир Батулланы чакыртып әйткән:

– Кыр инде шул сакалыңны, Батулла! Союзга кергәч, тагын үстерерсең.

– Соң, Мирсәй абый, – дигән Батулла. – Әдәбиятыгызда бер кара сакаллы язучы булырга тиештер бит инде!

– Усал-усал, – дип Мирсәй Әмир китеп бара.

Батулланы союзга алалар, ул тагын сакал үстерә, ләкин сакал инде агара башлаган була. Мирсәй Әмир Батулланы каридурда очратып әйтә:

– Батулла, сакалың агара башлаган бит! Кырып ташла! – ди.

– Соң, Мирсәй абый, – ди Батулла. – Әдәбиятыгызда чын аксакал булырга тиештер бит инде.

– Усал-усал! – дип Мирсәй Әмир китеп бара.

Беркөнне Батулла чәчен таптакыр итеп кырдырып, язучылар йортына килә. Аның каршысына язучылар оешмасы башлыгы Мирсәй Әмир очрый.

– Карале, Батулла, ник кырдырдың ул чәчеңне? – дип сорый әдип.

Шулчак Батулла:

– Һәй, Мирсәй абый, минем беркайчан да берәүгә дә баш булганым юк, ичмасам, үз башыма үзем баш булыйм инде! – дигәч, Мирсәй Әмир:

– Усал-усал! – дип китеп бара.

* * *

Батулланың каршысына шигырь яза торган Галимҗан белән әдип Мирсәй Әмир килеп чыга.

– Нихәлләр, Мирсәй абый? – ди Батулла.

– Шөкер, менә яңа роман тәмамлап килгәм, – ди әдип.

– Ә син нихәлдә, Галимҗан абый? – ди Батулла.

– Хәл әйбәт түгел әле, – ди Галимҗан. – Ике ай инде бер юл да шигырь яза алганым юк.

– Рәхмәт, бик күп рәхмәтләр сиңа, Галимҗан абый! – ди Батулла.

– Ни өчен рәхмәт? – дип гаҗәпләнә шигырь язучы.

– Син, Галимҗан абый, татар әдәбиятына ике ай буе файда эшләгәнсең бит! – дигәч, Мирсәй Әмир:

– Усал, усал! – дип китеп бара.



Яңа чыга башлаган «Идел» журналының беренче биш санын тикшерергә Язучылар берлегенең клубына бик күп язучылар килә. Мактыйлар да мактыйлар. Шуннан сәхнәгә Гөлшат Зәйнашева менә, ул журнал тышындагы ялангач хатын–кызлар сурәтен селки-селки сөйли:

– Җәмәгать, бу бит безобразие! Шәп-шәрә хатыннарны чыгаргансыз! Татар хатыннары алар беркайчан да чишенмәгән, хәтта урынга ятканда да чишенмәгән.

Шулчак Батулла кычкыра:

– Ә каян килгән ул җиде миллион татар?

* * *

Фикрәт Табеев татар зыялыларын Обкомга җыеп әңгәмә уздырырга була. Ни өчендер ул тарихи романнар яза башлаган әдип Нурихан Фәттахка бәйләнә башлый.

– У Фаттаха мозги не так запрограммированы! Он какой-то странный! Я его хорошо знаю, мы вместе в одной комнате жили, когда учились в университете! Он был жадным и скрягой. Запирал свою тумбочку на замок.

Шулчак Батулла, янәшәсендә утырганнар гына ишетелерлек итеп, әйтеп куя:

– Димәк, бүлмәдә кемдер карак булган!

Шоколад тарихыннан

Майя теленнән шоколад “ачы су” дип тәрҗемә ителә. Әлеге цивилизация өчен какао кузагы бер үк вакытта ризык та, валюта да булган. Мәсәлән, бер колны 100 кузакка алыштырганнар. Ацтеклар императоры Монтесума II Көньяк Американың иң бай кешесе саналган, аның мөлкәте миллиард какао кузагына бәяләнгән. Дөньяда беренче шоколад плиткасын Англиядәге Cadbury фабрикасы 1842 елда чыгарган. 1870 елда Испаниядә шоколад җитештерү автоматлаштырылган. 1 фунт (454 грамм) шоколад җитештерү өчен кимендә 400 какао кузагы кирәк. Немец галимнәре әйтүенчә, бу тәмле ризыктагы флавоноид матдәсе хәтерне һәм реакция тизлеген яхшырта, игътибарны тупларга булыша. Икенче бөтендөнья сугышы вакытында татлы плитка солдат паекларына кертелгән, тик кайвакыт, тиз арада ашап бетермәсеннәр өчен, аның тәмен пешкән бәрәңгенекенә охшатып махсус тәмсезләткәннәр. Адмирал Ричард Берд мәңгелек туңлыкта – Көньяк полюста калдырган шоколад 60 елдан соң да ашарга яраклы булган һәм үзенең файдалы сыйфатларын җуймаган. Бу татлы тәгамне даими куллану аңа бәйлелек китереп чыгара – наркотикларга күнеккән кебек күнегәсең икән. Хәзер әлеге индустриядә 45 миллионлап кеше эшли, алар ел саен 300 төрле тәмле һәм 400 төрле исле 3,8 миллион тонна шоколад җитештерә. Какао агачы 200 ел яши, тик ул аның 25 елында гына җимеш бирә. Бу агачлар экватор янында, нигездә Көньяк һәм Үзәк Америка, Көнбатыш Африка һәм Океания илләрендә үсә. Дөньядагы барлык какао чималының 40 проценты диярлек Кот-д’Ивуар өлешенә туры килә.

(“Die Presse”).

Язмышмы, әллә ялгышмы?

Һәркемгә таныш “Нәни принц” китабы авторы Антуан де Сент-Экзюпери күкне үлеп ярата, бик оста очучы була. 1944 елның 31 июлендә исә ул разведка очышына киткән җиреннән әйләнеп кайтмый... Эзлиләр, әсирлеккә төшкәндер, исәндер, дип өметләнәләр, 1948 елның апрелендә генә язучының вафатын рәсми рәвештә таныйлар. Берничә дистә ел буена аның ничек үлүен белмиләр. 1998 елның 26 сентябрендә Жан-Клод Бьянко исемле балыкчы ятьмәсенә Экзюпери фамилиясе язылган көмеш беләзек эләгә. Франция хакимияте шул урында эзләү эшләрен башлый. 2000 елның маенда Марсель шәһәре янындагы бухтада “Лайтнинг П-38” тибындагы очкыч калдыклары табыла, аның сул канатындагы 2734 санна-ры самолетның чыннан да Экзюперины-кы булуын дәлилли. Ниһаять, табышмак чишелә: 1944 елның 31 июлендә немец Хорст Рипперт идарә иткән “МЕ-109” истребителе француз самолетын диңгезгә бәреп төшерә. Пилот (ә бу Сент-Экзюпери була) дошманны күрмичә кала йә күреп тә сугышка керми. Рипперт 88 яшендә генә серен ача, тик журналистлар ул исән чакта аның исемен атамаска тиеш була. Ул менә нәрсәләр сөйләп калдыра: “Мин пилотны күрмәдем. Күрсәм дә, Сент-Экзюперины танымас идем. Мин озак вакытлар буе, бәлки бу башка кеше булгандыр, дип өметләндем. Без үсkәндә барыбыз да аның китаплары белән җенләнеп үстек, мин шуңа күрә күккә гашыйк булдым һәм очучы һөнәрен сайладым. Әгәр мин дошман очкычында яраткан язучым икәнен белсәм, әлбәттә инде, атмас идем...”

(“Интересно.cc”).

Юмартлык кадерен белмәгәч...

Моннан тугыз ел элек кытай бае Чэнь Шен якташларына яхшылык эшләмәкче булган һәм, 31,9 миллиард доллар акча бүлеп, үзенең туган авылында 258 зиннәтле вилла төзеткән. Өчәр катлы һәр йортта бишәр – йокы, икешәр кунак бүлмәсе, гараж һәм бакча бар. Берничә йортка бер спорт мәйданчыгы җиһазландырылган, төрле чаралар үткәрү өчен сәхнә дә ясалган. Әмма бүләк виллаларда хәзергә кадәр берәү дә яшәми. Чөнки саран авылдашлар һаман үзара килешә алмый – кемгә бер генә, кемгәдер берничә йорт эләгергә тиеш, дип бәхәсләшә. 2013 елгы җанисәп нәтиҗәләре буенча, авылда 190 гаилә яшәгән. Әмма төзелеш башлангач, авылга күчеп килүчеләр арткан. Бөтен кешегә җитсен дип, Чэнь Шен тагын 68 йорт төзеткән. Бушлай торакка кызыгучылар һаман ишәйгән, элек шул авылда яшәп, күптән күчеп китүчеләр дә кайта башлаган. Кайбер гаиләләр әле өйләнмәгән улларына да йорт дәгъваларга керешкән. Шен авылга килү белән, аны урап алып, яңадан-яңа йортлар даулап аптыраткач, бай кайтмый башлаган – хәзер күренгәне дә юк икән. Шунлыктан виллалар буш тора, ә халык һаман талаша. Шен әле, якташларын эш белән дә тәэмин итү өчен, авыл янында ферма төзетергә, бакча утыртырга да ниятләгән булган. Бу очракта җирле халыкның еллык кереме 32 мең долларга җитәр иде – мондый акчаның кытай фермерларының төшенә дә кергәне юк бит. Әмма халыкның саранлыгы юмарт байның бөтен планын юкка чыгарган. Буш торган йортлар исә искерә, туза, бала-чага аларның тәрәзәләрен дә ватып бетергән.

(“Batona.net”).

Иң озын асылмалы күпер

Моннан бер ай элек Төркиядә дөньяда иң озын асылмалы күпер файдалануга тапшырылды. “1915 Чанаккалә” дип аталган күперне ачу тантанасында дәүләт президенты Рәҗәп Тайип Эрдоган да катнашты. Әлеге күпер Дарданелл бугазы аша салынган. Аның киңлеге – 45,06, тулаем озынлыгы 4 608 метр тәшкил итә, иseme 1915 елда Чанаккалә сугышында төрекләрнең бөек җиңүгә ирешүләренә ишарәли. Дарданелл бугазы Мәрмәр һәм Эгей диңгезләрен бер-берсенә тоташтырса, аның аша салынган “1915 Чанаккалә” күпере Төркиянең Европа өлешендәге Балкан ярымутравы белән Азия ягындагы Кече Азия ярымутравын, шул исәптән Лапсеки һәм Гелиболу районнарын бер-берсенә тоташтыра. Ул бер ярдан икенче ярга элеккеге сәгать ярым урынына алты минутта чыгу мөмкинлеге бирә. Күперне төзүгә 2 миллиард 545 миллион евро акча тотылган. Ул Төркиягә елына 415 миллион евро экономияләргә мөмкинлек бирәчәк, аның ил сәнәгатенә икътисади уңай йогынтысы елына 5,3 миллиард еврога җитәчәк. 118 мең кешегә эш урыны ачылуга сәбәпче әлеге күпердән үтү түләүле – 200 төрек лирасы булачак. Төркиядә ике бугаз – 61 чакрымлы Дарданелл һәм 30 чакрымлы Босфор бугазлары бар. Бүгенге көндә Босфор бугазы аша өч күпер салынган, Дарданелл аша исә бусы әлегә беренче генә.

(“Turkmenportal.com”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

25 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 15.30 «УЕННАН УЙМАК». 12+
10.00, 22.10 «МАЧЕХА». 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30, 17.00 «Татарлар». 12+
12.00, 23.00 «СВОИ». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
14.45 «Уймак» һәм «Сәйлән».
16.30 «Мин». 12+
17.30 «Татарстан без коррупции». 12+
19.00, 20.00, 0.15 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.45 «Каравай». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Галәм илчесеннән хәбәр бар». Габдулла Тукай турында телеочерк. 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «Аклык турында җыр». Зөһрә Сәхәбиева турында телеочерк. 6+
19.10 «Татар халык җырлары». Җырлый Искәндәр Биктаһиров. 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ГОСПОДА-ТОВАРИЩИ». 12+
10.30, 21.00 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ЦИФРОВАЯ РАДИОСТАНЦИЯ». 16+
14.30 «Дорога в космос». 12+
15.00 «Химия». 12+
15.30 «Путеводитель по вселенной». 12+
16.30 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 0.55 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «НАЧАЛЬНИК РАЗВЕДКИ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+
0.00 К 70-летию Владислава Третьяка. «Легенда номер 20». 12+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.10, 10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 Невский ковчег. Теория невозможного. Виктор Набутов.
8.15 «РЕСПУБЛИКА ШКИД».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Театральные встречи. «За синей птицей...»
12.25 «Апостол радости».
14.05 Линия жизни. Анатолий Кролл.
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «ПОЗДНЯЯ ЛЮБОВЬ».
17.45 Солисты XXI века. Борис Андрианов и Андрей Гугнин.
18.35 «Таинственные города Майя».
19.45 Главная роль.
20.05 «Библейский сюжет».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.50 К 80-летию со дня рождения Святослава Бэлзы. Линия жизни.
21.45 «Сати. Нескучная классика...»
22.30 «МИРАЖ».

«НТВ»

5.00 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПОЛИЦЕЙСКОЕ БРАТСТВО». 16+
22.00, 23.30 «ПЁС». 16+

Сишәмбе

26 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК». 12+
10.00, 22.10 «МАЧЕХА». 12+
11.00 Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясен тапшыру тантанасы.
12.30, 16.30 «Татарлар». 12+
13.00 «И туган тел...». Г.Тукайның туууна 136 ел тулуга багышланган Шигърият бәйрәме.
15.15 «Уймак» һәм «Сәйлән».
16.00 «Родная земля». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Ватандашлар». 12+
23.00 «СВОИ». 16+
23.45 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Манзара». 6+
8.00 «БЕР МӨХӘББӘТ, МЕҢ ФАРАЗ». 6+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 18.20 Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләген тапшыру тантанасы. 6+
12.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
13.00, 21.25 «И туган тел...» Г. Тукайның туууна 136 ел тулуга багышланган Шигърият бәйрәме. 6+
15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
22.20 Г.Тукай. «Сөй гомерне!» 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ГОСПОДА-ТОВАРИЩИ». 12+
10.30, 21.00 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «БАБОНЬКИ». 16+
14.35 «Дорога в космос». 12+
15.00 «Тайны анатомии». 12+
15.30 «Один день в городе». 12+
16.30 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20, 0.00 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 0.40 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «НАЧАЛЬНИК РАЗВЕДКИ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.35 «Таинственные города Майя».
8.35, 16.35 «ТАЙНИК У КРАСНЫХ КАМНЕЙ».
9.45 «Забытое ремесло».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Омск».
12.10 Цвет времени. Василий Поленов. «Московский дворик».
12.20, 22.30 «МИРАЖ».
13.30 80 лет со дня рождения Святослава Бэлзы. Линия жизни.
14.30 «Павел Флоренский. Русский Леонардо».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Эрмитаж».
15.50 «Сати. Нескучная классика...»
17.40 Солисты XXI века. Николай Луганский.
19.45 Главная роль.
20.05 «Библейский сюжет».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.50 50 лет Николаю Луганскому. Линия жизни.
21.45 «Белая студия».

«НТВ»

5.00 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПОЛИЦЕЙСКОЕ БРАТСТВО». 16+
22.00, 23.30 «ПЁС». 16+

Чәршәмбе

27 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК». 12+
10.00, 22.10 «МАЧЕХА». 12+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.00 «СВОИ». 16+
13.00, 0.10 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
15.15 «Шома бас» һәм «Сәйлән».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00, 23.45 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.30, 20.30 «Юлчы». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 12+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10 «Халык җырлары». Зөһрә Сәхәбиева җырлый. 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ГОСПОДА-ТОВАРИЩИ». 12+
10.30, 21.00 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ГАЙД ПАРК НА ГУДЗОНЕ». 16+
14.40 «Дорога в космос». 12+
15.10 «Без химии». 12+
15.40 «Гастротур». 16+
16.30 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20, 0.00 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 0.40 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «НАЧАЛЬНИК РАЗВЕДКИ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.30 «Таинственные города Майя».
8.35, 16.35 «ТАЙНИК У КРАСНЫХ КАМНЕЙ».
9.45 «Забытое ремесло».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Волшебный фонарь». Режиссер Е. Гинзбург.
12.05 «Первые в мире».
12.20, 22.30 «МИРАЖ».
13.30 «Предки наших предков».
14.15 Искусственный отбор.
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 100-летие образования якутской АССР. Пряничный домик. «Якутский костюм».
15.50 «Белая студия».
17.45 Солисты XXI века. Константин Емельянов.
19.45 Главная роль.
20.05 «Библейский сюжет».
20.35 Абсолютный слух.
21.20 «Самая счастливая Пасха в моей жизни».
23.35 Цвет времени. Микеланджело Буонарроти. «Страшный суд».

«НТВ»

5.00 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПОЛИЦЕЙСКОЕ БРАТСТВО». 16+
22.00, 23.30 «ПЁС». 16+

Пәнҗешәмбе

28 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК 2». 12+
10.00, 22.10 «МАЧЕХА». 12+
11.00, 0.35 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.00 «СВОИ». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник» һәм «Сәйлән».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Ватандашлар». 12+
23.45 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 12+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Калеб». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ГОСПОДА-ТОВАРИЩИ». 12+
10.30, 21.00 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00 «Счастливо оставаться». 16+
14.30 «Дорога в космос». 12+
15.00 «Химия». 12+
15.30 «Путеводитель по вселенной». 12+
16.30 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
23.50 «ПЕРЕД РАССВЕТОМ». 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20, 0.00 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 0.40 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».

22.00 «НАЧАЛЬНИК РАЗВЕДКИ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.35, 10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Таинственные города Майя».
8.40, 16.35 «ТАЙНИК У КРАСНЫХ КАМНЕЙ».
9.45 «Забытое ремесло».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «О балете. Встреча с народным артистом СССР Николаем Фадеечевым».
12.05 «Первые в мире».
12.20 «МИРАЖ».
13.30 «Предки наших предков».
14.15 Абсолютный слух.
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Моя любовь - Россия! «Домры и гитары из Шихова».
15.45 «2 Верник 2».
17.45 Солисты XXI века. Борис Березовский и Никита Борисоглебский.
18.25 Цвет времени. Микеланджело Буонарроти. «Страшный суд».
18.35 «Петра. Секреты древних строителей».
19.45 Главная роль.
20.05 «Библейский сюжет».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.50 «Родина рядом».
21.35 Цвет времени. Эдгар Дега.
21.45 «Энигма. Лариса Дядькова».
22.30 «Мосфильм» на ветрах истории. От Сталина к Хрущеву. Заметки очевидца».

«НТВ»
5.00 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПОЛИЦЕЙСКОЕ БРАТСТВО». 16+
22.00 «ПЁС». 16+
23.30 «ЧП. Расследование». 16+

Җомга

29 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК 2». 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30, 16.30, 21.00 «Татарлар». 12+
12.00, 0.20 «СВОИ». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Рыцари вечности». 12+
15.15 «Төймә» һәм «Сәйлән».
16.00 «Мин». 12+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Реальная экономика». 12+
22.40 «ВОТ ЭТО ЛЮБОВЬ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10 «Туган җир». 12+
20.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә». «Габәши язмышы». 6+
21.25 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ГОСПОДА-ТОВАРИЩИ». 12+
10.30, 21.00 «СЕМЕЙНЫЙ АЛЬБОМ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.00 «НЕСНОСНЫЕ ЛЕДИ». 16+
15.00 «Тайны анатомии». 12+
15.30 «Один день в городе». 12+
16.30 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.40 «Поле чудес».
21.00 «Время».
22.00 «Голос. Дети».

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Петра. Секреты древних строителей».
8.35, 16.35 «ТАЙНИК У КРАСНЫХ КАМНЕЙ».
9.45 «Забытое ремесло».
10.20 Спектакль «Полтава».
11.35 «Библиотека Петра: слово и дело».
12.05 «Я, Майя Плисецкая...»
13.25 «Купола под водой».
14.10 «Юрий Кублановский. Родина рядом».
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Лариса Дядькова».
16.20 «Первые в мире».
17.40 Солисты XXI века. Максим Емельяничев.
18.20 «Тунис. Дворец Эссаада».
18.45 «Царская ложа».
19.45 «Смехоностальгия».
20.10 Искатели. «Клады копорской крепости».
20.55 «ЕЩЕ РАЗ ПРО ЛЮБОВЬ».
22.30 «Мосфильм» на ветрах истории. От Сталина к Хрущеву. Заметки очевидца».

«НТВ»
5.00 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
20.00 «Жди меня». 12+
20.50 «Страна талантов». 12+
23.15 «Своя правда». 16+

Шимбә

30 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Мин». 12+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 «Созвездие - Йолдызлык-2022». 6+
14.35 «Чын шигырьгә әверелә шагыйрь». Ркаил Зәйдулланың юбилей кичәсе. 6+
16.00 Концерт «Современная музыка мусульманского мира». 6+
17.00 «СТЕНДАПхана». 16+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.00 «СМОТРИНЫ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Ишеттем мин кичә берәү җырлый». 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.05 «Өмет йолдызы». Эльмира Кәлимуллина концерты. 6+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Йөрәк җылысы». Филүс Каһиров концерты. 6+
22.35 Спектакль «Кадер кичәсе». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Химия». 12+
5.30 «Дорога в космос». 12+
6.30 «Биосфера. Законы жизни». 12+
7.00 «Три кота. Сезон 3».
7.30 «Сказочный патруль. Хроники чудес».
8.00 «Планета лошадей». 12+
8.30 «ОСКОЛКИ СЧАСТЬЯ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ОПЕРАЦИЯ «КОЛИБРИ». 16+
14.50 «Все, кроме обычного». 16+
15.55 «Джокер». 12+
16.55 «УЛЕТНЫЙ ЭКИПАЖ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ПРАЗДНИЧНЫЙ ПЕРЕПОЛОХ». 16+
23.00 «Человек - невидимка». 16+
23.50 «СЧАСТЛИВО ОСТАВАТЬСЯ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
10.15. 16+
10.55 «Юстас - Алексу». Тот самый Алекс». 16+
12.15, 15.15 «СТАТСКИЙ СОВЕТНИК». 16+
16.25 «Кто хочет стать миллионером?» 12+
18.20, 21.35 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ. ПОБЕДА!» 16+
21.00 «Время».
23.00 «ГНЕЗДО». 18+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.35 «АКУШЕРКА». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 ЖИЗНЬ ПРЕКРАСНА. 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.20 «ВОСТОЧНЫЙ ДАНТИСТ».
9.30 Неизвестные маршруты России. «Карелия. От Кудамы до Фоймогубы».
10.15 «ЕЩЕ РАЗ ПРО ЛЮБОВЬ».
11.45 Письма из провинции.
12.15, 23.55 «Розовая чайка».
12.55 «Музеи без границ». Пермский музей современного искусства PERMM.
13.25 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
14.35 «КУБАНСКИЕ КАЗАКИ».
16.25 «Те, с которыми я... Итальянская тетрадь. Бернардо Бертолуччи».
16.55 «Хозяйки Удоры».
17.45 «ТОТ САМЫЙ МЮНХГАУЗЕН».
20.00 Большой джаз.
22.05 «ДАВАЙ ПОТАНЦУЕМ».

«НТВ»
5.10 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД». 16+
5.40 «МЕСТЬ БЕЗ ПРАВА ПЕРЕДАЧИ». 16+
7.20 Смотр.
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда с Сергеем Малозёмовым». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.05 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00 «Отрицатели болезней». 12+
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «По следу монстра». 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.15 «Маска». «Филипп Киркоров. 55!» 12+
23.00 «Скажи им, кто я». 16+

Якшәмбе

1 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00, 0.40 «Бәхетемне килә табасым». Айдар Рәкыйпов концерты. 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 Мультфильмы. 6+
8.45 «Полосатая зебра».
9.00 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Тархан». 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент.Общество». 12+
13.30 «Созвездие - Йолдызлык-2022». 6+
14.35 «Чын шигырьгә әверелә шагыйрь». Ркаил Зәйдулланың юбилей кичәсе. 6+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Профсоюз - союз сильных». 12+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «ПРИТВОРИСЬ МОИМ МУЖЕМ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30, 13.35 «Нәсыйхәт». 6+
6.00, 13.00, 0.40 «Татарлар». 12+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00, 16.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
8.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
9.00 «Яшәү кече килә җырларыннан». Мансур Шиһапов турында телеочерк. 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы». 12+
14.05 «Кайда сез, яшьлек еллары». Зөһрә Шәрифуллина концерты. 6+
15.35 «Ватандашлар». 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 «СТЕНДАПхана». 16+
21.40 Концерт «Современная музыка мусульманского мира». 6+

«ЭФИР»
5.00 «Тайны анатомии». 12+
5.30 «Романовы. Судьба русского Крыма». 12+
6.30 «Клятва Гиппократа». 12+
7.00 «Три кота. Сезон 3».
7.30 «Сказочный патруль. Хроники чудес».
8.00 «Кондитер. Сезон 3». 16+
9.00 «Один день в городе». 12+
9.55 «УЛЕТНЫЙ ЭКИПАЖ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ПРАЗДНИЧНЫЙ ПЕРЕПОЛОХ». 16+
15.00 «Планета лошадей». 12+
15.30 «ОСКОЛКИ СЧАСТЬЯ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ОПЕРАЦИЯ «КОЛИБРИ». 16+
22.50 «Человек - невидимка». 16+
23.45 «РАБОТОДАТЕЛЬ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
6.10 «Россия от края до края». 12+
6.45 «ХИРОМАНТ. ЛИНИИ СУДЕБ». 16+
8.25 «Часовой». 12+
8.55 «Здоровье». 16+
10.15 К 70-летию Владислава Третьяка. «Легенда номер 20». 12+
11.10 «АнтиФейк». 16+
12.15 «ВЕРНЫЕ ДРУЗЬЯ».
14.10, 15.15 «Крым. Небо Родины». 12+
16.05 «Оранжевые дети Третьего рейха». 16+
17.00, 18.20 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ. ПОБЕДА!» 16+
21.00 «Время».
22.35 «ПРИЗРАК». 16+

«РОССИЯ»
4.50 «ОНА СБИЛА ЛЁТЧИКА». 12+
8.00 «КАРНАВАЛЬНАЯ НОЧЬ».
9.30 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 14.00, 17.00 Вести.
12.15 «Измайловский парк». 16+
15.15 «КАВКАЗСКАЯ ПЛЕННИЦА, ИЛИ НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШУРИКА». 6+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.35 «ВЕСНА».
9.25 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
9.55 «Мы - грамотеи!»
10.35 «ШЛА СОБАКА ПО РОЯЛЮ».
11.45 Диалоги о животных.
12.25 Невский ковчег. Теория невозможного. Лидия Чарская.
12.55 «Музеи без границ». Коломна. Музей пастилы.
13.25 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
14.35 «СВЕРСТНИЦЫ».
15.55 «Пешком...»
16.25 «Те, с которыми я... Итальянская тетрадь. Федерико Феллини».
16.50 «Песня не прощается... 1975 год».
17.45 «12 СТУЛЬЕВ».
20.20 «Сказки венского леса».
21.55 «СИССИ».
23.35 Искатели. «Клады копорской крепости».

«НТВ»
5.10 «МОЙ ДОМ - МОЯ КРЕПОСТЬ». 16+
6.45 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 Своя игра.
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.00 Итоги недели.
20.40 «Маска». 12+

Соңгы вакытларда этләрнең кешеләргә, бигрәк тә, балаларга һөҗүм итүе яисә ошбу хайваннарга карата кылынган ерткычлыклар турында шаукым аеруча еш күтәрелә. Бу җәһәттән мәгълүмат чараларында Балык Бистәсе районындагы этләр приютына ут төртү хакында да хәбәрләр булды һәм бу явызлык бичара хайваннарга каршы эшләнгән гамәл итеп күрсәтелде. Чынлыкта, бу кеше үтерергә омтылу дигән җинаять иде.

Эт приютында ут

Приют Балыклы Чүкәй авылы җирлегендә Мәскәү-Уфа федераль автомобиль юлыннан ерак булмаган кырда ачыла. Аны 2018 елда Казанда яшәүче Альбина Хәсәнова (исеме үзгәртелә) үз карамагындагы 6 гектарлы җир кишәрлегендә оештыра. Рәсми теркәлмәгән приют хәйриячеләр ярдәме һәм, әлбәттә, А.Хәсәнова тырышлыгы белән яши. Узган ел көзендә калай койма артында 130 дан артык маэмай исәпләнә.

2020 елның сентябрендә 1985 елгы Ришат Исхаков дүрт аяклы дустын яхшы хуҗалар тәрбиясенә бирергә теләве турында интернетта хәбәр урнаштыра, тиздән «Земля надежды» дип аталган әлеге приют хуҗабикәсе Альбина белән элемтәгә керә. Нәтиҗәдә алабай шау-шулы приютта урын ала. Эт язмышындагы кискен борылыш кына булмый бу, ә бәлки ялгызак ир белән хатын тормышында да үзгәрешләргә китерә. Чөнки танышып якынаеп китеп, алар бергә тора башлыйлар.

Даими эш урыны булмаган Ришат хуҗалык эшләрендә булыша, чынлыкта, әлеге йөкне икәүләп тарта алар. Ир белән хатын этләр янәшәсендәге 15 кв. метр мәйданлы көнкүреш корылмасында көн күрә. Калай белән тышланган юка стеналы әлеге өй утын миче белән җылытыла, юынгыч, суыткыч, телевизор, тундыргыч, йоклау өчен ике сәке куелган, эт ризыклары тутырылган капчыклар да шунда саклана.

Казан уртасындагы яңа йортта фатиры, шәһәр читендәге бистәдә шәхси йорты булган ханымның кыр уртасында шушындый шартларда яшәвен Р.Исхаковка мөкиббән булу белән генә аңлатып булмастыр. А.Хәсәнова, иң әүвәл, үз карамагындагы җан ияләрен кайгырта. Иртүк торып машинасында Казанга китә, әби-бабасы белән яши торган 10 яшьлек улын мәктәпкә озатып куя да, кайтып, дүрт аяклылар янында кайнаша.

Аннан соң, бер түбә астында яшәгәч, ир кешене дә кайгыртмыйча булмый, ашатырга, бигрәк тә, эчертергә кирәк. Аек көне сирәк булган Р.Исхаков туктаусыз эчәргә сорый бит. Зур гәүдәле булгач, бер ярты да җитми иде ди Альбина. Шулай да азмы-күпме булышучы, үзе юкта күз-колак булып торган һәм ялгызлыктан коткарган ошбу кешене бөтенләй үк кирәкмәгән әрәмтамак диярлек түгел. Ләкин таяныч булырдай ышанычлы ир-егет тә булмый ул.

Ришат Казанда тулы гаиләдә туа, әтисе иртә үлгәнгә, 12 яшеннән әнисе тәрбиясендә үсә, алдан тегүчелеккә укып чыга, аннан соң парикмахер һөнәре ала. Бу кадәресе әйбәт, әмма армия хезмәтенә алынгач, Оренбург өлкәсендәге гаскәри частьне ташлап кача, айдан артык эзләгәннән соң, Казанда тотыла һәм хәрби суд тарафыннан бер елга колониягә озатыла. Аннан кайткач та, наркотикка хирысланып китә, героин, амфетамин кадаучы буларак махсус исәпкә дә куела, наркотикларга бәйле җинаять эшләп, тагын ел ярымга ирегеннән мәхрүм ителә. Колониядән азат ителгәч, наркоманнар исемлегеннән төшерелә, әмма әлеге зәхмәткә бәйлелекне эчкечелеккә алыштыра. Шул сәбәпле даими эшкә урнаша алмыйча, очраклы эшләргә йөргәли, 36 яшендә гаиләсез, баласыз яши, Казанда 16 яшькә өлкәнрәк Анфиса атлы ханым белән тора. Әнисе белән Апас районында йорт алып авылда яши башлагач та араны өзми алар, ул гына да түгел, этләр приютында «оялагач» та, ир-ат күптәнге сөйгәне янына Казанга кайткалап бер-икене кунып китә.

Аның ике арада йөрүен хатыннар да белә. Көндәшләрнең өлкәнрәге, Р.Исхаковны эчсә дә җайлы булды, дип уңай бәяли. А.Хәсәнова исә исерек чакта үзенә кул күтәрүен дә әйтә, полициягә хәбәр итмәдем, итсәм дә, кызганып гаризамны кире алдым, ди. Һәм боларга ир кешенең көнләшүен дә өсти.

Хикмәт шунда ки, узган ел җәй көннәрендә приютта 1980 елгы тагын бер ир-ат пәйда була. Балык Бистәсендә әнисе һәм әнисе белән яшәүче буйдак Алексей Горбунов социаль челтәрдән «Земля надежды» дип аталган әлеге этләр приюты булуын, аның ярдәмгә мохтаҗ икәнен белеп ала һәм бертуганы белән бергәләп үзенең «Ока» машинасында килеп тә җитә. Альбина һәм Ришат белән танышып сөйләшкәч һәм 137 баш хайванны күргәч, берникадәр акча биреп китә. Җәй айларында ул тагын 3-4 тапкыр матди яктан ярдәм күрсәтә, ә сентябрьдә атнасына дүртәр мәртәбә төрле төзү-кору эшләре башкарып йөри, әйтүенчә, хуҗалар белән дуслаша.

Эчми, тартмый торган түләүсез ярдәм итүче оста куллы кеше белән хуҗабикә яхшы аралаша, әлбәттә. Бусы инде күбесенчә кызмача йөрүче Ришат күңелендә шик-шөбһә вә көнче хисләр уятмый калмый. Моның ни дәрәҗәдә нигезле булуы билгесез. Ләкин шунысы хак, А.Горбунов Альбинага, үзе әйткәнчә, аны ошатуы, аңа карата битараф булмавы турында җиткергән була. Бусын хатын-кыз да раслый, ләкин якыннан аралашуларын кире кагалар. Эчми торган 43 яшьлек юньле ханымның, сәрхуш ирдән туеп, тәртипле тырыш кешегә өстенлек бирү ихтималы бар бит. Болар исә сәрхуш башында «кыска ялганыш» килеп чыгу куркынычын көчәйтә.

25 сентябрьдә төштән соң А.Хәсәнова Казанга бара, ике ир приютта кала, кич белән А.Горбунов, гадәттәгечә, өенә кайтып китә. Хатын-кыз, исерек сөйгән яр ишегалдында тавык кыздырып торганда, караңгы төшкәндә әйләнеп кайта. Бар да тыныч булды, тиздән Ришат йокларга түнде, ди ханым. Икенче көнне иртәнге сәгать 7 дә үк дүртаяклы дусларын карарга чыга ул. Шактый гына эшләгәч, баш төзәтеп өлгергән ир заты да күренә. Соңрак Альбина хәмерне кайдан алганын белмим дисә, Ришат ярты шешә коньякны үзе бирде дип аңлатыр. Ир-атның иртәдән исереп куюы бер хәл, монысын гадәти күренеш диярга мөмкин, чөнки. Ләкин очкын чыгу өчен тагын бер сәбәп туа, ягъни ир-ат озын-озаклап кем беләндер телефоннан сөйләшә. Аның Казандагы «сожительница»сы булуын белгән Альбина ризасызлык белдерми калмый. Кыскасы, үзара низаг куба. Ахыр чиктә, үзе әйтмешли, бушка эшләп гомер уздырудан туйган Ришат китәргә була. Хатын-кыз аңа алдан 150 тәңкә юллык акча тоттыра, аннан соң тагын 500 сум өсти. Шулай итеп Исхаков Мәскәү-Уфа юлына таба тәпили.

Трассага барып җиткәнче, «Ока» машинасында приютка таба җилдерүче А.Горбуновны очрата ул һәм аңа, кыскача гына әйтсәк, аерылышу хакында сөйләп өлгерә, кибеткә барып килергә өнди. Әлбәттә, кесәсенә аз-маз акча кергән кеше аракы алмакчы була, ләкин Алексей аның гозерен үтәүдән баш тарта, приютка барып төзү-төзәтү эшләре белән шөгыльләнә. Әлбәттә, Альбина «сожитель»не куып чыгаруын аңа әйтә, әмма бу сәрхуштән котылу дигәнне белдерми әле.

Кичке сәгать 4 ләр тирәсендә нык исерек Ришат тагын пәйда була. Көн буе хайваннар арасында йөреп арган ханымның торагына бикләнеп ял иткән чагы була бу. Сәрхушка ишекне ачмый ул. Бераздан тышта моторлы пычкы гөрелтесе ишетелә башлый, бу инде Р.Исхаковның ишекне кисеп эчкә үтәргә җыенуын белдерә. Ләкин моны шул тирәдә эшләгән Алексей күреп һәм ишетеп алып, бензин пычкысын сүндерә. Сәрхуш урындыкка утырып, аракы чөмерүен дәвам иттерә, инде хәзер А.Горбунов та аның янынннан китми, димәк ки, ирләр әңгәмә кора, әлбәттә, сүз хатын-кыз турында бара. Әгәр Горбунов соңрак сөйләгәннәр хак булса, Р.Исхаков аңа базардагы алыш-биреш, тегәлргә, сату-алу ясарга тәкъдим итә, ягъни Альбинаны калдырып Казанга китәчәгенә ышандыра, әмма моның өчен ай саен 20 мең сум түләп торырга кирәк булачагын әйтә!..

Бәрелгән машиналарны төзәтүче булып автосервиста эшләүче ир-ат кискен рәвештә баш тартса да, ошбу исерек ахмаклыкка әллә ни исе китми. Ләкин хатын-кызны исерек явыз янында ялгызын калдырып китәргә дә базмый. Икәүләп көнкүреш бүлмәсенә кергәч, тәмам «алҗыган» Ришат күнегелгән урынына ятарга омтылыш ясап карый, ләкин хатын-кызның кискен каршылыгына очрый. Әлбәттә, тавыш-гауга күтәрелә, сәрхушне икәүләп этә-төртә тышка чыгаргач, Альбина участковый Булатка шалтырата, ләкин барысын да әйтеп бетерә алмый, сискәнеп китеп телефонын төшереп җибәрә. Чөнки шул мәлдә кечкенә генә бердәнбер пластик тәрәзә коелып төшә, ишекнең тыштан бикле икәне мәгълүм була.

Утлы мәхшәрнең башлануын белдерә бу. Исхаков ватык тәрәзәдән бензин сибә башлый, эчтә калган ике кеше шул тишектән үрелеп аны туктатырга, ут төртүен кисәтергә тырышып карыйлар, ләкин барып чыкмый. Р.Исхаков соңрак канистр тәрәзәдән сыймый дип, өй эченә бензин сибүен кире кага, бары тик 200-300 грамм чамасы стенага гына бөркедем дип аклана. Ләкин ялкын өйне эчтән-тыштан күз ачып йомганчы ялмап ала. А.Горбунов кечкенә тәрәзәдән тышка чыгарга һәм бикләнгән келәне ачып, Альбинаны коткарырга өлгерә. Хатын-кыз яна торган корылмага үтеп, ятак астына поскан ике көчекне дә алып чыга әле. Шөкер, ут эт ояларына кадәр барып җитми.

Янгынны сүндереп азаплanулар нәтиҗә бирми. Янгынчылар, полиция килеп җиткәндә «бытовка»дан кыйшайган-кәкрәйгән калай өеме генә калган була. Аларны пешкән урыннары күренеп торган ике кеше каршы ала. Соңрак үткәрелгән экспертиза аларның сәламәтлегенә җиңел дәрәҗәдәге зыян китерелгән дип таба. Ләкин җинаять эше аңлы рәвештә һәм аеруча кансызлык белән ике кешене үтерергә омтылыш ясау очрагы буенча кузгатыла. Моңа ут төртеп чит кеше мөлкәтен юк итү хакындагы тагын бер эш өстәлә, билгеле. А.Хәсәновага 127 мең сумлык матди зыян китерелгән дип исәпләнә. Өстәвенә, хуҗабикәнең шофер таныклыгы, паспорты һәм башка документлары да көлгә әйләнә әле.

Алексей белән Альбина ут эченнән чыккач та, Р.Исхаковның алпан-тилпән «М-7» юлына таба китүен күреп калалар. Аның, егылганга күрә, пычрак киемле булуын, төс-кыяфәтен әйтеп бирәләр. Ләкин юкка чыгып өлгерә һәм өч көннән соң гына тоткарлана ул. Әйтүенчә, Васильево бистәсе тирәсендәге дачада яшеренеп ята, Анфиса фатирына яисә Апас якларындагы йортына кайтса эләктерәчәкләрен чамалый. Ләкин уйлый торгач, үз теләге белән Казандагы «Ямашев» полиция бүлегенә килеп бирелә, этләр приютына ут төрттем дип сөйли.

Ут төртүен таный, ләкин үтерү нияте, теләге булуын кире кага, андый уем булса ахырына кадәр җиткергән булыр идем, аларның «бытовка»дан чыгуын күреп, тормышларына куркыныч янамавына ышангач кына китеп бардым дип сөйли. А.Горбуновны авырта торган кулын каеруда, Альбинаны соңгы вакытта гел арзанлы «Перцовка» эчертүдә гаепли, хәтта ошбу хәмергә нинди дә булса дару салып аңына зыян китерү мөмкинлеге бар дип фаразлый. Ләкин тикшерү комитетының Биектау районара бүлегеннән С.О.Малахов тыштан ишекне бикләп ике кеше булган өйгә ут төртүчегә югарыда телгә алынган бик хәтәр гаепләү белдерә. Зарар күрүчеләр дә үтерергә омтылды дип саныйлар. Балык Бистәсе район суды гаепләү ягы фикеренә өстенлек биреп, 36 яшьлек ир-егетне 10 елга кырыс режимлы колониягә озатырга дигән хөкем чыгарды.

Наил ВАХИТОВ.

Сәхнә рәссамы бәйрәме

Татарстанның халык рәссамы, республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Сергей Скоморохов 70 яшен Г.Камал театрында күргәзмә белән билгеләп үтте.

Саратовта туып-үскән егет, Ростов-Донда – сәнгать училищесы, Мәскәүдә МХАТ мәктәп-студиясе тәмамласа һәм Комсомольск-Амурда, Хабаровск, Чита, Тверь, Тула, Түбән Новгород, Чабаксар, Йошкар-Ола һәм Казаныбызның В.Качалов театрында ун ел иҗат итсә дә, барыбер Камал театры – күңеленә иң якыны. Биредә кырык елга якын вакыт эшләгәнгә генә түгел. Кырык ел эчендә никадәр күренекле шәхес белән дуслашылган, ничаклы спектакльгә гашыйк булынган бит! С.Скоморохов иҗат юлын яшь, үзенчәлекле режиссер Дамир Сираҗиев белән башлый, Марсель Сәлимҗанов белән дәвам итә, бүген исә Фәрит Бикчәнтәев белән иҗат итә. Болар – һәркайсы олы шәхес, үзгә мәктәп. «Бик заманча, кызык сәхнә рәссамнары бар, әмма мин эзлим-эзлим дә, барыбер Скомороховка әйләнеп кайтам», – диде күргәзмәне ачу тантанасында режиссер Ф.Бикчәнтәев. Аның бу сүзләре сәхнә рәссамы өчен алтын бәясенә тиң. Чит милләттән булса да, татар театрын ярата, димәк. Мәхәббәтле кеше турында гына шундый мактау сүзләре әйтергә мөмкин. Ә татар театрын яратмау мөмкин түгел. Әгәр дә Гаяз Исхакыйның «Зөләйха»сын бизәп гасырлар буе изелгән, җәберләнгән татар кешесе өчен әрнисең икән, Туфан Миңнуллинның «Илгизәр+Вера»сы өчен сәхнә бизәлешләре ясап, тарихны, ата-баба сүзен онытқан бүгенге яшьләрнең фаҗигасен үз йөрәгең аша кичерәсең икән, татар милләтен гомерең буе якын күреп яшәячәксең. Туфан аганың «Җан-кисәккәем», «Галиябану, сылуым, иркәм» спектакльләренә декорация, костюм эскизлары ясагансың икән, син татар җанын аңлагансың дигән сүз. Г.Камалның «Кайниш, көндәш һәм башкалар», К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл», «Казан сөлгесе» әсәрләрен, андагы татар тормышын, милли бизәкләребезне яратмау мөмкинме соң?!

Татар җанын аңлап кына калмады, Скоморохов режиссерлар белән бергә җиһан зурлыгындагы проблемалар күтәрде. Чыңгыз Айтматов әсәре буенча куелган «Ахырзаман» спектаклендә кешелекне табигать һәм андагы җан ияләрен рәнҗеткән, кыерсыткан өчен җавап тотарга кирәк булачак, дип кисәтте. Георгий Хугаев әсәре буенча сәхнәләштерелгән «Кара чикмән» тамашасында исә адәм баласының табигатенә салынган хисләрне – куркаклыкны, сатлыкны, тәлинкә тотуны, ялагайлыкны үтемле сәхнә чаралары ярдәмендә фаш итте.

Шулкадәр җитди, көн кадагына суга торган әсәрләрне бизәү белән бергә С.Скоморохов үзенә алмаш та тәрбияли. Казан сәнгать училищесында элек-электән эшләп килгән театр рәссамнары бүлеген, 1990 еллар уртасында ябып торганнан соң, 2016 елда С.Скомороховның бәхетенә кабат ачалар һәм Геннадий улы Сергей анда берничә курс укытып чыгара. Гөнаһ шомлыгына, гөрләп эшләгән бүлекне кабат туктаталар. Ниһаять, моннан ике ел элек С.Скоморохов кабат мөгаллим дәрәҗәсенә ия була. Бүген аның шәкертләре икенче курста укый. Алар укуларын тәмамлагач, тагын ике елдан театр рәссамнары бүлеген япмаслар, яңа курс җыярлар дип ышанасы килә. Юбилей күргәзмәсендә Скоморохов шәкертләренең спектакльләргә иҗат ителгән эскиз, макетларын да күрдек. Сигез шәкерте үзләре дә остазларын тәбрикләргә килгән иде. «Сергей Геннадьевичның шәкертләрен укытуы рәхәт. Алар фикерли белә, белемнәре киң кырлы», – дип оста мөгаллимгә ия булуына шатланып туя алмады күргәзмәне ачу тантанасында сәнгать училищесының директоры Ольга Гыйльметдинова.

Спектакль турында сөйләсәләр, язсалар, гадәттә режиссер һәм артистларны гына телгә алалар, сәхнә рәссамнары күләгәдә кала. Аз сүзле, тыйнак Сергей Скоморохов исә күптән инде Камал театрыныкы гына түгел, бөтен Идел буе театрларының рәссамына әйләнгән. Әтнәдә генә дә С.Скоморохов бизәлешендә сәхнә күргән спектакльләр егермедән артык. Юбилей күргәзмәне ачканда, иҗатташлары исеменнән күренекле артистыбыз Илдар Хәйруллин С.Скомороховның кешелек сыйфатларын мактап телгә алды, кайсы театрда иҗат итсә дә, кешене хөрмәт итеп, итагатьле мөгамәлә кора белүен, зыялылыгын искәртте.

«Моннан унбиш ел элек «Зур Идел» төбәк күргәзмәсендә беренче һәм бердәнбер булып үз иҗат әсәрләрен тәкъдим иткән театр рәссамы – Сергей Скоморохов», - дип сәнгать фәннәре докторы, чараны оештыручы Рауза Солтанова рәсем сәнгате белеме турында офыкларыбызны киңәйтеп җибәрде. Шөкер, хәзер театр рәссамнары башка кылкаләм осталары белән бертигез мәртәбәле күргәзмәләрдә катнаша. Татарстан Рәссамнар берлегеннән Илнур Сираҗиевнең күргәзмәгә килеп Скомороховны котлавы бөтен рәссамнарның театр сурәтчеләренә карата хөрмәтен күрсәтә.

С.Скомороховның ике улы да рәссам. Геннадийның эшләрен театрларыбызда әледән-әле күреп торабыз. Күптән түгел К.Тинчурин театрында куелган «Мәдинә» спектаклендә сәхнә бизәлешләрен, мәсәлән, ул иҗат иткән. Икенче улы Юрий бүгенге көндә сиракка әйләнгән һөнәр иясе – китап иллюстраторы.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.



Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;
222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;
222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;
222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:
ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ
420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратыгыз

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга.
Бу санның чыгу көне 22.04.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2750 данә

Заказ 2749

16+